Таҗетдин ЯЛЧЫГОЛ

# ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЯ

## (Болгар тарихы)

www.darul-kutub.com

«Хузур» нәшрият йорты

Казан 2014

ББК 86.38

Гарәп графикасындагы текстларны гамәлдәге язуга күчереп транскрипцияләрен эшләүче, әсәрләрне хәзерге татар әдәби теленә күчерүче, искәрмә һәм сүзлекләрне язучы, кереш мәкалә авторы – филология фәннәре кандидаты **Сәлим ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВ**.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте

Экспертлар советы карарына нигезләнеп басыла

**ТАҖЕТДИН ЯЛЧЫГОЛ.** ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЯ. – Казан: Хузур-Спокойствие, 2014. – 154 б.

Җыентыкка татар тарихында мәгълүм язучы Таҗетдин Ялчыголның әдәби-тарихи чыганакларыбызга караган «Тәварихы Болгария» исемле ике әсәре кертелде. Язучының моңарчы укучыларга Мөслими псевдонимы белән билгеле булган бер әсәре беренче тапкыр Таҗетдин Ялчыгол исеме белән нәшер ителә. Китап халкыбызның тарихы һәм әдәбияты белән кызыксынучылар өчен тәкъдим ителә.

© *Издательство «Хузур-Спокойствие»*
© *Гилязутдинов С.М.*

www.darul-kutub.com

Татар халкы, татар кешесе борынгы төрки чордан ук килгән традиция буенча үзенең әти һәм әнисе ягыннан бабалары исемнәрен җиде буынга хәтле белергә тиеш булган. Хөрмәтле бабам Таҗетдин Ялчыгол бу традициягә тугрылыклы булып халкыбызга бик кирәкле китап язган һәм шуның белән безгә дә, үзенең оныкларына да изге традицияне сакларга васыять итеп калдырган. Ә инде татар халкының ике гасыр буе бик яратып укылып килгән, йөзләгән кулъязма нөсхәләре булган «Мөслими» псевдонимы белән язылган китапның да авторы бабам икәнен белү минем өчен бик шатлыклы вакыйга булды. Шуңа күрә бу ике китапны бастырып, халкыбызга яңадан кайтаруны үземнең изге бурычым дип исәплим.

*НӘКЫЯ СӘФӘРОВА*

www.darul-kutub.com

## ТАҖЕТДИН ЯЛЧЫГОЛНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТАРИХИ ҮТКӘНЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ТАРИХИ-ӘДӘБИ ХЕЗМӘТЛӘРЕ

Таҗетдин Ялчыголның 2000 нче елга хәтле бер генә тарихи-әдәби әсәре бар дип исәпләнелә иде: «Тәварихы Болгария» («Болгар тарихы») (1805). Әсәрнең кулъязма нөсхәләре чагыштырмача аз таралган һәм аның турындагы махсус тикшеренүләр дә бармак белән генә санарлык. Автор исә күп очракта Урта Азиядә яшәп иҗат иткән төрки шагыйре Суфи Аллаһийарның (1720-1721 нче елда үлгән) төрки телендә язылган «Сөбател гаҗизин» («Көчсезләрне ныгыту») әсәренә татарча язылган шәрехе (1725) белән бәйле рәвештә искә алына, чөнки бу шәрех революциягә хәтле татар халкы арасында гаять популяр була һәм 1847 нче елдан башлап XX гасыр башына хәтле кырыктан артык тапкыр басылып чыга.

Шулай да «Тәварихы Болгария»не тарихи чыганак буларак махсус тикшергән тарихчы М.Госманов әйтүенчә, «Идел һәм Урал буенда яшәгән төрки телле киң масса укучыларның тарихи белеме түбән булуы аркасында, Таҗетдин Ялчыголның бу әсәре бераз таралыш тапкан. Безнең кулда аның уннан артык кулъязма нөсхәсе бар» [1:158]. «Тәварихы Болгария» революциягә хәтле тулысынча нәшер ителмәгән. Бары тик 1897 нче елда гына башкорт галиме М.Өмидбаев тарафыннан кыскартылган варианты гына дөнья күрә [2, 1897].

1990 һәм 1998 нче елларда И. Галәветдинов әсәрнең тәнкыйди текстын бастырып чыгара. Монографиядә тарихи ядкәрнең кулъязма нөсхәләренә лингвотекстологик анализ ясала, русчага тәрҗемәсе дә бирелә [3, 1990; 1998].

Таҗетдин Ялчыгол турында без, нигездә, «Тәварихы Болгария»дә үзе язып калдырган мәгълүматлар буенча гына беләбез. Авторның биографиясен ачыклау өчен Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафадел

әхбар» [4:251] һәм Риза Фәхретдиновның «Асар» [5:151] китапларында китерелгән мәгълүматлар аеруча мөһим.

Барлык тикшеренүчеләрнең фикеренчә, авторның үзе турында язганнары бик буталчык, шулай да аның биографиясен азмы-күпме күзалларга мөмкинлек бирә. Таҗетдин бине Ялчыгол бине Мәмәткол бине Янтимер бине Җәянчура бине Котлыбулат чама белән 1768 нче елда Ялчыгол атлы башкорт гаиләсендә туган. Әтисе хаҗга барганда аңа ияргән һәм берничә ел Төркиянең Диарбәкер шәһәрендә яшәгән. Соңыннан әтисе белән Россиягә кайткан. Алар, күп сәяхәт итеп, Россиянең төрле төбәкләрендә (Әстерхан, Мәскәү, Түбән Новгород, Казан һ. б. шәһәрләрендә) булганнар. Әтисе Татарстанның Түбән Сөн авылында вафат булганнан соң, аның васыятен үтәп, Таҗетдин Татарстан җирлегендә яшәп калган Җирекле, Кызыл Чапчак, Мәлем авылларында имамлык иткән, табибчылык белән шөгыльләнгән. 1838 нче елда Имәнлебаш авылында кинәт вафат булган.

Композициясе ягыннан «Тәварихы Болгария» бик тотрыксыз. Ул, нигездә, Таҗетдин Ялчыголның «хыялый» нәсел шәҗәрәсеннән тора.

Бу җыентыкка кергән икенче әсәрнең исеме дә «Тәварихы Болгария», ягъни «Болгар тарихы». Татар әдәбияты тарихында бик каршылыклы бәяләмәләр алган башка әсәр юктыр, мөгаен. Берәүләр аны күккә чөеп мактады һәм хәзер дә мактый, икенчеләр исә көчле тәнкыйть утына тотты һәм әле дә сүгә.

Революциядән соң китапның 1999 нчы елга хәтле хәзерге әдәби телдә тулысынча басылмавы да, алты томлык татар әдәбияты тарихында аның турында махсус мәкалә булмавының сәбәбе дә, мөгаен, шундадыр. Хәлбуки, халык арасында киң таралуын исәпкә алсак, ул иң укыла торган һәм иң популяр тарихи әсәрләрнең берсе булган. М.Госманов күрсәтеп киткәнчә, XX гасырның 60 нчы еллары ахырында аның кульязма нөсхәләре генә дә 45 данә исәпләнгән, ә инде басылган текстлар һәм төрле кешеләр кулында сакланган нөсхәләр турындагы мәгълүматларны да исәпкә алсаң, аларның саны алтмыштан артып китә [6:134].

Хәзерге көндә исә бу саннар ике мәртәбә артык. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә генә дә әсәрнең 2007 нче елга хәтле тупланган 13 кульязма нөсхәсе саклана (Ф 39, саклау берәмлекләре 2082; 2269; 2462; 3104; 3323; 4196; 4458; 5146; 5148; 5320; 5998; 6382; 6435).

www.darul-kutub.com

«Тәварихы Болгария» чагыштырмача тулы килеш 1870, 1887, 1892, 1902 нче елларда аерым китап булып басыла.

Әсәрнең гамәлдәге язмада басылып чыкмавын истә тотып, 1999 нчы елда, ул вакытта Апанай мәчетенең имам-хатыйбы Вәлиулла хәзрәт Якуповның (1963-2012) хәер-догасы белән без әсәрнең тулы транскрипциясен, аның татар теленә тәрҗемәсен эшләп, кереш мәкалә һәм сүзлек, искәрмәләр язып «Иман» нәшриятында бастырган идек [7, 1999]. Китап бик тиз арада таралып бетте. Китап киң җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләмә алды. Мәсәлән, танылган галим Әнвәр Хәйри бу басма турында болай дип язып чыккан иде: «Гомумән, бу китап тулысынча итеп һәм текстологик эшкәртелеп, XX гасырда беренче тапкыр без куллана торган хәрефләрдә басылып чыгуы белән дә кыйммәтле һәм зур фәнни әһәмияткә ия булып тора. Бу китап – татар тарихы, татар әдәбияты тарихы, татар язма теле тарихы һәм башка төрле фән тармакларында эшләүче белгечләргә бик кирәкле һәм файдалы кулланма булачак» [8, 2000].

Инде китапның авторы мәсьәләсенә тукталыйк. Китапның тулы нөсхәләренең барысында да авторның исеме ике төрле язылган: әсәрнең башында аның исеме Хисаметдин бине Шәрәфетдин дип бирелсә, ахырында Шәрәфетдин бине Хисаметдин диелә. Шуңа күрә татар әдәбияты тарихында ул Мөслими исеме белән генә искә алына. Ә инде «Тәварихы Болгария» әсәрен җентекләп өйрәнгән атаклы тарихчыбыз Миркасыйм ага Госманов, гомумән, «китапның чын авторының исеме бөтенләй башка булуы да бик мөмкин» дип язып чыкты [9:153].

Танылган археограф һәм текстолог, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов бу ике әсәрнең телен, стилен һәм эчтәлеген чагыштырып «Мистик Мөслимигә» нисбәтләнгән «Тәварихы Болгария»нең чын авторының исемен ачык итеп әйтеп бирә: «Тәварихы Болгария»дә күтәрелгән проблемалар һәм файдаланылган тарихи фактларның байтагы икенче бер татар язучысы Таҗетдин бине Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» (кулъязмада) «Рисаләи Газизә» исемле әсәрләрендә кабатлана. Соңгы ике әсәр дә XVIII гасыр ахырында язылган. «Мөслими»нең бигрәк тә Ык, Минзәлә, Зәй төбәген яхшы белүен искә алсаң һәм Әйдән табигыйннар күрсәтүен дә санасаң аның күп кенә параметрлар буенча Таҗетдин бине Ялчыгол әл-Башгыри әл-Болгарига туры килгәнлегенә игътибар итәрбез. Таҗетдин Ялчыгол да үзен Әй буеннан чыккан «башкорт» итеп

www.darulkutub.com

күрсәтә, ләкин үзе җир алу мөмкинлекләре җиңеллеге белән кызыктырган ватанына бер дә кайтмый, Имәнле авылында үлеп кала.

«Тарихнамәи Болгар» авторының үзенең дә узган тормышы бик серле. Шунлыктан ул «үзенең иҗатының башлангыч чорында псевдонимнар куеп язуы белән гаҗәпләндерми» [10:100].

Галимнең бу гипотезасының дөреслеген Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган бер үтә кызыклы кулъязмадагы фактлар да куәтли. Кулъязма Татарстан Республикасының Лениногорск районы Керкәле авылында табыла, аны 1993 нче елда археографик экспедиция вакытында Марсель Әхмәтҗанов үзе алып кайта (Ф.39. Саклану берәмлеге 4592).

Кулъязма безнең тарафтан җентекләп өйрәнелеп, нәтиҗәләре докторлык диссертациямнең монографиясендә һәм филология фәннәре кандидаты Ләйлә Гарипова белән бергә язылган мәкалә бездә нәшер ителгәнгә [11:133-139]; [12:128-144] аларга озак тукталып тормыйча сүзне шул урында туктатабыз.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. / М.А. Усманов. – Казань: Издательство Казанского университета, 1972.
2. Уметбаев М. Ядкар. – Казань, 1897. – С. 45-49.
3. Галяутдинов И.Г. Тарих намаи Булгар Таджетдина Ялсыгулова. – Уфа: Башкирское книжное издательство, 1990; Уфа: Китап, 1998.
4. Мәрҗани Ш. Мостафадел әхбар фи әхвале Казан вә Болгар. 2 кисәк / Ш.Мәрҗани. – Казан, 1990. – 368 б.
5. Фәхретдин Ризаэтдин. Асар. I том. – Казан: Рухият, 2006. – 360 б.
6. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. / М.А. Усманов. – Казань: Издательство Казанского университета, 1972.
7. Мөслими. Тәварихы Болгария. – Казан: Иман, 1999.


www.darul-kutub.com

8. Әнвәр Хәйри. Рухи мирасыбыз ядкарьләре. – Шәһри Казан, 2000. – 26 нчы февраль.

9. Әхмәтҗанов Марсель. Татар кулъязма китабы / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2000.

10. Гилязутдинов С.М. Персидско-татарские литературные связи (X-начало XX в.). – Казань, 2011. – 212 с.

11. Сәлим Гыйләҗетдинов, Ләйлә Гарипова. Габдерәхим Утыз Имәни Таҗетдин Ялчыгол әсәре турында. Әдәби мирас һәм текстология. Икенче чыгарылыш. – Казан, 2011.

*Сәлим ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВ,*
*филология фәннәре кандидаты*

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

### ТАҖЕТДИН ЯЛЧЫГОЛ

## ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЯ

### ТЕКСТНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНӘ КҮЧЕРМӘСЕ

## *БОЛГАР ТАРИХЫ*

Мәрхәмәтле һәм рәхимле Аллаһ исеме белән

Һәртөрле мактаулар Аллаһы Тәгаләгә ки, кешеләрне галим итеп, сөйләшә белүче һәм аңлатучы итеп яратты һәм аларны үз хәлләрен аңларлык итеп, акыллылар итеп яратты, үз нәсел-нәсәпләрен һәм килеп чыгышларын белерлек итеп яратты, үз гамәлләрен, кыямәт көнендә хөкем итәр өчен, белерлек итеп яратты. Аннан соң хәер-дога һәм сәлам Рәсүлгә, аның гаиләсенә һәм сәхабәләренә.

Әмма соңыннан бу иң кечкенә кол, зәгыйфь һәм хәлсез, фетнәче һәм гөнаһлы Хаҗи Ялчыгол улы Таҗетдин, үземнең нәселемнең асылын Адәм Сафиуллага тоташтырдым. Тарих китапларыннан карап, зур тырышлык белән «Чыңгыз намә»гә тоташтырдым. Аннан түбәнге бабаларыбызны, [Чыңгыз] намәдән карап, үземә тоташтырдым. Тарих мең дә ике йөз дә егерменче елда, Куй елында, Сөнбеләнең егерменче көнендә, гарәп ае белән рабигылахир аенда, бу иң түбән бәндә бу китапны төзеп, аңа «Тәварихы Болгария» исеме бирдем. Без файдаланган тарих китапларының исемнәре түбәндәгечә: имам Тәбриз әл-Юнаниның «Тәварихы Дәваир»; икенче – имам әт-Тусиның

«Тәварихы Фәрһәнг», өченче – имам әл-Чәләбинең «Тәварихы һирмез»; дүртенче – имам әл-Чәгыйның «Тәварихы Раузат әс-Сафа»; бишенче – имам әт-Тәбризинең «Тәварихы Касфәрани»; алтынчы – имам әт-Тарзиның «Тәварихы Җамасиб» һәм җиденче – «Мәсабих» иясе имам әл-Бәгавинең «Тәварихы әл-Чәләби». Чыңгыз ханга хәтле бу кадәр китаплардан карап исбат иттек.

Аннан түбән бабаларыбызны «Чыңгыз намә»гә карап һәм күпне күргән картлардан ишетеп, бабаларыбызның яза килгән китапларыннан карап, бу рисаләне язып, Адәм пәйгамбәргә тоташтырдым. Безнең уебызча, картлардан ишетелгән һәм алар язган хәбәрләр мәшһүр, һәм хәзер дә башкорт кабиләләрен бабаларыбыз исемнәре белән атап йөртәләр, шулай булгач, бу хәбәр мәшһүр була һәм халык арасында таралган була. Шуңа күрә мин аларга таянам һәм шаһитлыкка Аллаһы Тәгаләне чакырам.

1 . Беренче Габделхарис, ул Адәм балаларының башы, туфрактан яратылган һәм ул – Адәм Сафиулла. Адәмнең гомере мең ел булды, дип әйтәләр. Аның җиргә иңүеннән алып ахыр заман рәсүлулласы хәзрәтләре килгәнче, дүрт мең өч йөз кырык ел узды, дип әйтәләр. Кайберләре биш мең тугыз йөз җитмеш ике ел, диләр, һәм кайберләре илле мең йөз утыз ел, диләр. Әмма тәфсир китапларының күбесендә күрсәтелгәнчә, иң дөресе җиде мең ел, шулай кабул ителгән. Чөнки ике «Сахих» китабында әйтелгән: «Дөньяга җиде мең ел, һәм мин аның ахыргы меңенче елында». Бу хәдисне аңлатучылар әйтәләр: «Пәйгамбәрләр заманы җиде мең ел, мин аның ахыргы меңенче елы пәйгамбәре». «Аннан соңгы меңнәрдә пәйгамбәрләр булмаячак». Бохарига шәрех итеп язылган «Фәтхү әл-Хәй» китабында шулай дип язылган. Шул хәдис буенча фәтва бирелә һәм гамәл кылына. Чәләби һәм башка тарихчылар да бу хәдис буенча гамәл итәләр, алты тарих китабында да бу хәдис кулланыла. Адәм галәйһиссәламне Шәйс күмде. Кабере турында төрлечә сөйлиләр: кайберәүләр Һиндстанда, Сәрәндиб тавында диләр, ә кайберәүләр Мәккәдә, Әбү Кабис тавында диләр. Адәм галәй-

www.darul-kutub.com

һиссәлам вафат булганнан соң, анабыз Хава бер ел яшәде, аннан соң Шәйс аны Адәм янына күмде. Соңыннан, туфан вакытында Нух галәйһиссәлам аларны табутлары белән җирдән чыгарып көймәгә куйды. Туфаннан соң әл-Мөкаддәс җирендә Хәлил әр-Рахман күмде. Каберләре хәзер дә анда.

2 . Адәм Сафиулладан Шәйс туды. Шәйс «ш» хәрефенең фәт-хәсе һәм «и» хәрефенең сүкүне белән, аннан соң сакау «с» хәрефе килә. Йәһүдиләр телендә мәгънәсе: «Мәгыйснең колы». «Сөтүр» һәм «Камус» сүзлекләрендә шулай килә. Шәйс тугыз йөз ун ел гомер сөрде, һинстанда күмелде.

3 . Аннан Унуш туды. Унуш – һәмзәнең заммасы белән. Йәһүдиләр телендә мәгънәсе: «Каты таш». «Сөтүр» да шулай килә. Биш йөз егерме ел гомер сөрде. Кяферлеге яки мөселманлыгы турында бердәм фикер юк. Һиндстанда күмелде.

4 . Унушдан Кайнан туды. Кайнан – «к» хәрефенең фәтхәсе һәм «и» хәрефенең сүкүне белән. Сүрияләләр телендә мәгънәсе: «Җимеш агачы» һәм «Сөтле имчәк». «Дәваир»да шулай килә. Бу Кайнан сигез йөз ел гомер сөрде. Хак Тәгалә аңа хәлифәлек, изгелек һәм пәйгамбәрлек бирде. Шәйснең китабы белән гамәл итте. Бабасы янында күмелде.

5 . Аннан Мәла туды. Мәла тугыз йөз ел гомер сөрде. Кяферлеге яки мөселманлыгы хакында бердәм фикер юк. Һиндстанда күмелде.

6 . Аннан Йәздәк туды. Әмма Йәздәкнең гомере мәгълүм түгел, дине һәм мәгълүм түгел. Уллары йөз егерме булды.

7 . Кече улы Нух галәйһиссәлам. Аңа Идрис диләр. Әмма Идрис пәйгамбәр дөньяда өч йөз алтмыш биш ел булды, соңында күккә ашты. Язу язмак, кафтан тегү, дин өчен сугыш һәм дәрес әйтү дөньяда аннан калды.

8. Идристән Әдәбән туды. Әдәбәннең гомере ике йөз ел булды. Галим һәм диндар кеше иде. Гыйрак шәһәрен ул төзеде. Гыйракта күмелде.

9. Әдәбәннән Һуд туды. Әмма бу Һуд Һуд пәйгамбәр түгел. Гомере өч йөз егерме ел булды. Кайсы милләттән икәне дә билгеле түгел. Гыйракта күмелде.

www.darulkutub.com

10. Һудтан Мөтәвәшшәх туды. Әмма Мөтәвәшшәхнең гомере һәм милләте билгеле түгел. Уллары бик күп иде. Ике йөз җитмеш яшенә җиткәндә.

11.Аннан Һибәтулла галәйһиссәлам туды, аңа Нух галәйһиссәлам диләр. Күп елаганы өчен Нух куелды. Әмма Нух галәйһиссәлам мең ел гомер сөрде. Илле йөз илле кавемне иманга өндәде. Күктән китап иңмәде, Идрис галәйһиссәлам китабы белән гамәл итте. Туфаннан соң йөз ел гомер сөреп, һиндстанда күмелде. Туфаннан соңгы гомерен Аллаһы Тәгалә хисапламады. «Тәварихы Раузат әс-Сафа»да шулай килә. Нухның дүрт улы булды: Кәнган Туфанда һәлак булды, кяфер иде. Калган өч улы: Сам, Йәфәс, Хам.

12. Әмма Хам Исфаханда падишаһ булды. Гомере алты йөз егерме ел булды. [Аның утыз улы булды.] Кече улы Кәюмирас. һиндстанда күмелде.

13. Бу Кәюмирас һәм падишаһ булды. Җиде йөз ел гомер сөрде. Идрис динендә иде. Кешеләргә беренче хотбә укыган ул булды. Падишаһлык итүне ул кертте. Бәлех һәм Керман шәһәрләрен ул төзеде. Бәлехтә күмелгән.

14. Кәюмирасдан Сийам туды. Сийамның гомере алты йөз ел. Милләте билгеле түгел. Ниһавәндә күмелде.

15. Сийамнан һушәнг туды. Әмма һушәнг шаһның гомере җиде йөз ел булды. Җиһанда гаделлек белән хөкем итте. Алтын-көмеш чыгару һәм тәхет төзү аннан калды. Сусан шәһәрләрен төзеде. Көнбатыш Европа халкының атасы. Сусан илендә Бажурда вафат булды. Көнбатыш илләренең күбесе аның нәселеннән.

16. Аның кече улы Таһморат исемле. Тарих китаплары Таһморат нәселе турында язалар, һушәнгнең башка уллары Түз һәм Хүзлаф. Таһмoратның гомере дүрт йөз ел булды, диләр. Диюләрне үзенә буйсындырды. Атны иярләү һәм корал ясау аннан калды. Мәрев, Шабур һәм Парс шәһәрләрен ул төзеде. Мәревтә вафат булды. Улы-кызы күп иде. Каһарман Катил – аның улы. Билгеле тарих китаплары буенча, безгә төп ата – аның кече улы Мәрван. Ягъни аның нәселе Чыңгыз ханга килеп тоташа.

17. Әмма Мәрван Бәдәхшанда ике йөз ел гомер сөрде, падишаһ булды. Кяферме, мөселманмы икәне билгеле түгел. Бәдәхшанда күмелде.

18. Мәрваннан Әфлаюн туды. Әмма Әфлаюнның гомере билгеле түгел. Багдад, Басра һәм Ку фәне ул төзеде. Багдадта күмелде. Хәзрәте Муса галәйһиссәлам заманына хәтле күп пәйгамбәрләр килделәр, иман китермәделәр. Әмма бу Әфлаюн хәзрәте Җирҗиз заманына хәтле утка табынды. Әмма бу Әфлаюн Мәҗмәгыйль-Бәхергә сәфәр иткәндә, хәзрәте Даудка иптәш булып, аның сәхабәсе булды. Багдадта күмелде.

19. Аннан Әкратис туды. Бу Әкратисның гомере билгеле түгел. Хәзрәте Йушыгга иман китерде. Димәшкъны ул төзеде. Анда күмелде.

20. Аннан Карамуш туды. Әмма бу Карамуш сихер гыйлемен яхшы белер иде. Сыерга табынучылар динендә Хәбәш илендә ике йөз алтмыш биш ел яшәп шаһ булды.

21. Карамушдан Әфламун туды. Хәзрәте Ясигъ галәйһиссәлам заманында аның әсхабыннан булып. Мәгъриб һәм Кум илләрендә шаһ булды. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел.

22. Әфламуннан Кинанә туды. Бу Кинанә әшәке, явыз кяфер иде. Чин илендә җеннәр һәм диюләр белән дус булып, Чин илен алды. Йөз утыз ел гомер сөрде. Шаһ булды. Анда күмелде.

23. Бу Кинанәдән Әфратим туды. Әфратим хәзрәте Сөләйман заманында, аңа әсхаб булып, Кодус һәм Фәләстыйн иленә килде. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел.

24. Әфратимнән Тәһлаеш туды. Сөләйман галәйһиссәлам заманыннан соң бу Тәһлаеш, кан коючы юлбасар булып, йөз алтмыш ел яшәде. Эткә табынучы иде. Шираз илендә күмелде.

25. Аннан Мәһлаеш туды. Бу Мәһлаеш гомеренең башында эткә табынучы иде. Аннан котылып хәзрәте Ильяс галәйһиссәламгә ияреп мөселман булды. Харәзем илендә йөз алтмыш ел гомер сөрде. Бәгалбәк дип Мәһлаеш кавеменә әйтәләр.

26. Аннан Әмкәш туды. Йөз туксан ел гомер сөрде. Харәземдә күмелде.

www.darulkutub.com

27. Аннан Тагланыш туды. Бу Тагланыш Төркестанны төзеде. Каберләргә төрбә кую, балаларга сабак өйрәтү һәм салым җыю аннан калды. Йөз дә өч ел гомер сөреп, Төркестанда вафат булды. Әмма дине Муса галәйһиссәлам динендә, яһүди иде. Болар барысы да алда әйтеп кителгән биш тарих китабыннан алынды. «Касфәрәни»дә әйтелгән, Әфләх Тагланышдан туды, дип.

28. Бу Әфләх – кыргыз халкының асылы һәм нигезе. Көтүлектән көтүлеккә күчеп йөрү аннан калды. Йөз ун ел гомер сөрде. Сырдәрьяда батып үлде. Кяферме, мөселманмы икәне билгеле түгел.

29. Аннан Мард туды. Бу Мард – төрекмән халкының атасы. Аннан күп уллар туды. Олы улы

30. Төрекмән, аннан кечесе Конгырат, аннан кече Бөрҗән, аннан кече Мангыт, аннан кече Кәрҗе, аннан кече Кыпчак, аннан кече Йөрмәте, аннан кече Кара Калпак. Бу заманнардагы халыкларның чыгышы боларның нәселеннән. Мардның гомере һәм дине билгеле түгел.

31. Төрекмәннән Кинҗә туды. Әмма бу Кинҗә Гайсә динендә иде. Бохараны ул төзеде. Гомере туксан елдыр. Бохарада күмелде. Бу Кинҗәдән күп уллар туды. Олы улы Татар, аннан кечесе Мишәр, аннан кечесе Иштәк, аннан кечесе Нугай. Болар һәрбере, шаһ булып, галәмнең төрле якларында дәүләтләр төзеделәр. Хәзерге халыклар чыгышы алар нәселеннән, дип сөйлиләр.

32. Бу Кинҗә улларыннан безнең нәселнең башлангыч бабасы – Иштәк. Бу Иштәк камил ир булды. Кәгъбәгә барды, күп дөяләр корбан чалды. Тәүрат белән Инҗилне камил белер иде. Гыйлемлектә тиңе юк иде. Бу Иштәктән күп уллар туды. Төп йорты Амудәрьяда иде. Олы улы Тамьян, аннан кечесе Үсүргән, аннан кечесе Күбләк, аннан кечесе Бәкәтун, аннан кечесе Сарт, аннан кечесе Торнакол, аннан кечесе Туплас, аннан кечесе Дәван. Бу халыклар – алар нәселеннән.

33. Әмма бу Иштәк улларыннан безгә баба тиешлесе Бәкәтун. Бу Бәкәтун гаять үпкәләүчән кеше иде. Җирен ташлап

төньяк тарафына барып Мияч елгасына килде. Анда урнашып туксан ел яшәде. Аның уллары күп булды. Олы улы Әйле, аннан кечесе Йөрми, аннан кечесе Байлар, аннан кечесе Байкы, аннан кечесе Ирәкитә, аннан кечесе Салчут. Болар һәрберсе, шаһ булып, галәмнең төрле якларына җәелделәр. Бу халыклар алар нәселеннән. Әмма Бәкәтун христиан динендә иде.

34. Безгә төп баба – олы улы Әйле. Әйле атасының төп йортында калды. Илле ел шаһ булып Мияч елгасында туксан тугыз ел яшәде. Вафаты анда булды.

35. Әйледән Нариман туды. Бу Нариман дөнья буйлап сәяхәт итте. Грек иленә белем алыр өчен китте. Күп гыйлемнәргә өйрәнде. Хикмәк гыйлемендә егерме дүрт китап язды. Христиан попы иде. Заманында, олы падишаһ булып, Сәмәркандны төзеде. Йөз ел яшәде. Шулай ук таш калалар төзеде, бу заманда һәм эзләре бар – «Кыяфәт биналары» дип атыйлар.

36. Нариманнан Касур шаһ туды. Ул да «күркәм» Сәмәркандта туксан ел яшәп, Гайсә динендә вафат булды.

37. Аннан Сократ хәким туды. Бу Сократ грек иленә килде. Ахырында Искәндәр Руми каршында хәким булып, «тормыш суы» эзләп төньяк тарафка килделәр. Бер шәһәр төзеделәр, исемен Болгар куйдылар. «Болгар» – грек телендә «хуш исле», шулай ук «агачлы» һәм «елгалы» дигәнне аңлата. Елгасының исеме дә – Болгар. Кыскартып, бу заманда «Булгы» дип әйтәләр, «Болгар»-дан үзгәртелеп «Булгы» булган. «Фәрһәнг намә»дә шулай дип язылган. Ул заманда Сократ хәким Болгардан бер кызны никахлады. Искәндәр шаһ белән Болгарда тугыз ай тордылар. Аннан соң «Караңгылык иленә киттеләр», «Караңгылык» иленнән кайтканда, Сократ хәким шунда вафат булды.

38. Әмма Сократ хәкимнең мәзкүр кыздан бер улы туды, исемен Гөфтар куйдылар. Сократ хәкимнең күпме яшәгәне билгеле түгел. Бу Гөфтар Болгарда шаһ булды, гомере туксан ел диләр. Утка табынучы иде, күп еллар шул динендә булды.

39. Аннан Айдар туды. Ак диңгездә Ташкүперне ул төзеде. Бик гадел шаһ иде. Дине һәм гомере билгеле түгел.

www.darul-kutub.com

40. Аннан Һәрмәз туды. Бу һәм Ташкүпердә шаһ булды. Дине һәм гомере билгеле түгел.

41. Аннан Алмас туды. Ташкүпердә яшәде, күпме яшәгәне билгеле түгел.

42. Алмасдан Мирһашим туды. Ул һәм Ак диңгез ярында бер шәһәр төзеде, исемен Әдернә куйды. Солтан исемен (падишаһга) әүвәл ул бирде. Туксан ел яшәде. Кодускә баргач, Гайсә галәйһиссәламнең Инҗилен күреп иман китерде.

43. Аннан Бабәк туды. Ул һәм Сальянда солтан булып җитмеш сигез ел гомер сөрде. Сальянда күмелде.

44. Аннан Корнакый туды. Йөз туксан ел яшәде. Аннан күп уллар туды. Кайсы Кырымда, кайсы Кытайда, Гыйракта солтан булдылар.

45. Безгә баба кече улы Даймас. Даймас төньяк өлкәдә Содум исемле шәһәр төзеде. Әмма Корнакыйның күмелгән җире билгеле түгел. Даймасның күпме яшәгәне билгеле түгел. Бу заманда ул Содумны Алабуга диләр, кечерәк бер кала. Ул Даймас солтаннан ике ул туды. Олы улы Владимир, икенчесе Мәскәү.

46. Безгә баба Мәскәү. Мәскәү белән Владимирга Даймас ике шәһәр төзеде, берсен Мәскәү, икенчесен Владимир дип атады. [Мәскәү]нең күпме яшәгәне билгеле түгел.

47. Мәскәүдән Тагыюн туды, христиан иде. Алтмыш ел гомер сөрде. Мәскәүдә солтан булды, анда үлде.

48. Тагыюннан Митрофан туды. Һератка барганда, юлбасарлар үтерде, күпме яшәгәне билгеле түгел.

49. Аннан Якау туды. Бу Якау Ак диңгезгә барды, бик зур галим булды, Ягъкубия дип аңа әйтәләр. «Өч китапны» өйрәнде. Алтмыш биш яшендә үлде, диләр. Бәдәхшанда күмелде, диләр.

50. Аннан Мард туды. Бу Мард башта Хәшвәр белән Бохара арасында юлбасар булды, ахырында Бохарага килде. Яһүд динендә сиксән ел яшәп, Бохарада үлде. Бохарада күмелде.

51. Мардтан Әмлан яһүд туды. Бу Әмланның улы-кызы күп булды. Кече улы Тимерҗан – безгә баба. Мардның гомере күпме булганы билгеле түгел.

www.darul-kutub.com

52. Бу Тимерҗан Төркестанда солтан иде. Туксан алты яшендә вафат булды. Гайсә динендә иде.

53. Аннан Бакыйҗан туды. Болгар халкына сугыш белән килде. Болгарның шаһын үтерде, Гайсә диненә өндәп. Йөз ел Болгарда яшәде, шунда үлде. Адәм Сафиулладан Бакыйҗанга хәтле илле ике баба. Барысын «Раузат әс-Сафа» тарихыннан фарсы теленнән төрки теленә тәрҗемә иттем, һәм моннан түбәнге бабалар, Чыңгыз хан чыкканчыга хәтле, «Тәварихы Җамасиб» һәм «Тәварихы Чәләби»дән тәрҗемә ителде. Белмичә калмагыз «Тәварихы Җамасиб»та һәм «Тәварихы Шам»да гарәпчә әйтелгән: «Бакыйҗан Фарсидан Шәмсун әл-Габид туды». Бетте.

54. Бу Шәмсун, үсеп буйга җиткәч, Кодускә килде. Кодустә Инҗилне укыды, яхшы остаз булды. Аңнан Куфәгә килде. Анда иман китермәгән гарәпләрне иманга өндәде. Соңында Куфәдә бәк булды. Йөз ун ел яшәп, Куфәдә вафат булды.

55. Аннан Науширван Гадел туды. Науширван Гадел заманында гарәпләр илендә җаһилият чоры иде. «Зәбур», «Тәүрат» һәм «Инҗил»не белгән кеше гарәп илендә калмаган иде. Наушырван Гадел үсеп җиткәннән соң, Төркестан чигеннән Көнбатышка хәтле ул алмаган шәһәр калмады, барысы аның кул астында иде. Пәйгамбәрләр җитәкчесе, аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер догасы һәм сәламе ирешсен, аның заманында килде: «Мин Солтан Гадел заманында тудым» дигәненнән Науширван күздә тотыла. Кырык сигез ел гаделлек белән Йәмәндә шаһ булды. Вафаты да шунда булды. Аннан ике ул туды. Олы улы Керан, кече улы Бездан. Безләр Бездан ыругыннан. Керан хәзрәте Имам Әгъзам ыругы. Мәсәлән: Керан улы Хордан, Хордан улы Шәһәр, Шәһәр улы Мирәз, Мирәз улы һәрмәз, һәрмәз улы Сабит, Сабит улы Ногман һәм ул – Имам әл-Әгъзам.

56. Без үз бабабыз Безданга килик. Бездан үсеп буйга җиткәннән соң, шәһәрдән-шәһәргә йөрергә иядәшеп китте. Чин, Мачин, Харәзем һәм һинд стан өлкәләрен йөреп, Хытай йортына килде. Хытай шаһының кызына гашыйк булды. Маг диненә керде, Хытай шаһының кызын алды. Кызның атасы үлгәннән

соң, Хытай йортында шаһ булып, утыз алты ел тәхеттә утырды. Хытай шаһының бер туганы, Шәбестан иленнән гаскәр белән килеп, Безданнан тәхетне алды, Безданны үтерде.

57. Аннан бер ул калды, исемен Тукый куйдылар. Атасыннан дүрт яшендә калды. Тукый үсеп буйга җиткәннән соң, һичбер шаһ аны [шаһ] урынына утыртмады. Нәтиҗәдә Хытай йортыннан качты. Качкан колларны, эшсезләрне һәм каракларны җыеп, үзенә гаскәр итте. Болгар чигенә килделәр, Болгар шәһәрен алдылар. Тукый үзенә лаек бер исем кушты, «хан» дип. «Хан» дип әйтү Тукыйдан калган. Төркиләр үз шаһларын «хан» дип әйтәләр.

Рәсүлулла, аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен, Тукый хан заманында әсхабеннән өч кешене сайлап [Болгарга] җибәрде. Аның дәверендә Болгар халкы мәҗүси иде. Ул заманда болгарларның йортлары биш йөз егерме булган, диләр. Булгы дигән Идел елгасы Болгарның астыннан ага икән. Бараҗ ханнан соң илле ел үткәч, Мир Тимер хәзрәтләре Болгарны харап итте. Аннан соң Булгы иделе, аннан күчеп, көнбатыш тарафына китте.

58. Пәйгамбәр вакытында Тукый ханның улы Айдар хан тәхеткә утырды. Тарих хиҗрәтнең тугызынчы елында Айдар хан тәхеткә утырды. Пәйгамбәр галәйһиссәлам сәхабәләреннән өч кешене сайлап, дингә өндәү өчен, Болгарга җибәрде. Ул сәхабәләрнең берсе – Габдрахман бине Зөбәер, икенчесе – Хантал бине Рабигъ, өченчесе – Зөбәер бине Җәгъдә. Бу сәхабәләрне җибәргәндә Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Мин сезгә өч нәрсә бирдем, сездән могҗиза күрсәтергә сораганда шулардай файдаланырсыз».

Беренчесе – кара савыты, аны Зөбәергә бирде, икенчесе – таяк, аны Ханталга бирде, өченчесе – чалма, аны Габдрахманга бирде. Болгарга килгәч, болар үзләрен табиб дип күрсәтеп, кешеләрне дәвалап йөрделәр. Нихәтле авыру булса, барысы да терелде.

Кыскасы, бер көн Айдар ханның кызына паралич булды. Ни кадәр табибларга мөрәҗәгать итсә дә терелмәде, гаҗиз булды.

www.darul-kutub.com

Бер көнне вәзирләре арасыннан Бураҗ исемле вәзире әйтте: «Әй ханым! Гомереӊ озын булсын, безнеӊ шәһәр эчендә өч гарәп бар, табиблыкта тиӊнәре юк. Бәлкем, бу кызның чиренә дәрман табарлар, әмма диннәре безнеке кебек түгел». Вәзир бу сүзләрне әйткәч, хан гарәпләрне чакырырга кушты. Кыскасы, сәхабәләр килделәр, сәлам бирделәр. Хантал бине Рабигъ хәзрәтләре төрки һәм грек телләрен тиӊсез яхшы белә иде, шулай ук Коръәнхафиз иде.

Хан әйтте:

– Әй гарәпләр, кайдан килдегез? Хантал әйтте:

– Мәдинәдән килдек. Хан әйтте:

– Нәрсә эзлисез? Хантал әйтте:

– Авыруларны дәвалыйбыз. Хан әйтте:

– Минем бер кызым бар, җиде ел буе авырый, аны терелтә алырсызмы?

– Хантал әйтте: «Чирен күрик». Чирен күргәч әйтте: «Бу паралич чире, моӊа сарбан агачы яфрагы кирәк»,– диде. Хан әйтте: «Сарбан нинди агач?»

– Каен агачы. Хан әйтте:

– Бездә ул агач күп.

Каен агачын китергәч, Хантал әйтте: «Бу иске каен яфрагы, безгә агачтан яӊа алганы кирәк», – диде. Хан әйтте: «Кыш көнендә аны кайдан табырга кирәк?» – диде. Хантал әйтте: «Аллаһы Тәгалә теләсә, аны без табарбыз, әмма шул шарт белән, безнеӊ динебезгә иман китерсәӊ», – диде. Хан әйтте: «Әгәр яӊа каен яфрагы тапсагыз һәм кызым терелсә, ислам диненә керермен»,– диде. Кыскасы, сәхабәләр Пәйгамбәр галәйһиссәлам биргән кара савытын җиргә куйдылар, таякны кара савыты эченә кадап куйдылар, хәзрәте Габдрахман бине Зөбәер, Пәйгамбәр галәйһиссәлам биргән чалманы киеп, ике рәкәгать намаз укыды, бу ике сәхабә «амин» диделәр. Баягы таяк үсеп бер кечерәк агач булды, хан өенеӊ түбәсенә җитте, ботакланып яфракланды. Җыеп себерке ясадылар, кызны мунчага кертеп чаптырдылар, кыз, шунда ук терелеп, өенә кайтты. Хан бу хәлне күреп иман китерде. Аннан Бураҗ вәзир, аннан соӊ башка вәзирләр

һәм калган шәһәр халкы барысы да иман китерделәр. Җәмигъ мәчете төзеделәр. Хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдә, имам булып, Пәйгамбәребез биргән таякка таянып хотбә укыды. Ул заманда, һиҗрәтнең 12 нче елында, Куй елы Балык йолдызлыгы аеның 26 нчы көнендә, изге Рамазанның 12 нче көнендә сәхабәләр Болгар халкын мөселман иттеләр. Бу өч сәхабә Болгарда ун ел калдылар, мәдрәсә төзеделәр, халыкны укыттылар. Аннан соң Габдрахман бине Зөбәер һәм Зөбәер бине Җәгъдә – икесе дә Мәдинәгә киттеләр. Хантал Болгарда калды, баягы авырудан терелгән кызны никахлады. Еллар үткәч, Хантал бине Рабигъ вафат булды. Аннан Мөхәммәд Әмин хан туды. Болар барысы да имам Чәләбинең «Тәварихы Һәрмәз»еннән алынды.

59. Айдар ханнан Сәйид хан туды. Айдар хан белән Сәйид хан һәр икесе Болгарда йөз ел ханлык кылдылар.

60. Сәйид ханнан Әмир хан туды, ул да илле ел ханлык кылды.

61. Аннан Солтан Морад хан туды. Ул да шәһре Болгарда илле ел хан булды.

62. Аннан Сәлим хан туды, кырык ел хан булды.

63. Аннан Илһам хан туды, аның заманында Чыңгыз хан чыкты. Барлык ханнар, аңа барып, буйсынганлыкларына ант бирделәр. Халыклар арасында тамга кую, оран һәм кош бирү аннан калды. Җиде тарих китабындагы сүзләр шуның белән бетте, аннан соң «Чыңгыз намә» китабында күргән һәм элекке хәлләрне белгән картлар сүзләрен язачакмын һәм шуңа тәвәккәллим һәм карыйм.

64. Илһам ханнан Габдулла хан туды, илле ел Болгарда хан булды. Аксак Тимер Болгарны харап итте, исеменә – билгесенә карап тормады. Габдулла ханны да үтерде. Аннан ике улы калды, бере – Галимбик, икенчесе – Алтынбик.

65. Безгә баба Галимбик. Бу Галимбик заманында алар нәселеннән ханнар калмады. Бу Галимбик читтә үсте, галим булды. Болгар өлкәсендә Кашан дигән кечерәк шәһәрдә имам һәм мөдәррис булды. Күпме яшәгәне билгеле түгел.

66. Аннан Мирхаҗи туды, ул да шул Кашанда утыз ел торды. Соңыннан ул Кашан шәһәрен ташлап киттеләр, Иске Казанга төштеләр. Анда йөз ел тәмам булгач, ул урынны лаек күрмичә, Казан суының тамагына шәһәр төзеделәр. Ул Иске Казанда бер изге кеше бар, шунда күмелгән, исемен Таҗетдин Хуҗа, диләр. Кем Иске Казаңда була, ваемсыз булмагыз, рухыннан ярдәм сорап, «Фатиха» сүрәсен укып багышлагыз. Без үз максатыбызга килдек. Хәзрәте Мирхаҗи Кашан дигән җирдән күчкән вакытында алар белән бергә күчте, Зәй тамагына килде. Анда Бараҗ ханда имам булып, Зәй тамагында вафат булды.

67. Аннан Кол Гали туды. Харәземгә китеп, анда кырык биш ел мөдәррис булды. Ахырында Ту си дигән патша Хытай йортыннан Ибн Хаҗибне үтерергә дип, гаскәр белән килде. Харәземне җимерде. Ибн Хаҗибне үтерде. Елганың икенче ягына чыгып, калган кешеләр бер шәһәр төзеделәр, исемен Үргәнеч куйдылар. Кол Гали, шул һәлакәттән качып, казах халкына килде, аннан качып, атасы йорты Зәй тамагына килде. Өч елдан соң Субай хан заманында Зәй тамагына бер аждаһа килде. Зәй тамагы халкы, аждаһадан качып, Чирмешән тамагында бер шәһәр төзеделәр, исемен Бүләр куйдылар. Кол Гали әфәнде Аксак Тимер һәлакәтендә йөз ун ел тутырып вафат булды. Ибн Хаҗибның остазы иде.

68. Кол Галидән Мир Гали туды. Ул да, гыйлем алыр өчен, Харәземгә китте. Үргәнечтә утыз ел мөдәррис булды, шунда вафат булды.

69. Аннан Мир Шәриф туды. Дәверендә аннан гали һәм фазыл кеше булмады, ул да Үргәнечтә һәм Хивада алтмыш ел имам һәм мөдәррис булып, вафаты Хивада булды.

70. Аннан Мирсәед туды. Дәверендә аннан белемле һәм фазыл кеше юк иде. Ул белмәгән фән юк иде. һәр беренә бер шәрех язды. Ахыр гомерендә Сәҗавәндә исемле авылда «Фәраиз» китабына шәрех язды. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел.

71. Аннан Нурсәед туды. Бу Нурсәед ханлыкка дәгъва белдерде. Үргәнеч һәм Хиваны буйсындырды, Кунгыратны җимерде. Аларда егерме өч ел хан булды. Соңыннан

кызылбашларның Надир шаһ беренченең ыругыннан гаскәр килеп Нурсәедне үтерделәр. Энҗе мисалындагы хатыннарны һәм кәнизәкләрне алдылар, шәһәрләрен талап киттеләр. Нурсәеднең бер калмык хатыны бар иде, йөкле иде. Хатын, шул һәлакәттән качып, төрекмәнгә килде, бер төрекмәннең хатыны булды. Йөгеннән Сәйдәш атлы ул туды.

72. Бу Сәйдәш зур баһадир, канкоючы булды. Юлбасарлык белән шөгыльләнде. Каракалпак һәм казахлар арасында караклык кылды. Ниһаять, каракалпак ханының кызын урлап качып, Мияс елгасына килде. Әй суының башында бер калкулык бар, ул – Сәйдәш ханның йорты. Бу Сәйдәштән ике ул туды, бере – Тыныш, икенчесе – Куштаймас. Тыныш белән Куштаймас икесе бер анадан иде. Каракалпак ханының кызыннан улкыз калмады. Бу ике улның аналары Әйле ыругыннан иде. Әйле ыругының нәселе бу икедән. Тыныш Алтмыш колак Әйлесе, Куштаймас Комый Әйлесе. Боларны ни өчен шулай аталулары сәбәбен Әстерхан йортында йөргәндә [белдем]. Анда Кубан халкына бардым, бер картта кунак булдым. Сорады: «Син, мулла егет, кайсы як баласы?» Мин әйттем: «Болгардан, иштәк»,– дидем. Карт әйтте: «Кайсы ырунык ы син?» – диде. Мин әйттем: «Әйле ыруы – мин»,– дидем. «Алтмыш колакмы син, я Комыймы син?» – диде. Мин әйттем: «Белмим, әмма атамнан ишеттем, Әйле мин»,– дип. Карт әйтте: «Тынышмы син, яки Куштаймасмы син?» – диде. Мин әйттем: «Тыныш мин». Карт әйтте: «Бабаң Сәйдәш, ауга чыкканда, утыз болан аткан, Тыныш бабаң ауның колакларын урлап яшергән, шуның өчен Тыныш бабаңны Алтмыш колак Әйлесе диләр. Янә Куштаймас бабаң, Сәйдәш белән ауга чыкканда, дүрт кондыз үтергән, аларның берсен урлап комга күмгән, шуның өчен аны һәм аның ыруын Комый Әйлесе, диләр». Мин картның белемлегенә хәйран калдым, йөз мең рәхмәтләр укыдым.

73. Безгә төп баба Тыныш. Бу Тыныштан ике ул туды. Бере – Күди, бере – Кошчы. Бу ике улдан күп халыклар таралды, хисабын Алла белер. Бу заманда хәбәр биргән адәмнәр шушы ике ырудан.

74. Безгә төп баба Күди. Искә алынган бабаларның күпме яшәгәннәре билгеле түгел.

75. Бу Күдидән Җәнбәш туды. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел. Әй елгасында батып үлгән.

76. Бу Җәнбәштән Бәбеш туды. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел. Әй елгасында тереклек иткән.

77. Бәбештән Үлмәс Хаҗи туды. Үлмәс Хаҗи, хаҗга барганда, Әстерхан йортында вафат булган. Туксан яшь булган диләр.

78. Үлмәс Хаҗидан Габдрахман Хаҗи туды. Ул Җәлем суында тереклек иткән. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел.

79. Габдрахман Хаҗидан мулла Җанбай туган. Ул Җанбай мулла Әй буенда Кыйгы дигән елга буенда мөдәррис булган. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел.

80. Җанбай мулладан Котлы Пулатбай туды. Дәверендә ул йортка аннан хуҗа кеше юк иде. Хатәм Тай кебек яшьлегендә хуҗа икән. Ахырында хаҗга барганда вафат булган. Хәзрәт пәйгамбәрне һәр җомга кич төшендә күргән, диләр. Төшеңдә пәйгамбәр белән сөйләшкән, диләр. Котлы Пулат Хуҗадан ике ул туды. Бере – Җыянчура, икенчесе – Җыянгол. Бу ике карендәш дәверләрендә байлыкта һәм акылда тиңдәшсез булганнар.

81. Безгә таба Җыянчура. Гомеренең озынлыгы мәгълүм түгел. Әй буенда йорт тоткан.

82. Җыянчурадан Янтимер туды. Ул да Әй буенда Арша елгасында йорт тоткан. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел.

83. Янтимердән Мәмәткол туды. Ул Арша белән Әй суы арасында йорт тоткан. Гомеренең озынлыгы билгеле түгел.

84. Мәмәтколдан мулла Ялчыгол туды. Әй елгасы белән Арша елгасы арасында Кормаш Елга авылында тереклек иткән. Гомеренең ахырында хаҗга барырга чыккач, мин – улы Таҗетдин белән Әстерхан йортында тордык. Аннан Дагстанга бардык, аннан Дияр-бәкергә бардык. Ул заманда мин, фәкыйрь Таҗетдин, өч яшемдә идем. Диярбәкердә мине бер хуҗа гаиләсенә биреп китте. Хода өчен бу баланы укытучыларга биреп укытсын, дип. Атабыз хаҗга баручы мөселманнар белән хаҗга китте. Мин,

фәкыйрь Таҗетдин, атам мулла Ялчыголны ундүрт ел көттем. Ундүрт ел эчендә мин төрле фәннәргә өйрәндем. Диярбәкердәге тәрбияләүче хуҗам вафат булды. Мин, атамны эзләп, Истанбулга бардым. Истанбулда Ихъя мәчетендә атамны күрдем. Ул хаҗилар белән рабигыл-әүвәлнең ахыргы пәнҗешәмбесендә Истанбулга кергән. Мин җомга көн иртә белән күрдем. Мине күргән заманда улы икәнен белмәде, мин белдем. Миннән сорады: «Кайсы як баласы син?» – дип. Мин әйттем: «Болгардан, иштәк»,– дидем. Шул заман һушы китеп егылды, һушына килде: «Таҗетдин, синме бу?» – диде. Әйттем: «Әйе, синең улың»,– дидем. Янә аһ орып акылы башыннан китте. Истанбулда ике ел калдык. Әхмәд әфәнде тәрбиясендә тордык. Аннан кәрван белән Хаҗи Тарханга килдек. Аннан Мәкәрҗә каласына килдек, анда өч атна тордык. Аннан Казан каласына килдек. Без Казан каласында ике ай тордык. Казаннан кырык сумга ат яллап, ямщиклар белән Троицки каласына чыктык. Казаннан чыккан көнне әткәм: «Башым авырта»,– диде һәм тагын әйтте: «Әй балакаем, Әй елгасын ахыры күрмәмен. Мин дөньядан үткәч, минем каберемне ялгыз ташлап китмә, минем каберем яныннан ерак китмә. Шул урында урнаш, дәрес укыт, сукырайсаң да укыт. Елына ике мәртәбә минем каберемә кил. Бу шартларны җиренә җиткерсәң, мин синнән риза. Әгәр үтәмәсәң, мәңге риза түгел. Моннан башка васыятьләрем дә бар: сандык эчендә дәфтәремне табарсың»,– диде. Кыскасы, без Казан шәһәреннән чыгып бу якка килдек, юлыбыз Мамадыш өязенә туры килде. Урта Сөн дигән авылга җиткәч әҗәл иреште, дөньядан үтте. Алтмыш биш яшендә, рәҗәб аеның беренче җомгасында, Рәгаиб киче, диләр, шул кичтә, тарих һиҗрәтнең 1200 елында, Җүзәнең 24 көнендә, Сарык елында иде. Рухыбызның кыйбласыбыз кебек, безгә газиз җанымыз кебек, тугыз мәртәбә Мәккә белән Мәдинәгә хаҗ кылган Хаҗи хәзрәтебездән аерылдык. Шул мәрхүмнең васыятен үтәп, Кыямәт көнендә күрешергә вәгъдә белән Хаҗ әл-Хәрәмәйн хәзрәтенең яклавыннан өмет итәм. Амин. Аллаһы Тәгалә рухын изге итсен. Әйтәләр: «Чынлап та, Аллаһыныкы, һәм чынлап та, аңа әйләнеп кайтабыз».

85. Хаҗ әл-Хәрәмәйн Ялчыгол хәзрәтеннән бу мескен бәндә, кешеләр аяк астындагы тузан, кара йөзле Таҗетдин туды. Мөдәррис мулла Таҗетдин Зәй суының Кызыл Чапчак авылында укытучы булып тереклек итте. Гомеренең ахырында Ирнә суы буенда Мәлем дигән авылда тереклек итте. Ул Таҗетдин фәкыйрьдән дүрт ул, өч кыз туды. Олы улым Баһаветдин Күперле авылында указлы имам булып тереклек итә. Аннан кечесе – Җәлалетдин. Мәлем авылында атасы янында хезмәт итеп һәм мәзкүр авылда указлы имам булып тереклек итә. Өченчесе – Шәрәфетдин. Ул да Мәлем авылында тереклек итә. Дүртенчесе – Гыйсаметдин. Ул да Мәлем авылында тереклек итә. Олы кызым – Бибинәфисә, аннан кечесе – Газизә, аннан кечесе – Бибиҗәмилә.

*Тәмам.*

ТЕКСТНЫҢ ТРАНСКРИПЦИЯСЕ

## ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЯ

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

Әлһәмдү лилләһи әлләзи халәкал-инсанә галимән билмәнтыйки вәл-бәйани вә җәгаләһүм гокаля ли тәгърифи әхваләһүм минән-нәсәби вәл-бөнйани вә җәгаләл-гададә вәззәвата ли хөкми әмәррәһүм илә йәүмил-кыйами. Сөммә әссаләтү вәс-сәламү галя нәбиил-имами мәга алиһи вә әсхабиһи илә йәүмил-кыйами. Әмма бәгъдү, бу әкаллүл-гыйбади вә әзгафүләхвали шикәстәхал, бәндәи гасый вә җафи Хаҗи Йалчыгол углы Таҗеддин үзенең аслы нәселене Адәм Сафи Аллаһыга васыйль әйдәдем. Тәварих китабларындан караб, иҗтиһаде тамм илән «Чыңгыз намә»гә васыйль әйдәдем. Андан түбәнге бабаларымызны «Чыңгыз намә»дән караб, үземә васыйль әйдәдем. Тарих мең дә ике йөз дә йегерменче йылда, Куй йылында, Сөнбеләнең

www.darul-kutub.com

йегерменче йәүмендә вә маһе гарәбийә Рабигыль-ахыр айында[1] ирде. Бу бәндәи әхкар бу рисаләне төзеб, бу рисаләгә «Тәварихы Болгарийә» аты бирдем. Әмма без нәкыль кыйлдык тәварих китабларының исемләре бонлардыр: «Тәварихы Дәваир[2]» лил-имам Тәбриз әл-Йунани, вә санийан «Тәварихы Фәрһәнг[3]» лил-имам әт-Туси, вә салисән, «Тәварихы һирмез»[4] лил-имам әл-Чәләби, вә рабиган, «Тәварихы Раузат әс-Сафа[5]» лил-имам әл-Чәгый, вә хамисән, «Тәварихы Касфәрани»[6] лил- имам әт-Тәбризи, вә садисән, «Тәварихы Җамасиб» лил-имам әт-Тарзи, вә сабиган, «Тәварихы әл-Чәләби» лил-имам әл-Бәгави, сахибе китабе «Мәсабих»[7], бу кадәр китаблардан караб исбат әйдәдек,

---

1 Тарих мең дә ике йөз дә йегерменче йылда, Куй йылында, Сөнбеләнең йегерменче йөүмендә вә маһе гарөбийө Рабигыль-ахыр айында – милади белән 1805 елның 11 сентябренә, ә рабигыль-ахир ае 1805 елның июнь-июленә туры килә.

2 «Төварихы Дәваир», «Төварихы Һирмез», «Төварихы Касфәрани» – фәндә мондый тарих китапларының булуы мәгълүм түгел. (М. А. Усманов. Татарские исторические источники XVII —XVIII вв. – Казань, 1972. – С. 164.)

3 «Тәварихы Фөрһөш» – фәндә мондый тарих китабы барлыгы мәгълүм түгел. Сүз Һинд галиме Габд әл-Латыйф бине Габдаллаһ әл-Габбаси әл-Гуҗаратиның (1638–1639 елда үлгән) атаклы суфи шагыйрь Җәлалетдин Руминың (1207–1273) «Мәснәвийе Мәгънәви» исемле поэмасындагы авыр аңлаешлы сүзләрдән төзелгән «Ләтайиф эл-Лөгать» сүзлеге турында бара. Бу сүзлекне икенче төрле «Фәрһәнге Мәснәви» («Мәснәви сүзлеге») дип йөрткәннәр.

4 2 нче сылтамага кара.

5 Әл-Чәгыйның «Төварихы Раузат әс-Сафа» китабының тулы исеме: «Раузат өс-Сафа фи сирөтел-әнбия вәл-мөлүк вөл холөфа» – «Пәйгамбәрләр, патшалар һәм хәлифәләр тормыш юлының сафлык бакчасы». Авторы нindidер мифик әл-Чәгый түгел, ә мәшһүр тарихчы Мир Мөхәммәд бине Сәйид Борһан әд-дин Хаванд шаһ бине Кәмал әд-дин Мәхмүд Бәлхи (1432/33–1498). Фәндә ул күбрәк Мирхонд исеме белән танылган.

6 2 нче сылтамага кара.

7 «Төварихы әл-Чөләби» лил имам әл-Бөгави, сахибе китабе «Мөсәвих» – авторның тулы исеме: Әбү Мөхәммәд әл-Хөсәйн бине Мәсгуд әл-Фарра әл-Мәрвәрди әл-Бәгави (1122 елда үлгән). Аның «Мәсабихес-сөннәт» («Сөннәт

www.darul-kutub.com

Чыңгыз хан хоружына дикен. Андан түбән бабаларымызны «Чыңгыз намә»дән караб вә һәм күбне күргән мәшаихләрдән ишетеб, вә бабаларымызның йаза килгән намәләренә йулыгыб, бу рисаләгә йазыб Адәм пәйгамбәре васыйль әйдәдем. Вә һәм мәшаихләрдән ишеттегем вә йаздыкларыны. Үз занымызда хәбәр мәшһүрдер вә һәм халя башкорд таифәләрене һәм бер кабаил вә шогубен шул исемләр берлән йөриләр, йәгъни бабаларымызның исемләре берлән әйтәләр. Бәс, мондаг булса, хәбәре мәшһүр булды вә һәм мөтәватир булды. Вә минһү әтәвәккәлү вә әшһәдү билләһит-тәүфикъ.

1. Әүвәлән Габд әл-Харис вә һүә аслы бәни Адәм, холика мин тораб, вә һүә Адәм Сафи Аллаһ. Әймешләр, Адәмнең гомере бең йыл улды. Аның һөбутындан хәзрәте рәсүлулла ахыр заманина киләнчә дүрт бең өч йөз кырык йыл улды, дийерләр; вә бәгъзиләр биш бең тугыз йөз йитмеш ике йыл, дийерләр; вә бәгъзиләр илле бең йөз утыз йыл, дийерләр. Әмма әсәхху ривайәт, китабе тәфасирнең Әксәрендә йите бең йылдыр, фәтвә боның үзәрендәдер. Нитәкки, «Хәдисе Сахихәйнд»ә[8] килмешдер: «Әд-дөнйа сәбгатү әлаф сәнәт вә өна фи ахири әлфи минһа». Вә калә шәррахе һәзал-хәдис: «Мөддәтү дәүри әл-әнбийа сәбгатү әлаф сәнәт вә әна нәби фи ахири минһа, фәля йәкүнү нәби бәгъдәһү минәл-үлүф». Кәза фи «Фәтхү әл-хәй»[9] шәрхи әл-Бохари вә галәйһи әл-фәтвә, вә галәйһи гамәл әһлүт-тәварих кәма фил-Чөләби вә гайриһи. Гамәлә биһи көтөб минәс-ситтәти тәварих». Адәм галәйһиссәламне Шәйс дәфен

яктырткычлары») исемле хәдисләр җыентыгының Вәли әд-дин бине Габдулла әл-Гомәри әл-хатиб әт-Тәбризи (1340 елда үлгән) тарафыннан үзгәртелгән варианты – «Мишкәт әл-мәсабих» («Яктырткычлар өчен уем») китабы татарлар арасында бик популяр була. Әмма Бәгавинең «Тәварихы әл-Чәләби» исемле китабы фәндә мәгълүм түгел.

[8] «Хәдисе Сахихәйн» – Әбү Габдулла Мөхәммәд әл-Бохари (810 – 870) һәм Мөслим ән-Нишапуриның (817 – 875) «Җамигы Сахих» («Дөрес җыентык») исемле хәдис җыентыклары.

[9] «Фәтхү өл-Хөй» («Фәтхү әл-Бари») – авторы Ибн Хәҗәр әл-Гаска-ләни (1448—1449 елда үлгән).

www.darulkutub.com

әйләде. Каберендә ихтилаф итмешләр: бәгъзиләр Һиндстанда, Сәрәндиб тагында дийерләр, вә бәгъзиләр Мәккәдә, Әбү Кабис тагында, дийерләр. Адәм галәйһисссәлам вафатындан соңра анамыз Хәүва бер йыл хәйат улды, андан соңра Шәйс[10] аны Адәм йанына дәфен әйләде. Вәгъдә туфанда Нух галәйһиссәлам[11] айларны йирдән табутлары илән чыгарыб кимәгә куйды. Туфандай соңра әл-Мөкаддәс йирендә Хәлил әр-Рахмән дәфен әйләде. Шәмди каберләре андадыр.

2. Адәм Сафи Аллаһдан Шәйс тугды. Шәйс бефәтхи әшшин вә сөкүне әл-йа вә бәгъдә саз мөсәлләс. Гыйбрани мәгънәһү «Габд әл-Мәгыйс». Кәза фис«Сөтүр» вәл-«Камус». Шөйс тугыз йөз ун йыл гомер сөрде, һиндстанда дәфен улынды.

3. Андан Унуш тугды. Унуш бе замми әл-һәмзә. Гыйбрани мәгънәһү «Хәжр әл-асм». Кәза фис-«Сөтүр». Биш йөз йегерме йыл гомер сөрде. Кяферендә вә мөселманында ихтилаф вардыр. һиндстанда дәфен улынды.

4. Унушдин[12] Кайнан[13] тугды. Вә әл-Кайнан би фәтхи әлкаф вә сөкүне әл-йа. Сирйани мәгънәһү шәҗәре сәмәр ю заргы зү ләбән. Кәза фид-«Дәваир». Бу Кайнан сигез йыл гомер сөрде, Хак Тәгалә аңа хәлафәт вә кәрамәт вә нөбөввәт бирде. Шәйснең китабы илән гамәл әйләде. Бабасы катында дәфен әйдәде.

5. Андан Мәла[14] тугды. Мәла тугыз йөз йыл гомер сөрде, кяферендә вә мөселманында ихтилаф вар. Һинддә дәфен улынды.

6. Андан Йәздәк тугды. Әмма Йәздәкнең гомере мәгълүм дүгелдер, дине һәм мәгълүм дүгел. Әмма угланлары йөз йегерме улды.

---

[10] Шөйс – Шис, Библиядә искә алынган Сиф пәйгамбәр.

[11] Нух галөйһиссәлам – «Раузат әс-Сафа»да ул Ухнух формасында бирелгән. Коръәндә Идрис пәйгамбәр.

[12] Унуш, Кайнап, Мәла, Нух – «Раузат әс-Сафа»да Адәмнән Нухка хәтле түбәндәге пәйгамбәрләр күрсәтелгән: Шис, Унуш (Ануш), Кайнан, Ухнух (Идрис), Мәһлаеш, Нух галәйһиссәлам (Раузат әс-Сафа. – Бомбей, 1848.- Җилд I.– 15–22 б. Фарсы телендә).

[13] 12 нче сылтамага кара.

[14] 12 нче сылтамага кара.

7. Кече улы Нух[15] галәйһиссәламдер. Идрис аңа дийерләр. Әмма Идрис нәби дөнйада өч йөз алтмыш биш йыл улды, бәгъдә күккә коруҗ әйләде, Йазу йазмак вә кафтан декмәк ю газа итмәк вә дәрес әйтмәк дөнйада андан калды.

8. Идрисдән Әдәбән тугды. Әдәбәннең гомере ике йөз йыл улды. Гыйлем вә парса кемсәнә купды. Гыйрак шәһәрене ул бина әйләде. Гыйракда дәфен улынды.

9. Әдәбәндән Һуд тугды. Әмма Һуд Һуд нәби дүгелдер. Гомере өч йөз йегерме улды. Вә каныкы милләтдә ирдеге мәгълүм дүгелдер. Гыйракда дәфен улынды.

10. Һуддан Мөтәвәшшәх тугды. Әмма Мөтәвәшшәхнең гомере вә милләте мәгълүм дүгелдер. Угланлары зийадә чук ирде. Ике йөз йитмеш йәшенә ирдекдә.

11. [Аннан] Һибәтуллаһ галәйһиссәлам тугды. Нух галәйһиссәлам аңа дийерләр. Күб-күб йыглаганы өчен Нух куйыдды. Әмма Нух галәйһиссәлам мең йыл гомер сөрде. Илле йәшендә пәйгамбәрлек килде. Тугыз йөз илле йыл каумне иманга дөгъвәт әйләде. Күкдән сахаиф иңмәде, Идрис галәйһиссәлам китабы берлән гамәл әйләде. Бәгъдә әт-Туфан йөз йыл гомер сөреб һиндстанда дәфен улынды. Туфандай соңгы гомрене Аллаһы Тәгалә хисабка куймады. Кәза фи «Тәварихы Раузат әс-Сафа». Нухның дүрт утлы булды: Кәнган Туфанда һәлак улды, кяфер ирде. Калган өч угланлары: Сам, Йәфәс, Хам.

12. Әмма Хам Исфаһанда падишаһ улды, гомере алты йөз йегерме йыл улды. [Аның утыз улы булды.] Кече углы Кәйүмирасдыр[16]. Һиндстанда дәфен улынды.

13. Бу Кәйүмирас һәм падишаһ улды. Йиде йөз йыл гомер сөрде. Идрис шәрифендә ирде. Әүвәл кешегә барча йирдә халкга хотбә укыган, падишаһлык идән ул килтерде. Бәлех вә Керман шәһәрләрен ул бина әйләде. Бәлехдә дәфен улынды.

---

15 12 нче сылтамага кара.

16 Көйүмирас, Сийам, Һушөнг, Таһморат – «Раузат әс-Сафа»да – Кәюмарс, Сиямәк, Һушәнг, Таһмурас – легендар Иран шаһлары (Раузат әс-Сафа.- Бомбей, 1848.- Җилд I.– 150–157 б. Фарсы телендә).

www.darulkutub.com

14. Кәйүмирасдан Сийам[17] тугды. Сийамның гомере алты йөз йылдыр, вә каныкы милләт ирдеге мәгълүм дүгелдер. Ниһавәндә дәфен улынды.

15. Сийамдан Һушәнг[18] тугды. Әмма Һушәнг шаһның гомере йиде йөз йыл улды. Вә җиһанда гадел вә дад әйләде. Алтын вә көмеш чыгармак вә тәхет бина әйләмәк андан калды. Сусан шәһәрләрен бина әйләде, вә һәм әфрәнҗ халкының атасыдыр. Сусан вилайәтендә Бажурда вафат әйләде. Әксәре дийаре мәгъриб аның нәселедер.

16. Андан Таһморат[19] атлыг кече утлыдыр. Тәварих китаблары Таһморат нәселеңдәй бәйан идерләр. һушәнгнең гайре углан ларыңдай силсилә Түз вә Хүзлафдер. Әмма Таһморатның гомере дүрт йөз йыл улды, дийерләр. Дийүләре кәндүйә мотыйг әйләмеш ирде. Аты ийөр урмак вә силах дүзмәк андан калды. Мәрев ю Шабур вә Парс шәһәрләрен ул йабды. Мәревдә вафат булды. Углы-кызы чук булды, Каһарман Катил аның утлыдыр. Мәгълүм тәварих китабларында безгә төб ата кече углы Мәрвандан безгә силсилә килмешдер.

17. Әмма Мәрван Бәдәхшанда ике йөз йыл гомер сөрде, падишаһ улды, кяфере вә мөселманы мәгълүм дүгелдер. Бәдәхшанда дәфен улынды.

18. Мәрвандан Әфлайун тугды. Әмма Әфлайунның гомере мәгълүм дүгелдер. Багдад, Басра вә Куфәне ул бина әйләде. Багдадда дәфен улынды. Хәзрәте Муса галәйһиссәлам заманына дикен чук пәйгамбәрләр килделәр, иман килтермәделәр. Әмма бу Әфлайун хәзрәте Җиржис[20] заманына дикен атәшпәрәстлек әйләделәр. Әмма бу Әфлайун мәҗмәгыльбәхрегә сәфәр әйләдегендә дуст улыб хәзрәте Дауда әсхаб улды. Багдадда дәфен улынды.

---

17 16 нче сылтамага кара.

18 16 нче сылтамага кара.

19 16 нче сылтамага кара.

20 Христианнарда Изге Георгий.

www.darulkutub.com

19. Андан Әкратис тугды. Бу Әкратисның гомере мәгълүм дүгелдер. Хәзрәте Йушыгга иман килтермеш. Димашкны ул бина әйләде. Анда дәфен улынды.

20. Андан Карамуш тугды. Әмма бу Карамуш җаду вә сихер гыйлемене камил белер ирмеш, гавпәрәстләр динендә Хәбәш вилайәтендә ике йөз алтмыш биш йыл гомер идеб шаһ улды.

21. Карамушдан Әфламун тугды. Хәзрәте әл-Йәсигъ галәйһиссәлам заманында аның әсхабындан улыб, Мәгъриб вә Кум вилайәтләрендә шаһ улды. Гомеренең мөддәте мәгълүм дүгелдер.

22. Әфламундан Кинанә тугды. Бу Кинанә йавлак йавыз кяфер иде. Чин вилайәтендә җенләр вә дийүләр илән йар улыб, Чин вилайәтене алыб йөз утыз йыл гомер сөрде, шаһ улыб анда дәфен улынды.

23. Бу Кинанәдан Әфратим тугды. Әфратим хәзрәте Сөләйман заманында аңа әсхаб улыб Коддүс, вә Фәләстыйн вилайәтенә килде. Гомеренең мөддәте мәгълүм дүгелдер.

24. Әфратимдан Тәһлайеш тугды. Сөләйман галәйһиссәлам заманындан соң бу Тәһлайеш хунриз вә каттагы тарикъ улыб йөз алтмыш йыл гомер сөреб, сәгпәрәст улыб, Шираз вилайәтендә дәфен улынды.

25. Андан Мәһлайеш тугды. Бу Мәһлайеш гомеренең әүвәлендә сәгпәрәст ирде. Андан хәлас улыб хәзрәте Илйас галәйһиссәламгә мөселман илән Харәзем вилайәтендә йөз алтмыш йыл гомер сөрде. Бәгалбәк диб Мәһлайеш кауменә әйтерләр.

26. Андан Әмкәш тугды. Йөз туксан йыл гомер сөреб, Харәземдә дәфен улынды.

27. Андан Тагланыш тугды. Бу Тагланыш Төркестанны бина әйләде. Каберләре астанә купармак, угланлара сабак үгрәтмәк вә баҗ алмак андан калды. Йөз дә өч йыл гомер сөреб Төркестанда вафат булды. Әмма дине Муса галәйһиссәлам динендә, йәһүди ирде. Әлкөллү мәнкул минәт-тәварихил-хәмсә әлләти вәкагнә фи әүвәлир-рабигый ләмма йә'ти бәйанәһү. Вә калә фил-Касфәрана ән Әфләх кад вулидә мин Тагланыш, йәгъни Тагланышдан Әфләх тугды.

28. Бу Әфләх кыргыз халкының асылы вә бонйанычдыр. Моргадан моргайә күчеб йөрмәк андан калды. Йөз ун йыл гомер сөрде. Сырдәрйасында гарык улды. Кяфере вә мөселманы мәгълүм дүгелдер.

29. Андан Мард тугды. Бу Мард төрекмән халкының атасыдыр. Андан чук угыллар тугды. Олуг углы

30. Төрекмән, андан кечесе Конгырат, андан кече Бөрҗән, андан кече Мангыт, андан кече Кәрҗе, андан кече Кыпчак, андан кечесе Йөрмәте, андан Кече Кара Калпак. Бу заманларда халаикъларның аймагы бонларның нәселендәндер. Мардның гомере вә милләте мәгълүм дүгелдер.

31. Төрекмәндәй Кинҗә тугды. Әмма бу Кинҗә Гайсә динендә иде. Бохараны ул бина әйләде. Гомере туксан йылдыр. Бохарада дәфен улынды. Бу Кинҗәдән чук угланлар тугды. Олуг углы Татардыр, андан кечесе Мишәрдер, андан кече Иштәкдер, андан кечесе Нугайдыр. Бонлар һәр бере шаһ улыб әтрафе галәмдә урдалар бина әйләделәр, халаикъларның аймагы айларның нәселеңдәй хәбәр бирмәкдер.

32. Бу Кинҗәнең угланларындан безгә нәсел баба Иштәкдер. Әмма бу Иштәк камил ир кубды, Кәгъбә йә варды, чук-чук тәвәләр корбан әйләде. Тәүрат вә Инҗилне камил белер ирде. Гыйлемлекдә нәзире йук ирде. Бу Иштәкдән чук угланлар улды. Төб йорты Гаму дәрйасында ирде. ОлТамйан, андан кечесе Үсүргөндер, андан кечесе Күбләк, андан кече Бәкәтун, андан кечесе Сарт, андан кечесе Торнакол, андан кечесе Туплас, андан кече Дәвандыр. Бу халаикъларның хәбәр бирмәге айларның нәселендәндер.

33. Әмма бу Иштәк угланларындан безгә баба Бәкәтундыр. Әмма бу Бәкәтун гайәт үфкәлү адәм ирде. Йирене ташлаб биляде Шималь тарафына барыб Мийач дәрйасына килде. Анда мәкам әйләб туксан йыл гомер әйләде. Аның угланлары чук улды. Олуг углы Әйледер, андан кечесе Йөрми, андан кечесе Байлар, андан кечесе Байкы, андан кечесе Ирәкитә, андан кечесе Салчут. Бонлар һәрберсе шаһ улыб әтрафе галәмә йәйелделәр. Халаикъларның хәбәр бирмәге анлар нәселендәндер. Әмма Бәкәтун насрани динендә иде.

34. Безгә төб баба олуг углы Әйледер. Әмма Әйле төб атасы йортында калмышдыр. Илле йыл шаһ улыб Мийач дәрйасында туксан тугыз йыл гомер сөреб, вафаты анда улды.

35. Әйледән Нариман тугды. Әмма бу Нариман дөнйаны сәйәхәт әйләде. Йунан вилайәтенә тәгаллөм өчен китде. Чук рузгярны гизде, гыйльме мәгъкулатның остады улды. Гыйльме хикмәтдә йегерме дүрт китаб тәсниф әйләде. Насрани динендә касис ирде. Заманында мәлике әгъзам улыб Сәмәркандны бина әйләде. Йөз йыл гомер сөрде, вә таш кальгалар бина әйләде. Бу заманда һәм әсәре вардыгр, «бинайе кыйәфәт» дийерләр.

36. Наримандан Касур шаһ тугды. Ул һәм Сәмәрканд җәмилдә туксан йыл гомер сөреб, Гайсә динендә вафат булды.

37. Андан Сократ хәким тугды. Бу Сократ Йунан вилайәтенә килде, ахырында Искәндәр руми[21] алендә хәким улыб абе хәйат варлыгына йул күстәреб шималь җанибенә килделәр. Бер шәһәр бина әйләделәр, адыны Болгар куйдылар. Болгар Йунан лөгатенчә хушбуй димәк вә дәхи агачлы вә дәрйалы димәкдер. Вә дәрйасының исеме Болгардыр. Андан касыр бу заманда Булгы дәйү әйтерләр. Болгардан Булгы тәгьриф улынмышдыр. Кәма фиһим фи «Фәрһәнг намә»[22]. Ул заманда Сократ хәким

[21] Искәндәр руми – Александр Македонский.

[22] «Фөрһөнг намә» – югарыда искә алынган «Фәрһәнге Мәснәви» сүзлегендәге «Болгар» сүзенә аңлатманың күчермәсе татарлар арасында фарсы телендә дә, татар телендә дә киң таралыш тапкан була. Танылган татар шагыйре һәм галиме Габдерәхим Утыз Имәни (1754 – 1834), сүзлекнең Ибраһим Дәһләви тарафыннан кыскартылган вариантын – «Мохтасар Ләтайиф әл-лөгать лил-Мәснәви»не эшкәртеп, аның яңа вариантын төзи. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульъязмалар бүлегендә сүзлекнең Утыз Имәни тарафыннан төзелгән бер нөсхәсе саклана. Түбәндә шул әсәрдән «Болгар» турындагы өзекнең фарсы теленнән татарчага тәрҗемәсен тулысынча китерәбез: «Болгар – «Караңгылык» иленнән ерак булмаган бер шәһәр. Зөлкарнаен (Александр Македонский. – **С. Г.**), «тереклек» суын эзләп, «Караңгылык» иленә килгәндә, үзенең чатырын «Бунгар»да куйган (Бунгар – фарсыча мәгарә төбе дигәнне аңлата.– **С. Г.**). «Караңгылык» иленнән кайткач, ул «Бунгар»дан китә. Бу «Бунгар»га төрле яктан кешеләр җыелган, Зөлкарнәен юлдашларының кайберләре дә юлдан арып шунда торып калганнар.

Болгардан бер кыз никах әйләде вә [И]скәндәр шаһ илә Болгарда тугыз ай тормышлардыр. Андан соң дийаре Зольматә китмешләр. Дийаре Зольматдән чыктыкдыкларындан отры Сократ хәким дийаре Зольматдә вафат булды. Әмма Сократ хәкимнең

38. Мәзкүр кыздан бер угыл тугды, адыны Гөфтар куйдылар. Әмма Сократ хәкимнең гомеренең мөддәте мәгълүм дүгелдер. Бу Гөфтар Болгарда шаһ улды, гомере туксан йыл димешләр. Атәшпәрәстлек улдылар. Чук рузгар буилә калдылар.

39. Андан Айдар тугды, Ак диңгездә Ташкүперне ул бина кылды. Бигайәт гадел шаһ улды. Дине вә гомере мәгълүм дүгелдер.

40. Андан һәрмәз тугды. Бу һәм Ташкүпердә шаһ улды. Дине һәм гомере мәгълүм дүгелдер.

41. Андан Алмас тугды. Ташкүпердә улды, мөддәте гомере мәгълүм дүгелдер.

42. Алмасдан Мирһашим тугды, ул һәм Ак диңгез кенарендә бер шәһәр бина кылды, адыны Әдернө куйды. Солтан улмак исемене әүвәл ул бирде. Туксан йыл гомере улды. Кодусә вардыкда, Инҗиле Гайсәне күреб иман китерде.

43. Андан Бабәк тугды. Ул һәм Салийанда солтан улыб йитмеш сигез йыл гомер сөрде. Салийанда дәфен улынды.

44. Андан Корнакый тугды, йөз туксан йыл гомере улды. Андан чук углан лар тугды. Кеме Кырымда, кеме Кытайда, Гыйракда. һәр бере солтан улдылар.

---

Әкренләп ул зур шәһәргә әйләнгән. Соңыннан «н» хәрефен «л» га үзгәртеп «Болгар» дип әйтә башлаганнар. Болгар – шулай ук хуш исле күн исеме. Бу илдә бик салкын, анда попугайлар яшәми. Бу илдә өч зур шәһәр бар: беренчесе – Болгар, икенчесе – Сувар, ә өченчесе – Исәнбәр. Болгарлылар тирәсендә барысы да кяфер төркиләр».

Текст ахырында Утыз Имәнинең искәрмәсе дә бар: «Исәнбәр – Идел елгасындагы рус шәһәре. «Хәмзә»сен төшереп «Синбир» дип әйтәләр. Күп сүзлекләрдә хата белән язалар: кайберләрендә «Иск», кайберләрендә «Эсель» һ. б. Дөресе без әйткәнчә булыр» (Гилязутдинов С. М. Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства. – Казань, 2002. – С. 235.). Текстның русча бер варианты М. Госманов тарафыннан да бастырылган (Усманов, 1972:162).

www.darul-kutub.com

45. Безгә баба кече углы Даймасдыр. Даймас вилайәте шимальдә Содум атлыг шәһәр бина әйләде. Әмма Корнакыйның дәфен улындыгы йире мәгълүм дүгелдер. һәм Даймасның гомере мәгълүм дүгелдер. Бу заманда ул Содумны Алабуга дийерләр, кечерәк кальгадыр. Ул Даймас солтандай ике углы тугды, олуг углы Уладимир вә икенчесе Мәскәүдер.

46. Безгә баба Мәскәүдер. Мәскәү илә Уладимирга Даймас ике шәһәр бина әйләде, беренә Мәскәү аты бирде, беренә Уладимир аты бирде. Мөддәте гомере мәгълүм дүгелдер.

47. Мәскәүдән Тагыйун тугды, насрани ирде. Алтмыш йыл гомер сөрде. Мәскәүдә солтан улды, анда вафаты булды.

48. Тагыйундан Митрафан тугды. һирадка вардыкында харамилар үлтерделәр, мөддәте гомере мәгълүм дүгелдер.

49. Андан Йаков тугды. Бу Йаков Ак диңгезә варды, бигайәт галим кубды, Йагъкубийә аңа дийерләр. Көтөбе сәласне йад алды. Алтмыш биш йәшендә вафат булды, дийерләр. Бәдәхшанда дәфен улынды, дийерләр.

50. Андан Мард тугды. Бу Мард әүвәл гомерендә Хәшвар илә Бохара арасында каттагыт-тарикъ улды, ахырында Бохарайа килеб, йәһүд динендә сиксән йыл гомер сөреб, Бохарада дәфен улынды.

51. Марддан Әмлан йәһүд тугды. Бу Әмланның углы-кызы чук улды. Кечек углы Тимерҗан безгә бабадыр. Мардның мөддәте гомере мәгълүм дүгелдер.

52. Бу Тимерҗан Төркестанда солтан улды. Туксан алты йәшендә вафат булды. Гайсә динендә ирде.

53. Андан Бакыйҗан тугды. Бу Бакыйҗан Болгар халкына җәнг илән килде, Болгарның шаһыны хараб әйләде, Гайсә диненә дәгъвәт әйләб. Йөз йыл Болгарда сакин улды, вафаты һәм анда улды. Адәм Сафи Аллаһдан Бакыйҗане дикен илле ике бабалардыр. Көллесен тәварихы «Раузат әс-Сафа»дан фарси гыйбарәтендән төрки теленә тәрҗемә кылдым, һәм бондан түбәнге бабалар тәрҗемә кылынмышдыр китабе «Тәварихы Җамасиб» вә «Тәварихы Чәләби»дән Чыңгыз хан хоруҗына дикен. Гафләт улынмайә, вә калә фи «Тәварихи Җамасиб» вә

www.darulkutub.com

«Тәварихиш-Шамийә» әл-гарабийә: «Кад вулидә мин Бакыйҗан әл-Фарси Шәмсүн эл-Габид», интәһә.

54. Чунки бу Шәмсун балигъ улдыкдан отыры Кодусә[23] килде. Кодусә Инҗилне укыды, остаде маһир булды. Андан Куфәйә[24] килде. Анда иман килтермәйән гарәбләрне иманә дәгъвәт әйләде. Ахыйрел-әмер Куфәдә бәк улды, йөз ун йыл гомер сөреб Куфәдә вафат булды.

55. Андан Науширван Гадел[25] тугды. Науширван Гадел заманында вилайәте гарәб җаһилийәт иде. «Зәбур»дан вә «Тәүрат»дан вә «Инҗил»дән хәбәр бирдеге кемсәнә вилайәте гарәб дә калмады. Балигъ улдыгындан отыры ул алмаган шәһәр калмады. Төркестан хәддендән мәгърибе дикен аның зире хөкемендә улды. Сәрвәре әнбийа саллааллаһы галәйһи вә сәлләм аның заманында килде. «Әнә вулидтү фи замани Солтан әл-Гадел»[26] дидегендән Науширван мораддыр. Кырык сигез йыл гадел вә дад илә Йәмәндә шаһ улды, вафаты һәм анда улды. Андан ике углы тугды. Олуг углы Керан, кече углы Бездан. Безләр Бездан ыругымыз. Керан хәзрәте Имам Әгъзам ыругыдыр. Мәсәлән: Керан углы Хордан, Хордан углы Шәһәр, Шәһәр углы Мирәз, Мирәз углы Һәрмәз, Һәрмәз углы Сабит, Сабит углы Ногман вә һүә әл-Имам әл-Әгъзам.

56. Безләр килдек үз бабамыз Бездан. Бездан балигъ улдыкдан кизин шөһәрдән-шәһәрә йөрмәк һәвесене әйләде, та Чин вә Мачин вә Харәзем вә Һиндстан вилайәтләрене тәй кыйлыб Хытай йортына килде. Хытай шаһының кызына гашыйк улды. Муг диненә керде. Хытай шаһының кызыны алды. Кыз атасы үлдегендән кизин Хытай йортына шаһ улыб утыз алты

---

[23] Кодус – Иерусалим.

[24] Куфә – Көньяк Гыйрактагы шәһәр.

[25] Науширван Гадел – Иран шаһы Хөсрәү I (537 – 579). Көнчыгыш халыкларының легендаларында Әнуширван Гадел исеме белән мәшһүр.

[26] «Әнә вулидтү фи замани Солтан әл-Гадел» («Мин Солтан Гадел заманында тудым») – Мөхәммәд галәйһиссәламгә нисбәт ителгән хәдис. Традиция буенча Мөхәммәд пәйгамбәр Иран шаһы Хөсрәү I – Әнуширван Гадел – заманында 570 елда туган дип исәпләнә.

www.darul-kutub.com

йыл тәхет биләде. Хытай шаһының бер карендәше Шәбстан вилайәтендән гаскәр илә килеб Бездандан тәхетне алды. Безданны һәлак әйләде.

57. Андан бер углы калды, атыны Тукый куйдылар. Атасындан дүрт йәшендә калды. Тукый балигъ улдыкдан кизин һич бер шаһ аны урынга ултырдмадылар. Гакыйбәт башыны алыб Хытай Йортыйдан китде. Качкан колларны вә бикярларны, угрыларны җәмыг идеб кәндүенә гаскәр ирүнде. Болгар хәдденә килделәр. Болгар шәһәрен алдылар. Тукый кәндүенә лаек бер исем ирүнде, «хан» дәйү. Хан димәкләре Тукыйдан калгандыр. Төрки Җәмәгате шаһларына «хан» дийерләр.уг углы  Хәзрәте Рәсүл саллаллаһы галәйһи вә сәлләм Тукый хан заманында әс-хабендән өч кемсәнәне ихтыйар идеб узамыш. Аның дәверендә Болгар халкы мәҗүсиләр ирмеш. Ул заманда Болгарның ханәләре биш йөз йегерме димешләр. Булгы дидеге Идел дәрйасы Болгарның астындан агар ирмеш. Бараҗ хандан соң илле йылдин кизин Мир Тимер хәзрәтләре Болгарны хараб әйләде. Андан кизин Булгы иделе андан күчеб мәгъриб тарафындай китде.

58. Заманы нөбөввәтдә Тукый ханның углы Айдар хан тәхетә кичде. Тарих хиҗрәтнең тугызынчы йылында Айдар хан тәхетә кичде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әсхабләрендән өч кемсәнәне ихтыйар идеб дәгъвәт өчен Болгара йибәрелмеш. Ул әсхабләрнең берсе Габдрахман бине Зөбәйер, икенчесе Хантал бине Рабигъ, өченчесе Зөбәйер бине Җәгъдә[27]. Вәгъдә Пәйгамбәр галәйһиссәлам бу өч әсхабене йибәрмешдә димешки: «Бән сезләрә өч нәрсә вирдем, сезләрдән кәрамәт кылдыкларында бу өч нәрсәдән истимдад идәсезләр». Бере дөват, Зөбөйерә вирде, вә бере тайак Хантала вирде, вә бере дәстар Габдрахманга вирде. Чун бонлар Болгара килделәр, үзләрен табиб сурәтендә кылыб, табибчылык кылыр ирделәр. Нә кадәр хәстә-сүкәл бар ирсә барчалары шифа табар ирделәр. Әлкыйсса,

[27] Габдрахман бине Зөбәйер, Хантал бине Рабигъ, Зөбөйер бине Җәгъдә – Ш. Мәрҗани әйтүенчә, Мөхәммәд галәйһиссәлам сәхабәләре арасында андый кешеләр булмаган (Мәрҗани, 1897:57).

бер көн Айдар ханның кызына гыйлләте фалиҗ пәйда булды. Нә кадәр табиблардан шифа эстәде, сиххәт тапмады, гаҗиз калды. Бер көн вәзирләре эчендән Бураҗ атлыг вәзире бар иде, әйтде: «Әй, ханым, йәшең озак улсын, безнең шәһәр эчендә өч гарәб бардыр, табиблыкда нәзирләре йукдыр, бу кызның зәхмәтенә дәрман табарлар, әмма динләре безчәләйен дүгелдер», – диде. Чун вәзир бу сүзне әйткәндәй отры, хан бойырды, гарәбләрне өндәйделәр. Әлкыйсса, сәхабәләр килделәр, сәлам бирделәр. Хантал бине Рабигъ хәзрәтләре төрки вә рум теленә бинәзир остад иде, вә һәм хафизе Кәламулла ирде. Хан әйде: «Әй, гарәбләр, кандин килерсезләр?». Хантал әйде: «Мәдинәдән килермезләр». Хан өйде: «Нә эзләйүрсезләр?» Хантал әйде: «Табиблык кылырмызлар». Хан әйде: «Бәнем бер кызым бардыр, йиде йылдан бире хәстәдер, аңа дәрман табармысызлар?» Хантал әйде: «Зәхмәтенә күрәлик». Чун зәхмәтене күрделәр, өйделәр: «Бу фалиҗ зәхмәтедер, боңа шәҗәрәи сарбан йафрагы кирәкдер», – тиде. Хан әйде: «Сарбан кайу агачдыр? Хантал әйде: «Кайын йыгачыдыр». Хан әйде: «Издә ул йыгач чукдыр». Чун каен йафрагыны китерделәр, Хантал әйде: «Бу иске кайын йафрагыдыр, безләргә агачдан йаңа алган кирәкдер», – диде. Хан әйде: «Кыш көнендә аны кайдан тапмак кирәк?» – диде. Хантал әйде: «Иншаллаһы Тәгалә аны безләр табармызлар, мәгәр шул шарт илән, безнең динемезгә иман килтерсәң», – диде. Хан әйде: «Әгәр йаңа кайын йафрагы тапсаңыз вә кызым сиххәт улырса ислам диненә керермен»,– диде. Әлкыйсса, бу әсхаблар пәйгамбәр галәйһиссәлам биргән дәватны йиргә куйды, вә гасаны дәват эченә кадаб куйдылар, хәзрәте Габдрахман бине Зөбәйер Пәйгамбәремез биргән дәстарын кийеб ике рөкәгать намаз кылды, бу ике сәхабә «амин», диделәр. Байагы тайак үсеб бер кечерәк чавыл булды, хан өйенең тамына ирешде, бодакланыб йафракланды. Җыеб дүркә баглаб кызны хәммамә кертеб чабдырдылар, филхаль кыз сиххәт булыб өйенә килде. Хан бу хальне күреб иман килтерде. Андан Бураҗ вәзир, андан гайре вәзирләр вә калан шәһәр халкы барчалары иман килтерделәр. Мәсҗед җамигъ бина әйдәделәр. Хәзрәте

www.darul-kutub.com

Зөбәйер бине Җәгъдә имам булыб Пәйгамбәремез вирдеге тайакга тайаныб хотбә укыды. Ул заманда тарих һиҗрәт 12 нче йылында Куй йылы бөрҗе Хутның 26 нчы йәүмендә, Рамазан мөхәррәмнең 12 нче йәүмендә[28] сәхабәләр Болгар халкыны мөселман әйләделәр. Ул өч әсхаб Болгарда ун йыл калдылар, мәдрәсә бина кылдылар, халаикъга тәгълим бирделәр. Андан кизин Габдрахман бине Зөбәйер вә Зәбәйер бине Җәгъдә – һәр икесе Мәдинәйә китделәр. Хантал Болгарда калды, байагы хәстәдән терелдеге кызны никах әйләде. Рузгардан соң Хантал бине Рабигъ вафат булды. Андан Мөхәммәд Әмин хан тугды. Әлкөлле мәнкуль минәт-«Тәварихы һирмез» лил-имам Чәләби.

59. Айдар хандан Сәйид хан тугды. Әмма Айдар хан илә Сәйид хан һәр икесе Болгарда йөз йыл ханлык кылдылар.

60. Сәйид хандан Әмир хан тугды, ул һәм илле йыл ханлык кылды.

61. Андан Солтан Морад хан тугды. Ул һәм шәһре Болгарда илле йыл хан улды.

62. Андан Сәлим хан тугды, кырык йыл хан улды.

63. Андан Илһам хан тугды, аның заманында Чыңгыз хан хоруҗ әйләде. Барча ханлар аңа барыб бәйгать бирде. Халык ара тамга салдырмак оран бирмәк, кош бирмәк андан калды. Тәммәт әкъвале тәварихы китабе әс-сәбгатә вә бәгъдәһү әкулү ма раәйтүһү фи рисаләти Чыңгыз вә мин әкъвали мәшаихел-кибарес-син галим бил-халатил-мазыйати вә биһит-тәвәккәл фә нәзар.

64. Илһам хандан Габдулла хан тугды, илле йыл Болгарда хан улды. Аксак Тимер Болгарны хараб әйләде, нам-нишан куймады. Габдулла ханны һәм үлтерде. Андан ике угыл калды, бере Галимбик вә бере Алтынбик.

65. Безгә баба Галимбиедер. Бу Галимбик заманында анлар нәселеңдәй ханлык киселде. Бу Галимбик горбәтлекдә үсде, галим кубды. Болгар нахийәсендә Кашан тидеге кечерәк шәһәрдә имам вә мөдәррис улды. Мөддәте гомере мәгълүм дүгелдер.

---

[28] 12 нче йылында Куй йылы берҗе Хутның 26 нчы йөүмендә, Рамазан мөхәррәмнең 12 нче йәүмендә – милади белән 633 елның 21 ноябре.

www.darul-kutub.com

66. Андан Мирхаҗи тугды, ул һәм шул Кашанда утыз йыл торды. Вәгъдә ул Кашан шәһәрен ташлаб килделәр, Иске Казанга дөшделәр. Анда йөз йыл тәмам улгач ул урынны лаек күрмәйүб Казан суының тамагына шәһәр бина әйләделәр. Ул Иске Казанда сахибе кәрамәт вардыр, анда дәфен улынмышдыр, исеме Таҗеддин Хуҗа дийерләр. һәр кем ирсә Иске Казандай үтеб гафил улмайасызлар, рухындан истиганәт вә истимдад идеб «Фатиха» укыб багышлайа. Без ул максудымыза килдек. Хәзрәте Мирхаҗи Кашан тидеге йирдән күчдеге вакытында анлар илән бергә күчде, Зәй тамагына килде. Анда Бараҗ ханда имам улыб Зәй тамагында вафат булды.

67. Андан Кол Гали тугды. Харәземә китеб анда кырык биш йыл мөдәррис улыб ахыры Туси дидеге хаким Хытай Йортыйдан гаскәр илән Ибн Хаҗибне үлтермәк өчен килде. Харәземне хараб әйләде, Ибн Хаҗибне үлтерде, дәрйаның икенче җанибенә чыгыб калдыгы кемсәнәләр бер шәһәр бина әйләделәр, атыны Үргәнеч куйдылар. Кол Гали шул мәһләкәдә качыб кыргыз халкына килде, андан качыб атасы йорты Зәй тамагына килде. Өч йыл мөрурындан кизин Зәй тамагына Субай хан заманында бер аждаһа белгерде, Зәй тамагы халкы аждаһадан качыб Чирмешән тамагына бер шәһәр бина әйләделәр, адыны Бүләр куйдылар. Кол Гали әфәнде Аксак Тимер мәһләкәсендә, тәмам йөз ун йыл гомерендә вафат улды. Ибн Хаҗибнең остады ирде.

68. Кол Галидин Мир Гали тугды. Ул һәм тәхсыйле гыйлем өчен Харәземә китде. Үргәнечдә утыз йыл мөдәррис улды, вафаты анда улды.

69. Андан Мир Шәриф тугды. Дәверендә андан галим вә фазыйль кем-сәнә улмады, ул һәм Үргәнечдә вә Хивада алтмыш йыл имам вә мөдәррис улыб вафаты Хивада улды.

70. Андан Мирсәйид тугды. Дәверендә андан гыйлем вә фазыл кемсәнә йук ирде, һич бер фән калмады, илля аны белде, һәр беренә бер хашийа итде. Ахыр гомерендә Сәҗавәндә дидеге күйдә «Фәраиз»[29] мәтене шәрех итде. Гомеренең мөддәте мәгълүм дүгелдер.

[29] «Фәраиз» – варислык буенча киң таралган мөселман юриспруденциясе китабы. Авторы – Сираҗетдин Әбү Таһир Мөхәммәд бине Габдер-рөшид әс-Сәҗәвәнди (XII гасыр).

www.darul-kutub.com

71. Андан Нурсәйид тугды. Бу Нурсәйид ханлык дәгъвәсене кылды. Үргәнеч вә Хива зире хөкемендә әйләде, вә Кунгыратны хараб әйләде. Анлара йегерме өч йыл ханлык әйләде, ахыр кызылбашдан Надир шаһ әүвәленең[30] оругындан гаскәр илә Нурсәйидне үлтерделәр. Кәәмсале лүэ-лү хаватин вә кәнизәкләрене алдылар, шәһәрләрен талаб китделәр. Нурсәйиднең бер калмак хатыны вар иде, хамилә иде. Хатын шул мәһләкәдән качыб төрекмәне килде, бер төрекмәннең хатыны улды. Хәмелендән Сәйдәш атлыг угыл тугды.

72. Бу Сәйдәш газыйм баһадир, хунриз улды. Харамилыклар әйләде. Каракалпак вә кыргыз арасында угрылык кылыр ирде. Ахырыл – әмер каракалпак ханының кызын угырлаб качыб, Мийач дәрйасына килде, Әй суының башында бер түбә бардыр, ул Сәйдәш ханның йортыдыр. Бу Сөйдәшдән 1 ике угыл тугды, бере – Тыныш, вә бере – Куштаймас. Тыныш илән Куштаймас – икесе бер анадан иде. Каракалпак ханының кызыйдан угыл-кыз калмады. Бу ике угылның аналары Әйле ыругыңдай ирде. Әйле ыругының нәселе бу икедәндер.

Тыныш Алтмыш колак Әйлеседер. Куштаймас Комый Әйлеседер. Бонларның вәҗһе тәсмийәләрене Әчтерхан йортында йөрдегемдә Кубан халкына бардым, бер картда кунак булдым. Сүәл кылды: «Син, мулла егет, нә йирлек фәрзәндсең?» Бән әйтдем: «Болгарлык иштәкмен»,– тидем. Карый әйде: «Каныкы ыругы син?» – тиде. Бән әйдем: «Әйле ыругы мән»,– тидем. «Алтмыш колакмусән? – тиде.– Йә Комыймы сән?» – тиде. Бән әйдем: «Белмәзем, әмма атамдай ишетдем, Әйлемән, дәйү». Карый әйде: «Тынышму сән, йәки Куштаймасмусән?» – тиде. Бән әйтдем: «Тыныш мән». Карый әйде: «Бабаң Сәйдәш ауга чыкмышда утыз болан атмыш, ауның колакларын угырлаб бабаң Тыныш йәшермеш, шул җәһәтлән Тыныш бабаңны Алтмыш колак Әйлесе дийерләр. Йәнә Куштаймас бабаң Сәйдәш илән ауга чыкмышларындан түрт кондыз үлтермеш, ауның берсене угырлаб комга күммеш, шуның өчен аны вә һәм аның ыру-

[30] Надир шаһ әүвәл – Иран хөкемдары Надиршаһ. 1747 елда һәлак була.

гыны Комый Әйлесе дийерләр, имеш»,– тиде. Бән карыйның даналыгына хәйран калдым, сәд Һәзар афәринләр укыдым.

73. Безгә төб баба Тынышдыр. Бу Тынышдан ике угыл тугды. Бере Күди, бере Кошчы. Бу ике угылдан күб халаикълар йәйелде, хисабын Алла белер. Бу заманда адәмләрнең хәбәр бирмәге бу ике ыругдандыр.

74. Безгә төп баба Күдидер. Мәзкүр бәйан улынмыш бабаларның мөддәте гомерләре мәгълүм дүгелдер.

75. Бу Күдидән Җәнбәш тугды. Гомеренең мөддәте мәгълүм дүгелдер. Әмма Әй дәрйасында гарык булыб үлгәндер.

76. Бу Җәнбәшдән Бәбеш тугмышдыр. Мөддәте гомере мәгълүм дүгелдер. Әй дәрйасында тереклек әйләмеш.

77. Бәбешдән Үлмәс Хаҗи тугмышдыр. Үлмәс Хаҗи хаҗ китдегендә Әчтерхан йортында вафат улмышдыр. Гомере туксан йыл димешләр.

78. Үлмәс Хаҗидан Габдрахман Хаҗи тугмыш. Ул Җәлем суында тереклек әйләмеш, гомеренең мөддәте мәгълүм дүгелдер.

79. Габдрахман Хаҗидан мулла Җанбай тугмыш. Ул Җанбай мулла Әй буйында Кыйгы дидеге дәрйа буйында мөдәррис булмышдыр. Гомеренең мөддәте мәгълүм дүгелдер.

80. Җанбай мулладан Котлы Пулатбай тугмышдыр. Дәверендә ул йортда андан хуҗа кемсәнә улмамыш. Хатәм Тай кеби җәванмәрд хуҗа иркән. Ахыр хаҗ таләбендә вафат улмыш. Хәзрәте пәйгамбәрне һәр җомга кичәсендә дөшендә күрсә кирәк. Сүзләрне дөшендә пәйгамбәрдән сүәл кылса кирәк. Котлы Пулат Хуҗадан ике угыл тугмыш. Бере – Җыйанчура вә бере – Җыйангол. Бу ике карендәш дәверләрендә байлыкда вә гакыл әһле улмакда Нәзирләре йукдыр.

81. Безгә баба Җыйанчурадыр, мөддәте гомерләре мәгълүм дүгелдер. Әй буйында мәкам итмешләрдер.

82. Җыйанчурадин Йантимер тугмышдыр. Ул һәм Әй буйында Арша дәрйасында мәкам тотмышдыр. Мөддәте гомере мәгълүм дүгелдер.

83. Йантимердән Мәмәткол тугмышдыр. Ул Арша берлән Әй суы арасында мәкам тотмышлардыр. Мөддәте гомере мәгълүм дүгелдер.

84. Мәмәтколдин мулла Йалчыгол тугмышдыр. Әй дәрйасы илән Арша дәрйасы арасында Кормаш йылга авылында тереклек әйләмеш. Гомеренең ахырында хаҗ талибән кылыб, бән, углы Таҗеддин илән Әчтерхан йортында тордык. Андан Дагстанә вардык, андан Дийарбәкерә вардык. Ул заманда бән фәкыйрь Таҗеддин өч йәшемдә ирдем. Дийарбөкердә бәне бер хуҗа аленә биреб китде. Хода өчен бу угланчыкны өфәнделәрә виреб тәхсыйле гыйлем кыйлсын дәйү. Атамыз хаҗҗаҗелмөслимин илән хаҗ китде. Бән фәкыйрь Таҗеддин атам мулла Йалчыголны ундүрт йыл көтдем. Ундүрт йыл эчендә бән әнвагь фөнүн илә монсыф улдым. Ахырыль-омур Дийарбәкердәге мөрабби хуҗам дөнйадин үтде. Бән атамны эстәйү Истанбула вардым. Истанбулда мәсҗеде Ихйада атамны күрдем. Ул Хаҗҗаҗ илә Рабигыль-әүвәлнең ахыргы пөнҗешәнбесендә Истанбула кермеш. Бән иртәсенде җомга көне күрдем. Бәне күрдеге заманда углы ирдеге икәнне белмәде, бән белдем. Бәндән сүәл кылды: «Нә йирлек фәрзәндсән?» – дәйү. Бән әйтдем: «Болгарлык иштәкмен»,– тидем. Шул заман Һушы китеб йыгылды. һушына килде: «Таҗеддин, синмүсән?» – тиде. Әйтдем: «Бәли, җегәргушәң мөнгыйм»,– тидем. Йәнә аһ орыб гакылы башындан китде. Мәсҗед әһеле йаранлар хәйранә калдылар, шул ахшам өч мәртәбә һушыны китде. Истанбулда ике йыл калдык. Әхмәд әфәнде тәрбийәсендә тордык. Андан каравай илә Хаҗи Тархана килдек. Анда бер йыл тордык. Андан каравай илә Мәскәүйә килдек, алты ай Мәскәүдә тордык. Андан Мәкәрйә кальгасына килдек, анда еч җомга тордык. Андан Казан каласына килдек. Безләр Казан каласында ике ай тордык. Казандай Тураиски каласына кырык сум илә ат иҗарийә алыб йәмшикләр берлән чыкдык. Казандай чыкдыгымыз көн әткәм: «Башым агрыйдыр»,– тиде, вә дәхи әйде: «Әй, балакайем, әй дәрйасыны ахры күрмәмдер»,– тиде.– «Качан ки бән дөнйадин үтсәм, бәнем каберемне гариб идеб ташлаб бәнем каберем әтра-

фындан йырак китмәгел, шул урында йорт-йир иденгел, вә дәрес әйткел вә дәресне әгәрчә күздән калсаң да әйткел вә һәм йылында ике мәртәбә бәнем каберемә зийарәт иткел, бу шартларымны йиренә килтерсәң бән синдән хуш-нудәм»,– тиде.– «Әгәр бивафак, бән синдән әбәдән разый дүгелмен»,– тиде. – «һәм мондан гайре васыйәтләрем вардыр», – тиде. – «Сандык эчендә дәфтәремде табарсың»,– тиде. Әлкыйсса, безләр Казан шәһәрендән чыгыб бу җанибә килдек, йулымыз Мамадыш өйәзенә уграды. Урта Сүн тидеге авылга йитдегемездә әҗәл ирешде, дөнйадин үтде. Алтмыш биш йәшендә, Рәҗәб айында әүвәлге җомгасыны, Рәгаиб киче дийерләр, шул кичдә Җүзәнең 24 нче йәүмендә, тарих һиҗрәтнең 1200 нче йылында, Куй йылында[31] иде. Рухымыз кыйбламыз кеби, безгә газиз җанымыз кеби, тугыз мәртәбә хаҗ кылган, Хаҗ әл-хәрәмәйн хәзрәтемездән җөда булдык. Шул мәрхүмнең васыйәтене бежай килтереб йәүме кыйәмәтдә күрешмәгә вәгъдә илән Хаҗ әл-хөрәмәйн хәзрәтенең шәфагатендән өмид идәрем, амин. Нәбәһү вә кәррәмәһү. Калу иннә лилләһи, вә иннә иләйһи раҗигун.

85. Хаҗ әл-хәрәмәйн мулла Йалчыгол хәзрәтендән бу бәндәи бибизагать, хакъпайе мэрдангруйе сийаһ Таҗеддин тугмыш. Мулла Таҗеддин мөдәррис, Зәй суының Кызыл Чапчак карйәсендә мөдәррис улыб тереклек әйләмеш. Ахырындагы гомерендә Ирнә суы буйында Мәлем дидеге карйөдә тереклек әйләмеш. Ул Таҗеддин фәкыйрьдән дүрт угыл тугды, өч кыз тугды. Олуг углым Бәһаведдин Күперле карйәсендә мәншур илә имам улыб анда тереклек өйләде. Андан кечесе – Җәлаледдиндер. Мәлем карйәсендә атасы хозурында хезмәт идеб һәм мәзкүр карйәдә мәншур илә имам улыб тереклек әйләмеш. Өченчесе – Шөрәфеддиндер. Ул һәм Мәлем карйәсендә тереклек әйләмешдер. Дүртенчесе – Гыйсамеддиндер. Ул һәм Мәлем карйәсендә тереклек әйләмешдер. Олуг кызым – Бибинәфисә, андан кечесе – Газизә, андан кечесе – Бибиҗәмиләдер. Тәммәт.

---

[31] Җүзәнең 24 нче йөүмендә, тарих һиҗрәтнең 1200 нче йылында, Куй йылында – милади белән 1896 елның 14 июне.

# СҮЗЛЕК

А
Аб – су
Аймак – ыру
Аль – гаилә
Астанә – төрбә
Атәшпәрәст – утка табынучы
Афәрин – яхшы, рәхмәт
Ахирел әмер – ниһаять, иң ахырда, соңгы чиктә

Ә
Әбәдән – мәңге
Әҗәл – вакыт, үлем
Әзгафу – иң зәгыйфь
Әкаллү – иң кечкенә, мескен
Әксәр – күбесе, күпчелек
Әлаф – меңнәр
Әлеф – мең
Әлкыйсса – кыскасы
Әлләзи – кайсыдыр ки
Әмсаль – мисалның күплеге, мисаллар
Әнвагъ – төрле, төрлеләр
Әсамму – иң каты
Әсәхху – иң дөрес
Әсхаб – сәхабәләр, яраннар
Әтәвәккәлү – тәвәккәллим
Әтраф – тарафлар, тирә-як
Әхваль – хәлләр
Әхкар – иң түбән
Әшһәдү – шаһитлык бирәм

Б
Баҗ – салым
Балигъ – буйга җиткән, җитлеккән
Бәйан – аңлату
Бәгъду – соңыннан
Бәйгать – буйсыну турында ант
Бәли – әйе
Бәндә – кол
Бәни – уллары, балалары
Бежай – үтәү, җиренә житкерү
Би – юклыкны аңлата торган кисәкчә
Бигайәт – бик, чиксез
Бизагать – байлык, мал, товар
Бикяр – эшсез
Биляд – дәүләтләр, шәһәрләр
Бонйан – нигез
Бөреҗ – Зодиак йолдызлыгы

В
Васыйль – тоташтыручы
Вәҗеб – йөз, сәбәп
Гавпәрәст – сыерга табынучы
Гадад – саннар
Газа – дин өчен сугыш
Газыйм – бөек, зур
Гакыйбәт – ахырда, нәтиҗәдә
Галимән – белүче итеп
Галя – өстендә, өчен
Гариб – чит, ялгыз
Гарык – бату
Гасый – фетнәче, гөнаһлы
Гокаля – акыллы лар, акыл ияләре
Горбәтлек – читтә йөрү
Горуҗ – күтәрелү
Гыйбад – коллар
Гыйбрани – яһүди
Гыйллэт – авыру

Д
Дад – гадел
Дана – белүче, белемле
Дәват – кара савыты
Дәрйа – елга, диңгез

Дәстар – чалма
Дәфен итү – күмү
Дийар – ил, дәүләт
Дикен – хәтле Дүдкә – себерке

Җ
Җаду – сихерче
Җанәб – як
Җаниб – як, тараф
Җафи – каты күңелле, гөнаһлы
Җаһилийәт – наданлык
Җәванмәрд – яшь егет
Җәгалә – эшләде, бар итте
Җәмил – матур
Җәмыг – җыю
Җәнг – сугыш
Җәүза – игезәкләр (йолдызлык)
Җегәргушә – кадерле бала (фар. бәгырь почмагы)
Җөда – аерылу

З
Зан – фикер, уй
Зарыг – имчәк
Зәват – «зат»ның күплеге
Зәхмәт – чир, авыру
Зийадә – күп
Зир – аст
Зире хөкем – хөкеме астында
Зийарәт – килеп карау
Зольмәт – караңгылык

И
Иҗтиһад – тырышлык
Инсан – кеше
Интәһә – бетте, тәмам булды
Истиганәт – ярдәм сорау
Истимдад – файдалану, гамәл кылу
Ихтилаф – каршылык
Ихтыйар – сайлау

Й
Йәүм – көн Йунан – грек

К
Кабаил – кабиләләр
Каныкы – кайсы
Карый – карт
Карья – авыл
Касис – поп
Касыр – кыскарту
Каттаг – кисүче
Каттагы тарикъ – юлбасар
Кә – кебек
Кәза – шулай
Кәламулла – Алла сүзе, Коръән
Кәнд – үз, үзе
Кәнизәк – кол кыз, хезмәтче
Кәрамәт – изгелек, могҗиза
Кизин – соң, соңында
Кенар – яр, кырый
Куй – сарык
Куй (Күй) – квартал, авыл

Л
Ләбән сөт
Лилләһи – Алла өчен
Лүэ-лүэ – энҗе

М
Мантыйк – тел, сөйләшү
Маһ – ай
Мәга – белән, бергә
Мәгъкулат – кабул ителгәннең күплеге
Мәгъриб – көнбатыш
Мәзкүр – искә алынган
Мәкам – урын
Мәлик – патша
Мәншур – указ
Мәрдан – кешеләр, ирләр
Мәтен – текст

Мәһләкә – үтереш, һәлакәт
Мәшаих – шәехләр, картлар
Монассаф – бүленгән
Монсыф – гадел
Морга – көтүлек
Мотыйг – буйсынган
Мөкәррәм – хөрмәтле, кадерле, изге
Менгыйм – бүләкләүче, изгелек итүче
Мөрабби – тәрбияче, опекун
Мөрур – дәвамлы булу, үтү
Мөслимин – мөселманнар
Мөтәватир – халык телендә еш кулланылган

Н
Нам – исем
Намә – язма, китап
Нахийә – өлкә
Нәби – рәсүл, пәйгамбәр
Нәзир – тиң, охшаш
Нәкыль – күчерү
Нәсәб – туганлык, нәсел шәҗәрәсе
Нитәкки – чөнки
Нишан – дәрәҗә, билге
Нөбөввәт – пәйгамбәрлек

О
Оран – яуга чакыру авазы

Ө
Өлүф – меңнәр

П
Пай – аек
Парса – диндар, изге
Пәйда – күренү, табылу

Р
Рабиган – дүртенчедән
Рузгяр – көннәр, вакыт
Руй – йөз
Рум – Византия

С
Сабиган – җиденчедән
Садисән – алтынчыдан
Сакин – яшәүче, торучы
Саләт – дога
Салисән – өченчедән
Санийан – икенчедән
Сахаиф – битләр, китап
Сахиб – ия, дус, хуҗа
Сахихәйн – ике дәрес
Сәбгату – җиде
Сәгпәрәст – эткә табынучы
Сәд – йөз
Сәмәр – җимеш
Сәрвәр – башлык, җитәкче
Сийаһ – кара
Силах – корал
Силсилә – чылбыр
Сирйани – сүрияле
Сиххәт – тазалык, саулык
Сөммә – соңыннан
Сүкәл – авыру

Т
Та – хәтле, кадәр
Табиб – врач
Таифә – кабилә
Там – түбә, оч
Тамм – тәмам, күп, бөтен
Тәгаллөм – белем алу, уку
Тәгълим – укыту, белем бирү
Тәгъриф – аңлату
Тәсмийә – исем кую
Тәсниф – китап язу, китап төзү
Тәфасир – тәфсирләр
Тәхсыйль – белем алу
Түбә – калкулык
Урда – дәүләт Ф

www.darulkutub.com

Фазыл – укымышлы, өстен
Фалиҗ – паралич
Фәрзәнд – бала
Филхаль – шунда ук
Фөнүн – фәннәр

Х
Хаватин – хатыннар
Хаҗҗаҗ – хаҗга баручы
Хаким – әмир, патша, хөкемдар
Хакъ – җир, тузан
Халя – хәзер
Хамилә – йөкле
Хамисән – бишенчедән
Харамилык – караклык, юлбасарлык
Хафиз – саклаучы, Коръәнне яттан белүче
Хашийа – китап кырыендагы шәрех, аңлатма
Хәд – чик, кырый
Хәҗәр – таш
Хәйат – тормыш
Хәким – акыл иясе
Хәләка – бар итте, яратты
Хәлафәт – хәлифәлек
Хәляс – котылган, бушаган
Хәмед – мактау Хәмел – йөк
Хәммам – мунча
Хәрәмәйн – ике хәрам, изге Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре
Хәстә – авыру, чир
Хоруҗ – чыгу, килеп чыгу
Хунриз – кан коючы
Хут – балык
Хушбуй – хуш исле
Хушнуд – риза

Ч
Чавыл – яшь каен
Чук – күп
Чунки – кайчан ки

Ш
Шәҗәр – агач
Шәмди – хәзер
Шәррах – шәрехләүче
Шәфәгать – яклау, ярдәм, теләктәшлек
Шималь – төньяк
Шикәстә халь – ярлы, мескен
Шогуб – халыклар

Һ
Һәзар – мең
Һөбут – иңү
Һүә – ул (он)

www.darul-kutub.com

**МӨСЛИМИ**

# ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЯ

ТЕКСТНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНӘ КҮЧЕРМӘСЕ

## *БОЛГАР ТАРИХЫ*

Рәхимле һәм мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән

Галәмнәрнең хуҗасы Аллаһы Тәгаләгә мактау, аның илчесе Мөхәммәдкә, гаиләсенә һәм яраннарының барчасына Аллаһы Тәгаләнең хәер догалары һәм сәламе ирешсен.

Әмма соңра бу фәкыйрь һәм мескен, кәсебе аз, ялкаулыгы күп булган Шәрәфетдин улы Хисаметдин әйтер ки, Аурупа айларының вакыйгалары, хәлләренең төрләре турында «Мәлхәмә» китабында әйтеп үтелде. Хәзер гарәп айларының исемнәре, ни сәбәптән теге яисә бу исем бирүләре, бәхетләре һәм шомлыклары турында аерым сөйләргә кирәк табылды, һәм дә җиде йолдызның бәхет һәм шомлыклары турында сөйләмәк мөһим булды һәм бу китапта язмак кирәк табылды. Безнең Болгар шәһәренең ислам кабул иткән заманда изге сәхабәләрдән, аларның барчасына Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын, белем һәм гыйлем алган табигыйн һәм табигатьләр турында сөйләмәк һәм алардан соң бу илдә бөек әүлия-лардан һәм изге шәехләрдән кемнәр булганын сөйләмәк бөек бурычыбыз булды, һәм дә алар кайсы җирләрдә һәм кайсы илләрдә күмелгәнен сөйләмәк кирәк табылды.

Бу китап ике бүлектән – мәкаләдән тора. Беренче бүлек Аллаһы Тәгалә яраткан җан ияләренең һәм әйберләренең гаҗәп хәлләре турында һәм икенче бүлек табигыйн һәм табигатьләрнең урыннары турында. Бу китап тәмам булды Ташбилге авылында, Болгар шәһәренең якынында, һиҗри белән тугыз йөз илле сигездә, бөек галим Тәфтазани заманында иде. Аның мәдрәсәсендә укып кайтканнан соң, Болгар иленең картлары табигыйннарның дәрәҗәләре һәм урыннары турында, шулай ук галәмнең гаҗәп хәлләре турында бер китап язарга сорадылар. Аларның теләгенә буйсынып бу китапның каралamasын язарга тотындым.

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ ЯРАТМЫШ ҖАН ИЯЛӘРЕ ҺӘМ БАШКА ӘЙБЕРЛӘР ТУРЫНДА

### ЗАМАН ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Заманны болай аңлаталар: «Заман бөек күк гөмбәзенең хәрәкәте, микъдарыннан гыйбарәт». Ягъни, заман дип, кич һәм көндезнең килеп киттегенә әйтәләр, әмма микъдары күк гөмбәзенең хәрәкәте белән исәпләнер. Чор. Чор өлешләргә бүленер, аны вакыт диләр. Бәхет һәм бәхетсезлек – һәр икесе заман белән кәсеп ителер.

### КӨННӘР ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Җомга көн. Бәхетледер. (Изге) урыннарны хаҗ кылу (көне). Кавышу көне һәм никах көне. Чөнки Адәм галәйһиссәлам белән Хава, Аллаһы Тәгаләнең аларга ризалыгы булсын, һәм Бәлкыйс белән Сөләйман галәйһиссәлам, вә Йосыф галәйһиссәлам белән Зөләйха, һәм Муса галәйһиссәлам илә Сафура, һәм хәзрәте Мө-хәммәд галәйһиссәлам белән Хәдичә вә Гайшә (аларның икесенә дә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) җомга көн никах кылын-дылар. һәм Адәм галәйһиссәлам дөньяга җомга көн килде һәм җомга көн оҗмахка керде, вә җомга көн оҗмахтан

чыкты. Вә җомга көн алты тапкыр йөз мең адәмнәрне Аллаһы Тәгалә җәһәннәмнән азат итәр. Вә һәркем җомга көн тырнак киссә, малы күп була һәм гомере озын була.

Шимбә көн. Мәкер һәм хәйлә көне һәм шомлы көн. Чөнки ул көн пәйгамбәрләрдән алты[1] кешегә шомлык билгесе булды: бере Салих вә бере Нух, вә бере Муса, вә бере Гайсә, вә бере Мөхәммәд галәйһиссәлам. Ләкин бу көндә ау ауламак бәхетле. Вә һәркем шимбә көндә тырнак киссә, бармагы яралана.

Якшәмбе көн. Христианнар бәйрәме. Дөнья көненең беренчесе. Ул көн агачлар һәм бакчалар төзелә башлаган көн. Аллаһы Тәгалә җирне, йолдызларны, күкләрне (айның) «тукталышларын» һәм йолдызлар төркемен (Зодиак билгесе) ул көн яратты. Вә һәркем ул көн тырнак киссә, малының бәрәкәте китә.

Дүшәмбе көн. Бәхетле көн. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллал-лаһу галәйһи вә сәлләм (Аңа Аллаһы Тәгаләнең хәердогасы һәм сәламе ирешсен) ул көн туды. һәм Җәбраил галәйһиссәлам ул көн вәхи китерде. Вә һәм ул көн дөньядан үтте һәм барлык өммәтләренең гамәлләре ул көн пәйгамбәргә тапшырылыр, һәм дәхи Ибраһим галәйһиссәлам Кәгъбәне ул көн япты. Вә Муса галәйһиссәлам Тур тавына Аллаһы Тәгалә белән сөйләшергә ул көн чыкты. Ул көн сәфәргә чыгу бәхетле була. Ул көн тырнак кисмәк һәм бәхетле.

Сишәмбе көн. Аллаһы Тәгалә хайваннарны ул көн яратты. Шомлы көн, чөнки хәзрәте Хава ул көн күрем күрде. Вә Кабил Һабилне үтерде. Вә Җирҗис (Святой Георгий), вә Зәкәрия, вә Яхъя галәйһиссәламнәрне ул көн шәһит иттеләр. Ул көн кан көнедер, кан алдыру һәм кан алу ул көн бәхетледер. Вә һәркем, ул көндә тырнак киссә, кайгы һәм хәсрәттән котылмаячак.

Чәршәмбе көн. Яхшылыгы аз, әмма мунчага яхшы. Шомлы көн. Ганык улы Гуҗ, вә Фиргавен, вә Нәмруд, вә Гад, вә Сәмуд кавеме һәлак булдылар. Юныс галәйһиссәлам бу көндә балык карынында тоткын булды. Ибраһим галәйһиссәламне ләгънәт төшкән Нәмруд бу көн утка атты. Йосыф галәйһиссәлам бу көн зинданга керде. Бу көн тырнак кисмәк һәм начардыр.

[1] Китапта биш пәйгамбәр исеме генә китерелә.

Пәнҗешәмбе көн. Бәхетледер. Хак Тәгалә нурны һәм утны, Җәннәтне һәм Җәһәннәмне бу көндә яратты, һәм хаҗәтләрне сорый торган көндер. Иртә белән Рәсүл галәйһиссәлам бәрәкәт берлә өммәте өчен дога кылды: «Йә Аллам, пәнҗешәмбе иртәсендә һәм шимбәдә минем өммәтем өчен хәер-догада бул», – дип. Аллаһы Тәгаләнең Рәсүле ул көн Мәккәне ачты. Вә Муса галәйһиссәлам ул көн Мисырны ачты. Йосыф галәйһиссәлам ул көн Мисырда падишаһ булды, Ягъкуб галәйһиссәлам белән ул көн күрештеләр. Исмәгыйль галәйһиссәлам ул көн дөньяга килде. Ул көн һәркем, икенде белән ахшам арасында тырнак киссә, авырудан шифа була.

АЙЛАР ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Бу фасыл гарәп айларын белдерер. Бер елда өч йөз илле дүрт көн. Фарсы елыннан унбер көнгә кыскарак.

**Мөхәррәм**

Гарәпләрдә ел башы, әмма иранлыларда ел башы – Нәүрүз, ягъни хәмәл (сарык бәрәне) – март аедыр. Гарәпчә исем куюның сәбәбе шулдыр ки, сүриялеләрдә һәм грекларда әүвәл исеме «дән-бас» иде. Мөхәррәм булуы шулай булды: гарәптә ике падишаһ сугыштылар. Берсенең исеме – Гамир, икенчесенең Сафуан иде. Бу Гамир гаять гыйлем-хикмәт иясе иде. Сафуан җиңеп Гамирны үтерде, ә халкын әсир итте. Шатлыгыннан бу айның исемен мөхәррәм куйды. Үзенең кул астында булган гарәпләргә сугышны хәрам кылды. Шуңа күрә бу ай мөхәррәм (хәрам ителгән, тыелган) дип атала. Унынчы көндә Юныс галәйһиссәлам балык карыныннан чыкты. Хак Тәгалә Гарешне һәм Көрсине, вә дүрт фәрештәне ул көндә яратты. Атабыз Адәм галәйһиссәлам ул көндә тәүбә итте. Нух галәйһиссәлам сиксән кеше белән Җүди тавында көймәдән чыгып, ул көн урнашты. Вә Идрис галәйһиссәлам ул көндә күккә ашты. Ут Ибраһим галәйһиссәламдә ул көндә гөлбакча булды. Карунны ул көндә җир йотты. Йосыф галәйһиссәлам коедан ул көн

чыкты. Ягъкуб галәйһиссәлам күзе ул көн ачылды. Давыт галәйһиссәлам вә Яхъя галәйһиссәлам, вә Искәндәр дөньяга ул көн килделәр. Вә Сөләйман галәйһиссәлам тәхеткә ул көн менде. Вә Әюб галәйһиссәлам ул көндә газаптан котылды. Вә бер риваятькә күрә, хәзрәте Хөсәен ул көндә шәһит булды. Вә Гайсә галәйһиссәлам хәзрәте Мәрьямнән ул көндә туды, вә һәм ул көндә күккә ашты. һәркем ул көндә күзенә сөрмә сөртсә, һич авырлык күрмәс. Вә мөхәррәмнең уналтынчы көнендә «Бәйтел Мөкаддәс» (Иерусалимдагы «Акъса» мәчете) кыйбла булды. Унҗиденче көнендә «Фил ияләре» «Әбабил» кавеме тарафыннан һәлак булып Мәккә халкы бәладән котылдылар.

**Сәфәр**

Сүриялеләрдә һәм грекларда әүвәл исеме «бәрнас» иде. Гарәпчә исем куелуы сәбәбе бол айдыр ки: Гаднан кабиләсе гарәпләр арасында гаять баһадир һәм сугышчан кешеләр иде. Бу айны мөбарәк күреп сугышка киттеләр. Кыскасы, бу бәни Гаднан кабиләсеннән бер Габдешшәмес дигән падишаһның Көнбатышта бер дошманы бар иде. Аурупа падишаһларыннан иде. Бу падишаһ белән бу ай эчендә сугыш кылып күп крепостьларын харап итте. Җиңеп, гади халыкны әсир итеп, вәзирләрен һәм олугларын зинданга салды. Вә (бу халыкның) йөзләре сары булганга, көзен булганга күрә, бу айның исеме сәфәр булсын диде (гар. «әсфару» – сары). Бу ай, Гакраб (Чаян) йолдызлыгында булганга Мөнәҗҗимнәр (күрәзәчеләр) фикеренчә, шомлы һәм начар ай исәпләнә. Никах кылырга һәм бина төзергә ярамый диләр. Бүтән эшләр тыелмаган диләр. Әмма шәригать буенча бу айда барлык хәерле гамәлләрне башлау – бәхетледер. Бу ай мозаффар – теләккә ирешү ае дип тә мәшһүрдер. Бу айның әүвәл көнендә йәзидиләр хәзрәте Хөсәеннең (Аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын), башын кисеп алып Димәшкъка илттеләр. Йәзид аның башыннан бәхиллек теләде. Ул мөбарәк баштан аваз килде: «Без Аллаһы Тәгаләнең казасына вә хөкеменә ризабыз, һәм мин синең шомлыгыңнан вә гамәлеңнән үлмәдем, бәлки, Аның хөкеменнән үлдем. Кыямәт көнендә синнән үзебезнең ка-

ныбызны таләп итмәбез»,– дип. Шуның өчен Йәзидкә ләгънәт укымакка мөмкин булмады. Егерменче көнендә ул башны кире Хөсәеннең (Аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) тәненә илттеләр. Ул баш кире тәненә әүвәлге кебек урнашты, бары тик бугазында башны кискән җәрәхәте калды. Кәрбәла сахрасында күмделәр. Сәфәрнең егерме алтынчы көнендә, тарих һиҗрәтнең илле алтынчы елы иде, Куй елында мөбарәк җомга кичәсендә иде.

**Рабигыләүвәл**

Бу айның әүвәлге исеме сүриялеләрдә һәм грекларда «хуан» иде. Гарәпчә исеме куелуы сәбәбе бол айдыр ки: Пәйгамбәребезнең Кәнанә исемле бөек бабасы бар иде, гарәпләр падишаһы иде. Бер көн ул Кәнанә вәзирләре белән язның әүвәлге аенда сәфәргә чыкты. Күрделәр ки, чәчәкләр ачылган. Болыннарны күрделәр һәм бу айның исемен «рабигыләүвәл» куйдылар, (рабигъ – «яз» сүзеннән). Бу ай – мөбарәк айдыр. Мөхәммәд галәйһиссәлам бу айның сигезенче көнендә Мәдинәдә урнашты. Унынчы көнендә Бөек Хәдичәне (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) никах укытып алды. Егерме икенче көнендә Фатыйма (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) дөньяга килде. Егерме өченче көнендә хәзрәте Рәсүлуллаһ галәйһиссәламнең вафаты булды. Вә хәзрәте Әбү Бәкер ул көндә вафат булды.

**Рабигылахир**

Искә алынган гарәпләрнең падишаһы Кәнанә сәфәрдән кайтканда чәчәкләрнең камил булуларын күрде, яз аеның ахыры иде. Бу ай «рабигылахир» булсын диде. Әүвәл исем грекларда һәм сүриялеләрдә «рәбкан» иде. Ул көндә Йосыф бине Хаҗҗаҗ Кәгъбәне һәм «Хәрам» (мәсҗеден) тәмам итте. Бу айның ундүртенче көнендә намаз фарыз булды. Егерме бишенче көнендә зәкят аяте иңеп фарыз булды. Кайберәүләр Рамазан ае уразасы Рәҗәб аенда фарыз булды, диләр.

www.darulkutub.com

**Җөмадиәләүвәл**

Бу айның исемен грекларда һәм сүриялеләрдә «хәнин» диерләр иде. Гарәпчә исеме куелуының сәбәбе булыр ки: гарәпнең бәни Гаднан угылларыннан Закур шаһ, Көнбатыш дәүләтенең бер Кәран исемле әфрәнҗ (аурупалы) шаһы белән сугышыр өчен Йәмәннән чыгып, Көнбатышның Лига дигән крепостен алып, гаскәре белән кунганда көзнең әүвәле иде. Ул кичә гаять суык булды, сулар туңды. Болар һич тә суның туңганын күргәннәре юк иде. Галәмне бар итүче Аллаһы Тәгаләнең гаҗәп сәнгатен күреп гаҗәпләнделәр, бу айның исемен «җөмадиәләүвәл» диделәр (җәмәдә – «боз булып катты»). Бу айның сигезенче көнендә Гали, Аллаһы Тәгалә аның йөзен хөрмәтле кылсын, дөньяга килде, унбишенче көнендә дөньядан үтте. Чәршәмбе көненең кичәсендә тәмам юып һәм намаз укып беткәннәреннән соң, «күренми торган дөньядан» бер кызыл дөя барлыкка килеп, хәзрәте Галине фәрештәләр ул дөягә салдылар, күтәреп алып Бәкыйг зиратының бер почмагында күмделәр. Хәзер дә кабере Бәкыйгдадыр. Кабере ябылуында Аллаһы Тәгаләнең бер бөек сере бардыр, бәндәләр аны аңлый алмаслар. Бу айның өченче көнендә, җомга көн иде, хәзрәте Гомәр (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) ислам динен кабул итте. Вә шул көндә хөрмәтле Кәгъбә эчендәге потларны пакьләде. Шул көндә өйлә намазын, җәмәгать булып, хөрмәтле Кәгъбәдә укыдылар, ул заманда кырык мөселман булды. Бу айның унбишендә хәзрәте Хәмзә белән хәзрәте Габбас, аларга Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын, мөселман булдылар.

**Җөмадиәлахир**

Бу айның исеме сүриялеләрдә һәм грекларда «зәбед» иде. Гарәпчә исем куелуның сәбәбе будыр ки: югарыдагы гарәп падишаһы Закур, Аурупа иленнән кайткан вакытта, әрмәнленең Ник исемле крепостендә гаскәре белән кунды. Көз аеның ахыры иде, ул көндә әүвәлге көз аеның артык суык булып, сулары артык туңганын күреп әйттеләр: «Бу ай җөмадиәлахир булсын»,–

www.darul-kutub.com

дип. Мәгънәсе: «Бу тегесеннән бозлырак» димәктер. Бу айның әүвәл көнендә Җәбраил фәрештә вәхи китерде: «Раббыңның исеме белән укы!» сүрәсе инде (96 нчы «Галәкъ (Оешкан кан) сүрәсе»). Тугызынчы көн хәзрәте Җәгъфәр Садыйк дөньяга килде. Әберһә мәлгунь хөрмәтле Кәгъбәне ягарга килде. Утызынчы көн Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Кәгъбәне япты.

**Рәҗәб**

Бу айның исеме сүриялеләрдә һәм грекларда «мөнфасыл» иде. Гарәпчә исем куелуның сәбәбе будыр ки: Пәйгамбәребез галәй-

һиссәламнең «наданлык» заманында Һашим исемле бөек бабасы бар иде, гарәп кабиләләренең бөек падишаһы иде. Вә һәм башка дәүләтләргә, Грузиягә, Византиягә, Парска (Иран) вә Фәрәнгестанга (Аурупа) хөкем итәр иде. Бер көн Византиягә сәфәргә чыкты. Юлы Византиянең Салиян исемле крепостена төште. Ул крепостьның сахраларында сәяхәт итеп йөргәндә, бер тауга менделәр. Бу тауның исемен Каләндәр тавы диерләр, гаять биек таудыр. Ул тау Салиянның каршысында иде. Ул тауның башыннан бер чишмә чыга иде, бик мөбарәк судыр. Чыккан җирдән аваз белән чыгар иде. Аның суыннан тирәягындагы илләр авыруларыннан шифа эзләрләр иде. Бу Һашим шаһына бер көн эч авыруы булды, ул чишмәнең суын эчеп шифа тапты. Ул арада рәҗәб ае туган иде, кояш тәмам баткан иде. Үз телендә башлап әйтте: «Бу нинди кадерле дару, безнең шифалануыбыз бу чишмәдәнме яисә бу яңа туган айданмы?» – диде. Шуның өчен бу айга рәҗәб диелде. Гарәпчә мәгънәсе будыр: «Бу ни гаҗәеп, олуг вә кадерле дарудыр. Безнең шифа тапмагыбыз бу чишмәдәнме, юк исә бу яңа туган айданмы?» – диде. Бу айның әүвәл көнендә Нух галәйһиссәлам көймә төзеде. Җиденче көнендә хәзрәте Нухның миче төбеннән су чыкты. Егерме җиденче көнендә Пәйгамбәребез (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен) «Мигъраҗ»га ашты. Егерме сигезенче көнендә Пәйгамбәр хәзрәтләребезгә (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен) пәйгамбәрлек би-

www.darul-kutub.com

релде. Егерме тугызынчы көнендә хәзрәте Госман (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) шәһит булды диләр.

**Шәгъбан**

Бу айның әүвәлге исеме сүриялеләрдә һәм грекларда «гадел» иде. Гарәпчә исем куелуның сәбәбе будыр ки: гарәпнең бәни Тәмим исемле кабиләсендә бер падишаһ бар иде, исеме Нәүфәл бине Вәрака иде. Гаять олуг падишаһ иде. Үзе фәлсәфә гыйлеменнән бик маһир иде. Заманында аннан да хикмәт вә фәлсәфә фәннәреннән галимрәк кеше юк иде. Галәмнең борынгылыгын исбат иткән иде. Бер көн ул фәлсәфә шаһы сәфәргә китте. Килеп юллары Тарабстан диңгезенә төште. Җөрҗан исемле крепостьта гаскәре белән кунак булдылар. Җөрҗан шаһы аны сахрага ау ауларга алып чыкты. Ау аулаган вакытта каршыда күзләренә бер биек тау күренде, Җөрҗан шаһы әйтте: «Әй гарәпләр хуҗасы, хәзер шул тауның башына чыгыйк. Анда бер чишмә бар. Башы бер, унике бүлек булып агарлар, һәр бүлек сулары бер-берсеннән аерыладыр. Бер бүлеге бик суык, бер бүлеге эссе. Кай бүлектә сөт тәме бар, кай бүлектә гамбәр исе бар. Кай бүлеге кара төсле, кай бүлеге кызыл төсле. Кай бүлеге агулы, кай бүлеге су булып агар, кара таш булып туңар. Моны күреп Нәүфәл бине Вәрака гаҗәпләнеп әйтте: «Әй Җөрҗан шаһы бине Рөстәм бине Бәлгам, минем бүсер зәхмәтем бар, бу чишмәләрнең кайсы бүлегеннән эчәргә әмер итәрсең?» – диде. Җөрҗан шаһы әйтте: «Гамбәр исе килгән бүлегеннән эч», – диде. Кайчан ки гарәп шаһы эчте, шунда ук шифа тапты, бүсере уылып артыннан чыкты, һәм ул арада кояш баткан иде. Мөнфасыл ае тәмам булган иде. Үз теленчә дога укыды: «Йә Аллам, бу айны мөбарәк кыл, чынлап та, мин бу бүлекләнеп аккан чишмәдән шифа таптым». Төрки мәгънәсе будыр ки: «Әй бари Ходайа, бу айны мөбарәк кылгыл барча бәндәләреңә, мин, чынлап та, шифа таптым шогубләнеп торгучы чишмәдән», – диде. Шогуб дип бүлек булып таралып киткән нәрсәгә әйтәләр. Шул вакыттан бу ай шәгъбан булды. Бу айда хәзрәте Муса галәйһиссә-ламгә Тиһ сахрасында «манна һәм бытбыл-

дыклар» күктән иңде, өченче көнендә хәзрәте Хөсәен анадан туды, дүртенче көнендә хәзрәте Хәсән туды. Унбишенче көн Бәраәт кичәсе иңде. Уналтынчы көнендә Кәгъбәгә намаз өчен йөзне юнәлдерделәр, әүвәле «Коддуожа (Иерусалим) йөзне юнәлдерәләр иде. Егерме бишенче көнендә хәзрәте Гомәрнең вафаты булды.

**Рамазан**

Бу айның исеме сүриялеләрдә һәм грекларда «туан» иде. Гарәпчә исеме куелуның сәбәбе будыр ки: хәзрәте Исмәгыйль заманында бәни Харҗәм исемле бер залим шаһ Хәбәш (Эфиопия) дәүләтеннән чыкты, хәзрәте Исмәгыйльнең җирен алыр өчен. Күп гаскәр белән килделәр. «Хәбәш шаһы сиңа сугыш белән килде, дәүләтеңне харап итәргә», – дигәч, Исмәгыйль галәйһиссәлам Мәккә халкы белән чыгып, ул Харҗәм гаскәрен тар-мар иттеләр. Кайбер ләрен үтереп, калдыкларын кол иттеләр. Ул көн сугышта бик каты эссе иде, Рамазан аеның башлангычы иде, хәтта ки, аякларының тиресе эсселектән пешеп кабарып, каты зәгыйфьләнделәр. Мәккә гарәпләре кычкырып әйттеләр: «Ва Рамазан, ва Рамазан, янды безнең йөрәкләребез сусаудан, ә аякларыбыз эсселектән». Мәгънәсе төрки теленчә: «Ай-вай, янды безнең йөрәкләребез сусамак белән, вә аякларыбыз ком вә таш эсселеге белән».

Инде шул вакыттан бу айга «Рамазан» (раммәзә – эссе булды) дип исем бирделәр. Бу айның әүвәл көнендә Коръән «Ләүхел-мәхфүз»дән[2] Мәккәгә, Пәйгамбәребезгә, аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен, иңдерелде. Кирәк саен Җәбраил галәйһиссәлам аннан өйрәнеп Пәйгамбәр галәйһиссәламгә укыр иде. Өченче көнендә Ибраһим галәйһиссәламгә «Зәнд» дигән изге кәгазь (китап) иңде. Дүртенче көнендә хәзрәте Гайсәгә «Инҗил» (Евангелие) иңде.

---

[2] Ләүхел-мәхфүз – Язмыш тактасы (гар. – сакланылган такта).

**Шәүвәл**

Бу айның исеме сүриялеләрдә һәм грекларда «туван» иде. Гарәпчә исеме куелуның сәбәбе будыр ки: гарәпнең бәни Гайс исемле кабиләсендә Борһан бине Әнус исемле шаһ гаять олуг иде. Җирдә булган хайваннарның һәм бөҗәкләрнең җенси якынлык кылу үзенчәлекләрен тикшереп, тауларда, сахраларда һәм урманнарда йөрер иде. Юлда килгәндә, попугай төркемен күрде, ягъни чебен төркемен, тутый кошлар төреннән бер чебендер, диңгез ярында күп булалар. Төсе яшел. Аларның җенси якынлык кылганнарын күргәне юк иде. Ягъни аларның хатын-кызларның җенси әгъзасы канатлары астында, ә ирләрнең җенси әгъзасы билгеле урында. Моны күреп, гаҗәпләнеп әйтте: «Бу нинди шәүвәл (күченү), нинди җенси якынлык кылу, җенси әгъзасы канатлары астында». Ягъни: «Бу ни гаҗәп җенси якынлык кылу, җенси әгъзасы канатлары астында»,– дип гаҗәпләнде. Моны күргәндә кояш бату вакыты иде, чөнки ул чебеннәр кояш баткач уйнарлар. Ул арада яңа ай күренде, ягъни туван ае тәмам булды. «Бу гаҗәп кодрәтне күрдем, шуның өчен бу айның исеме «шәүвәл» булсын», – диде. Бу айның беренче көне бәхетсездер һәм бәйрәмдер, гыйбадәттән башка бүтән гамәл кылырга тыелган. Җиденче көнендә хәзрәте Хәмзәне шәһит иттеләр. Егерме җиденче көнендә «Бәдәр» сугышы булды.

**Зөлкәгъдә**

Бу айның исеме сүриялеләрдә һәм грекларда «вәзна» иде. Гарәпчә исем куелуының сәбәбе будыр ки: Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен) бөек бабасы Габдешшәмес бине Габделманнаф исемле иде. Җир шарының кешеләр яши торган барлык дүрттән бер өлешен үзенә буйсындыру теләге бар иде. Бер көн бу фикер белән ятты: «Бу вәзна аенда Көнбатыш дәүләтләренә барам, 'андагы падишаһлар миңа буйсынсыннар, ясак түләргә риза булсыннар, яки үзем кебек кояшка гыйбадәт итсеннәр, ягъни минем динемдә булсыннар», – дип. Шул фикер белән ятты, йокы-

га китте. Шул кичәдә төшендә хәзрәте Газраилне күрде. Шулай итеп күрде ки, моның кебек матур сурәтне дөньяда һич күргәне юк иде. Габдешшәмес сорады: «Йә чибәр һәм камил кеше, син кем һәм сине кем диерләр, Тәңре түгелме син?» – диде. Газраил галәйһиссәлам әйтте: «Мин синең кебек үк кол, әмма мине Үлем фәрештәсе диерләр. Ягъни барча тереклек ияләренең җанын вә атаң-анаң җанын мин алдым»,– дип әйтте. Габдешшәмес әйтте: «Бу кояш Тәңре түгелме?» – диде. Хәзрәте Газраил әйтте: «Түгел, бәлки, Аллаһы Тәгалә, барлык әйберләрне бар итүче һәм барлык тереклек ияләрен ризыкландыручыдыр». Габдешшәмес әйтте: «Мин ул Тәңрегә иман китерәм, иман таләп ит»,– диде. Газраил галәйһиссәлам әйтте: «Алладан башка иляһ юклыгына шаһитлык китерәм һәм Газраил Аның пәйгамбәре икәненә шаһитлык китерәм, дип әйт, – диде. – Иманга китергәне өчен Газраил нәбиуллаһ»,– диде. Бәс, Габдешшәмес, кояшка табынудан кайтып, «Рахман»га гыйбадәт кылганын таныды һәм раслады. Хәзрәте Газраил әйтте: «Йә падишаһ, синең исемең Габдрахман булсын, минем исемем дә Аллаһы Тәгалә алдында Габдрахман», – диде. «Гозер» димәк кол мәгънәсендәдер, «ил» димәк Аллаһ мәгънәсендәдер, сүрияле (телдә). Бәс, Габдрахман әйтте: «Минем җанымны кайчан алырсың, мин үлемгә хәзерләнеп үләр идем»,– диде. Хәзрәте Газраил башын кырын салып уйлап торганнан соң, аягының биш бармагын күрсәтеп югалды. Падишаһ бу төштән куркып уянды. Дәүләтендә ни хәтле фәлсәфә галимнәре, йолдызлар буенча төш юраучылар һәм күрәзәчеләр бар – һәммәсен чакырды, төшен юрау өчен. Бер ай буенча моның төшен аңлата алмадылар. Кайберләре биш ел дип, кайберләре биш йөз ел дип юрадылар. Кыскасы, бердәм юрау булмыйча, бер ай тоташ шул хәлдә булдылар. Ниһаять, туван ае тәмам булып, егерме тугызынчы көнендә Аллаһы Тәгалә хәзрәте «Мәңге тере» Хызырны җибәрде. «Бар, ул колым Габдрахманның төшен аңлатып бир һәм (сөеклем Мөхәммәд (аңа хәер-дога һәм сәлам ирешсен) аның нәселеннән) киләчәге турында шатлыклы хәбәр бир», – диде. Кыскасы, Хызыр галәйһиссәлам барды. Шаһ йокысын-

нан уянгач күрде: бер дивана йөрер, кулында кечерәк балтасы бар. Ул дивана, падишаһка игътибар итмичә, тәхетенең аягын балта белән чабарга кереште. Падишаһ хәзрәте бик сабыр кеше иде, каравылчыларны чакырмыйча акрын әдәп белән: «Йә фәлән, син минем тәхетемнең аякларын кисмә, чөнки атал арыбыздан калган мирас, зиннәте китмәсен»,– диде. «Кил минем аягымны чап», – дип аягын сузды. Дивана, аны кире кагып, арлы-бирле карады, йөрде, күрде, падишаһның кул юа торган алтын тазы бар иде, аңа барып сиде. Падишаһ әйтте: «Зинһар, әй фәлән, ул тазга симә, чөнки атал арыбыздан калган мирас, ашаганнан соң анда кулларыбызны юабыз, аны шакшылатма, кил минем таҗыма си»,– дип, башыннан таҗын алып хәзрәте Хызырның алдына куйды. Моннан соң Хызыр галәйһиссәлам елмаеп шаһка сәлам бирде һәм әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең колларыннан бер колымын, синең төшеңне аңлатып бирергә килдем. Минем исемем Хызыр. Вә дәхи синең нәселеңнән бер хак пәйгамбәр килер. Ул дөнья вә ахирәт падишаһы булыр. Исеме Мөхәммәд Габдулла углы. Һашим углының Габделманнаф нәселеннән килер, – диде. – Инде төшеңне аңлатам. Дәүләтендә никадәр күрәзәчеләр, шәехләр, фәлсәфә гыйлемен белүчеләр һәм Мөнәҗҗимнәрең (йолдызлар буенча күрәзәчеләр) бар, барысын да өндә, алар алдында аңлатам», – диде. Соңыннан падишаһ фәлсәфә галимнәрен, Мөнәҗҗимнәрне һәм күрәзәчеләрне җыйды һәм әйтте: «Минем алдагы төшемне ничек аңлатырсыз?» – диде. Алар әйттеләр: «Буталчык төшләр, буталчык төшләргә юрау юк», – диделәр. Шаһ, ачуланып: «Барчагызны хөрмә агачына асармын, – диде. – Ничә еллар буе сезне хәзинә йортыннан тәрбия итәм, минем төшем ничек буталчык булсын. Чөнки мин төшемдә Үлем фәрештәсен күрдем, ул миңа Аллаһы Тәгаләнең берлеген өйрәтте», – дип сикереп кылыч алып торганда хәзрәте Хызыр галәйһиссәлам, бер фәкыйрь сурәтендә торып: «Йә гарәпләр падишаһы, ачуланма, алар да бәндәләр. Аллаһы Тәгалә белдермәгәнне алар белмәсләр, утыр, төшеңне аңлатам»,– диде. Барчалары утырдылар, вә әйтте: «Йә, падишаһ, ул Үлем фәрештәсе бармак күрсәтүе синең гомерең

күплеген яисә азлыгы турында хәбәр бирү түгел, бәлки будыр. Биш нәрсәне Аллаһы Тәгаләдән гайреләр белмәсләр, димәктер. Ул биш нәрсәнең берсе – Кыямәт көненең кайчан, кайсы фасылда һәм кайсы көндә булачагын Аллаһы Тәгаләдән башкалар белмәсләр. Икенче бармагы ишарәдер, яңгырның кайсы айда, кайсы көндә һәм кайсы сәгатьтә явачагын Аллаһы Тәгаләдән гайреләр белмәсләр. Өченче бармагы ишарәдер, йөкле хатыннар вә хайваннар карынында ирме, кызмы, карамы-кызылмы икәнен Аллаһы Тәгаләдән гайреләр белмәсләр. Дүртенче бармагы ишарәдер, һичбер җан иясе иртәгә нәрсә кәсеп итәсен белмәс, Аллаһы Тәгаләдән гайре. Бишенче бармагы ишарәдер, адәм балалары кайсы җирдә һәм кайчан үләчәген белмәсләр, мәгәр Аллаһы Тәгалә белер, димәктер. Шуның өчен Аллаһы Тәгалә Коръәндә «Локман сүрәсе»ндә хәбәр бирде: «Чынлап та, Аллаһы Тәгалә (Кыямәт көне) сәгатен белүче; Ул яңгыр яудыра һәм карыннарда нәрсә бар икәнен белә. Ә җан (иясе) белмәс, иртәгә нәрсә кәсеп итәчәген һәм белмәс кайсы җирдә үләчәген» (31 нче сүрә, 34 нче аять),– дип, төшне аңлатканнан соң, Хызыр галәйһиссәлам халык арасыннан юк булды. Белделәр: бу – Хызыр. Ул арада туван ае тәмам булды, яңа айны күрделәр. Габдрахман Көнбатыш илләренә баруыннан, аларны ялган дингә өндәүдән тәүбә итте. Сугышка бармый өендә калды. Вәзна аена «зөлкәгъдә» дип исем бирде (өйдә утыру ае). Бу айның дүртенче көне «Мәгарә ияләре» мәгарәләренә керделәр. Бишенче көнне Ибраһим галәйһиссәлам Кәгъбәне төзи башлады. Җиденче көнендә Фиргавен гаскәре белән Нил елгасында һәлак булды.

**Зөлхиҗҗә**

Бу айның исеме сүриялеләрдә һәм грекларда «бәрдан» иде. Гарәпчә исем куелу сәбәбе будыр ки: Исмәгыйль галәйһиссәламнең углы Әдбән иде. Хаҗ кылу өчен, Сүриядән Мәккәгә килде. Ул заманда Мәккәдә хәзрәте Ибраһимның Изге китаплары белән гамәл кылучы бер олуг галим бар иде, исеме Әюб иде. Халык белән хәзрәте Әдбәнне каршы алып олыладылар. Ул

көндә вәзна ае тәмам булган иде. Әюб галим әйтте: «Хәзер, әй шаһ Әдбән бине Исмәгыйль галәйһиссәлам, хаҗ аеның ахырыдыр. Бу бәрдан аеның ун көненнән ары хаҗ булмас дип боерылды. Бабаң Ибраһим галәйһиссәламнең китабы «Зәндә» исемле, анда шундый вакыт беләи чикләнелгән», – диде. Ул арада яңа ай күренде, Әдбән хәзрәтләре үз теленчә дога кылды: «Аның ахыры «зөлхиҗҗә». Ягъни бу ай хаҗ айларының ахыры», – диде. Бәрдан аена зөлхиҗҗә (хаҗ ае) дип исем бирде. Унынчы көн бәйрәм көне, Гарәфә җомга көнгә туры килсә, «иң олы хаҗ» диерләр.

## Үзебезнең икълим турында

Җиденче икълим, ягъни җирнең җиденче бүлеге. Ягъни җиденче уралы турында, һинд диңгезеннән Иран диңгезенә барганчы, ягъни Әстерхан диңгезеннән Кытай диңгезенә барганчы. Бу икълим ай тәрбиясендә, алты уралдан күркәмрәк. Файда ягыннан һәм чисталык өчен кирәк-яраклары күплегеннән. Чөнки чишмәләре вә елгалары, вә агачлары күп. Сулары бик тәмле һәм җиңел үзләштерелә. Игенне Аллаһы Тәгалә яңгыр суы белән сугара. Бу икълим Мияс елгасыннан, ягъни Уралның көнчыгыш ягыннан башлана. Кытайга хәтле җитеп, Кытайның Пекин шәһәреннән, Суык диңгезнең көньягыннан, урысның Архангель шәһәренең көньягына барып Лена елгасына чыга. Аннан Көнбатыш илләренә килеп, Көнбатыш Европаның Буляк исемле шәһәреннән Рим җирләренең чигендәге Латыш шәһәреннән килгән Поляк җиренә чыгар. Поляк илен үткәч, Дунай елгасының көнчыгыш ягына, Киев шәһәренә килер. Аннан Грузия һәм Дагстан тирәләреннән Дон һәм Ананов шәһәрләреннән Тибриз елгасының аргы ягы белән килеп, Кубань елгасының башыннан Әстерханга чыгар. Бу – Икълимнең көньяк чиге. Көнчыгыш ягының чиге – Кытай йортының Пекин дигән шәһәре. Ягъни бу икълимдә, ягъни җиденче уралда кояш чыгу, кич һәм көндезнең сәгатьләре төрле-төрле. Кытайның шәһәрләрендә, вә һәм Лакур, һәм Бакур шәһәрләрендә, якут халкына чыкканчы, төннең иң кыска вакыты 9 сәгатьтән

ким булмас. Аннан Уралның көнчыгыш ягында Тубыл суына килгәнче Ангар(а) сулары, вә Әртеш (Иртыш) суы, вә Тубыл суы, вә Уй суы, вә Мияс суы бу җиденче Икълимнән исәпләнмәсләр, чөнки алар Уралның көнчыгыш ягында. Алар алтынчы Икълимнән саналыр, ягъни алтынчы уралның чиге; ә Җаек, Сакмар һәм Сарайчык сулары – алтынчы икълимнең чиге, ягъни алтынчы уралның көнбатыш ягындагы чик. Инде җиденче уралдагы бөек елгаларны һәм мәшһүр суларны искә төшерәм. Мәгълүм булсын, Уралның көнбатыш ягындагы чиге, ягъни Уралның көнбатыш тарафыннан Агыйдел чыга, Архан тавыннан чыга. Өфе иделе дә Уралның көнбатыш ягыннан таудан чыга. Әй суы Тагынай тавыннан чыга. Чулман иделе төньяктан, Төньяк диңгездән, аның көньягыннан чыга.

### Мәшһүр елгалар турында

Урал (тавының) көнбатыш ягы турында сөйлим: Кыйгы елгасы Әй елгасына коя, Әй елгасы Өфе иделенә коя. Таныб һәм Бөре дигән елгалар Агыйделгә коя. Узан елгасы Өфе иделенә коя. Бази, Сармәсан, Кармәсан елгалары Агыйделгә коя. Ак елгасы да, Сөн елгасы да Агыйделгә коя. Мәллә елгасы Акка коя. Ирәнә һәм Зәй елгасы, бергә кушылып, Агыйделгә коя. Мәшһүр елгалардан Агыйдел Чушмысы диерләр һәм Кичү дигән елга Агыйделгә коя. Агыйдел Чулман иделе белән кушылган җирдә бер тау бар, Юнчә тавы диләр. Анда бер чишмә бар. Ул чишмәне «Гаеп ирәннәр чишмәсе» диләр, анда «гаеп иреннәрнең» җитәкчесе күмелгән, исеме Габдессамат (аңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ирешсен). Төньякта Агыйдел белән Чулман иделенә койган елгалар күп, әмма мәшһүрләре – Иж суы, Туймы елгасы, Чирмешән елгасы. Чирмешән елгасы ике: берсе – Олы Чирмешән, икенчесе – Кече Чирмешән, Агыйделгә коялар. Самар елгасы Волга иделенә коя, Кинәле Са-мар елгасына коя. Волга иделенә көнбатыш яктан елгалар күп коя, мәшһүре – Мәскәү елгасы, ул Агыйделгә коя. Агыйдел, килеп, Ока иделен һәм Чулман иделен һәм Нократ иделен берләштереп, Мишә тавыннан бераз түбән Волга иделенә коя. Тагын мәшһүр елгалар

www.darul-kutub.com

– Зөя һәм Суй елгалары. Волга елгасына Төньяктан килеп койган елгаларның мәшһүрләре – Илләт һәм Казан елгалары һәм Мишә елгасы. Нократ иделенә көньяктан Бөре елгасы һәм Чушмы елгасы коя, көнбатыштан көнчыгыш якка таба агып килә. Моны Нократ Чушмысы диләр,– мәшһүрдер. Башка мәшһүр елгалар күп, барын да язу мөмкин түгел. Хәким Птолемейның «Атлас» дигән тарих китабында күренгәннәрнең «Җиденче икълим» турындагысы бу урында тәрҗемә ителде.

## ДИҢГЕЗЛӘРНЕҢ ГАҖӘП ХӘЛЛӘРЕ ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ МОХИТ ДИҢГЕЗЕ

Диңгезләрнең олысы – Мохит диңгезе. Юпитер тәрбиясендә. Барлык җир йөзен ул каплаган. Шулай хикәят кылалар: Мохит диңгезен тикшерер өчен, Мисыр патшасы Хуҗа Бәйрәм бер көймә ясатты, алты еллык азык куеп, биш йөз кешене юлга чыгарды, аларга берәүне башлык итеп билгеләде. Исеме «Диңгез углы» дип мәшһүр иде, җитмеш ике төрле тел белә иде. Ул көймәдә бер ел бардылар, диңгездән башка нәрсә күрмәделәр. Искәндәр заманы иде. Искәндәр кушуы буенча, бу Хуҗа Бәйрәм патша аларны җибәргән иде. Юлда болар бер көймәгә очрадылар, сугыштылар, җиңә алмадылар. Моннан соң сөйләшә башладылар, әмма бер-берсенең телләрен аңламадылар. Аллаһы Тәгалә боларның көймәсенә Хызыр Ильяс галәйһиссәламне җибәрде. Мисырлылардан ул: «Сез кем, кайдан киләсез?» – дип сорады. Болар: «Безнең падишаһыбыз – Искәндәр, ул – җир йөзендә кеше яши торган бөтен җирләрнең падишаһы»,– диделәр. Алар Искәндәрнең кем икәнен, дәрәҗәсен белмәделәр, мисырлыларны кунак итеп, үз шәһәрләренә алып бардылар, бер ел кунак итеп, Мохит диңгезенең атауларын һәм шәһәрләрен күрсәттеләр. Күпме утрау, күпме авыл, күпме шәһәр бар – Мисыр гаскәрләренә һәммәсен күрсәттеләр. Ул утрауларны «Яңа дөнья» дип атадылар. Мисырлылар, кайтып, Искәндәргә хәбәр бирделәр. Искәндәр, бу хәлләрне ишетеп: «Йә Рабби, синең кодрәтеңне һәм галәмнәреңнең күплеген бу мескен бәндә ничек белсен»,– дип, Аллага сәҗдә кылды.

Мохит диңгезендәге утрауларны һәм алардагы гаҗәп хәлләрне бу урында язу мөмкин булмаганга язылмады.

**Чин (Кытай) диңгезе**

Сатурн планетасы тәрбиясендә. Бу диңгез Мохит диңгезенә тоташкан. Көнчыгыштан Кызыл диңгезгә, анысы Көнбатышка барганчы. Дөньяда, Мохит диңгезеннән кала, бу диңгездән олы диңгез юк. Аның гаҗәп яклары бик күп. Аллаһы Тәгалә ул диңгездә аккошлар яраткан. Ул кошлар Аллаһы Тәгаләгә мондый зикер әйтәләр: «Синнән башка һичбер иляһ юк. Син безне бар цттең һәм безгә ризык бирәсең». Шулай ук бик матур көйләр чыгарып сайрыйлар. Ишеткән гашыйклар бии-бии үлә. Ул диңгез унбиш көн хәрәкәтсез, тын тора. Ул кошлар һаман йомырка салалар һәм бала очыралар. Әмма диңгездән чыга белмиләр. Анда тагын бер утрау бар. Ул утрауда мәче токымыннан булган хайваннар бар. Ул утрауда тычканнар бар, бездәге мәчеләрдән зур. Әлеге хайваннар тычканнарны аулап ашыйлар, тизәк итәләр, ул тизәк «кабәлә» дип йөртелә торган хуш исле була. Ул утрауда кешеләр дә бар. Кайсы кызыл тәнле, кайсы яшел тәнле, канатлары бар, очалар. Анда өч төрле тутый бар. Берсе ак, берсе кызыл, берсе яшел. Камфара агачы да анда. Ул агачның түбәсен уйсалар, су чыга, камфара була; төбен уйсалар, су чыга, туңа, минералга әйләнә. «Бак-Бак» дигән агач та анда. Кояш баткач, ул агачлар: «Бак, бак!» – дип кычкыралар. Таң аткач юкка чыгалар. Ул диңгездә нурдан киеккә охшашлы кошлар бар. Авызларыннан күбек аталар, ул күбек кан була, ул каннан хуш исле әйбер була. Ул диңгездә егерме карыш биеклеге бакалар бар. Йомырка салганда, һәрберсе мең йомырка сала, артык та, ким дә түгел. Кайсы йомыркага күз төшерсәләр, шуннан бака чыга; күз төшермәсәләр йомырка кала, бака чыкмый.

**Һинд диңгезе**

Меркурий тәрбиясендә. Бу җирдә Иран диңгезе белән Кызыл диңгез бергә җыелган. Ул диңгездә егерме мең утрау бар.

Ул утрауларның берсе – «Таил» исемле. Таил утравында бер халык бар. Йөзләре балыкныкы кебек. Чәчләре ат койрыгы кебек. Үзләре: «Алладан башка иляһ юк», – дип зикер әйтәләр. Валерианка агачы да шунда. Анда соя агачы да күп. Ул утрауда бер чишмә бар: көндез акканы ак таш, кичен акканы кара таш була. Анда тагын бер утрау бар. Кичен дә көндез кебек яктылык бирә. Анда нур бар: ут кебек яна. Анда тагын бер утрау бар: анда ат башлы, сыер аяклы кешеләр бар. Үзләре кеше кебек, әмма башлары юк.

**Иран диңгезе**

Бу диңгез кояш тәрбиясендә, мөбарәк диңгез. Алты ай көнбатыштан көнчыгышка ага, алты ай көнчыгыштан көнбатышка ага. Анда ике упкын бар: очраган көймәләр исән чыкмыйлар, шунда һәлак булалар. Гамбәр һәм якут ул утрауда күп. Ул утрауда кешеләр яшиләр. Ул гамбәр һәм якутларны алып, Һиндстанга килеп сәүдә итәләр. Ул диңгез «Гамбәр» дигән исем белән дә мәшһүр.

**Калзәм диңгезе**

Бу диңгез Марс планетасы тәрбиясендә. Калзәм дигәне бер шәһәр исеме. Аның турында болай хикәят итәләр. Әүвәл заманда Калзәм арасында олы ил бар иде. Ул заманның падишаһын «Сөләйман хакыйкый» диләр иде. Идрис галәйһиссәлам шәригатендә иде. Калзәм шәһәрен Идрис галәйһиссәлам шәригатенә өндәде. Кабул итмәделәр. Аларны ул падишаһ, шәһәре белән бергә харап иттерде. Калзәм диңгезен казытып, ул шәһәрне агыздырды. Аннан

Йәмәнгә барды, аннан Җиддә һәм Сиданга, аннан Мохит диңгезенә барды. Анда бертөрле балык бар. Өстендә ак мамык кебек төкләре бар. Хатын-кызлар аны эрләп, җеп ясап тукыйлар, кафтан әзерлиләр. Ул илнең халкын «Сәмәхи» дип атыйлар. Калзәм диңгезен «Зәнҗи» диңгезе дип тә әйтәләр. Ул диңгездә дулкын булмый, күбеге дә булмый. Язын төбеннән кыйммәтле таш – агат чыга. Аны Йәмән ташы диләр.

**Көнбатыш диңгезе**

Бу диңгез Зөһрә йолдызы тәрбиясендә. Анда бер зур балык бар, аю балыгы диләр. Йөзе – кеше йөзе кебек. Ак сакалы бар, гәүдәсе койрыгы кебек, һәр айның урта декадасында, коры җиргә чыгып утырып, Ходага зикер әйтә. Зикере болай: «Сиңа мактау булсын, без Сине олылыйбыз, һәм Синнән башка иляһ юк!» Кич булгач, ул балыклар диңгезгә кереп китәләр. Ул диңгездә бер утрау бар, ул утрауда бер күл бар. Ул күлнең киңлеге бер айлык юл. Күлдә бертөрле балык бар. Аның колаклары бар. Уң колагының өстенә «Алладан башка иляһ юк», сул колагына «Мөхәммәд Аллаһының илчесе» дип язылган. Ул күлне «Тиңдәшсез» диләр. Аның суының хасияте бар: һәркем утка пешсә, ул кешене күлгә салсалар, тиз арада төзәлеп, тәне әүвәлге кебек була. Карыны ач кеше, аның суын эчсә, бер атна буе ашамый түзә.

**Җөрҗан (Каспий) диңгезе**

Бу диңгез ай тәрбиясендә. Көнчыгыш-яктан чыга. Бу диңгездә тау кебек аждаһалар бар. һәм бу диңгездә утраулар бар. Ул утрауларда адәм сурәтле җеннәр көне-төне ашау-эчү, уен-көлке, бию белән вакыт үткәрәләр. Бу җеннәрнең шәһәренә «Магин» диләр. Һинд теленчә «Оҗмах кебек» дигән сүз. Бу утрауда төрле җимеш агачлары күп. Чишмәләреннән сөт һәм хәмер ага. Өрмия галәйһиссәлам аларны дингә өндәргә барды. Алар аның сүзен кабул итмәделәр. «Әгәр синең оҗмах, тәмуг дигән сүзләрең дөрес булса, безгә Дөньяда оҗмах бирсен, Ахирәттә тәмугта газап кылсын», – диделәр. Өрмия галәйһиссәлам аларның сүзләрен Аллаһы Тәгаләгә җиткерде. Аллаһы Тәгалә, аларның газабын кичектереп, Исрафил галәйһиссәламнең һәлак итү быргысына хәтле аларның тормышын оҗмах кебек кылды, төрле чишмәләр агызды. Аларның саны йөз сиксән мең ир һәм йөз сиксән мең хатын-кыз. Бала тудырмыйлар һәм картаймыйлар, Кыяматкә чаклы кәеф-сафа чигеп үткәрәләр. Безнең төрки телендә ул шәһәр «Барсаң – кайтмас» дип йөртелә. Искәндәр Зөлкарнәен хәзрәтләре ул шәһәргә килеп чыкты, Аллаһы Тәгаләнең гаҗәп эшләренә карап сәҗдә кылды.

Бу мәкаләнең эчендәге гаҗәп хәлләр Гиппократның «Атлас» исемле китабыннан күчерелде.

### ТАУЛАРДАГЫ ГАҖӘП ХӘЛЛӘР ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Мәккәдә Әбү Кобәес тавына менеп сарык башын ашаса, ул кешегә беркайчан да эт өрмәс, тешләмәс.

Әндәлүс (Испаниядә) тавында чынаяклар буйый торган буяу һәм «кызыл күкерт» бар, башка җирләрдә юк. һәм ул тауның башында бер күл бар, аннан терекөмеш чыга. Күлнең исеме – «Терекөмеш күле».

Кытайда бер тау бар, «Энгер» тавы диләр. Ул тауның башында сарык башы кебек алтын-көмешләр бар. Әгәр дә алтыннарны ярлы алса – үлә. Зинадан туган байлар алса үлмәсләр, файда алырлар. Яхшы ата-анадан туган байлар алса, шулай ук һәлак булырлар.

Сәмәркандта шулай ук бер тау бар. Яз көнендә кар ява, гаять суык була. Кыш көне бик эссе була.

Кирманда бер тау бар. Исеме – «Сур» тавы. Ул тауда бер төрле ак алача ташлар бар. Берәр кеше ул ташны алып «Өфф» дип өрсә, таш эченнән бер адәм сурәтле таш чыга. Ул ташка «Өфф» дип өрсәләр, ком була, өрмичә суга салсалар, кеше сурәтендә кала. Судан алып янә «Өфф» дип өрсәләр, элеккечә ак алача ташка әйләнер.

Табаристанда тагын бер тау бар. «Мәрҗан» тавы исемле. Ул тауга, болыт килеп, яңгыр яуса, яңгыр булып төшәр, кара таш булып катыр. Ул ташлар дүрт, алты, сигез кырлы булалар. Әгәр дә бу ташларга үтмәс балталарны, пычакларны салсалар, өч тәүлек анда тотсалар, үткен булыр, корычка әйләнер.

Һөрмездә һәм бер тау бар. Ул тау башында бер чишмә бар. Аны «Рәхмәт чишмәсе» дип йөртәләр. Әгәр дә бер кеше «Йә, һү» дисә, ул су акмый, тик тора. Әгәр «Йә, мән һү» дисә ага, юлына китә.

Исфаһанда бер тау бар, тау өстендә бер елга бар. Кояш чыкканда, ул елга көнчыгыштан көнбатышка ага, кояш батканда, көнбатыштан көнчыгышка ага.

www.darulkutub.com

Азәрбайҗанда бер чишмә бар. Аның суын алып калыпка койсалар туңа, таш була. Азәрбайҗан халкының таш савытлары, казаннары шуннан ясала.

Ширазда бер тау бар. Анда бер чишмә бар. Әгәр ул чишмәгә пычрак салсалар дулкынлана, пычракны салган кеше артыннан куып китә, җитә алса – батыра, җитә алмаса – кире кайта. Әгәр көненә ун кат пычрак салсалар, ул да ун кат шулай итә.

Җөрҗанда бер чишмә бар, аның юлында ак кырмыскалар яши. Әгәр берәр кеше, су алырга барганда, шул кырмыскаларның берәрсен үтерсә, суны тутырып алса да, савыты буш була.

Йсфаһан белән Шираз арасында бер чишмә бар. Ул чишмәдән бер савыт су алып, ул суны берәр урынга куйсалар, сыерчыклар җыелып, ул суны алган кеше илтеп куйганчы, төрле-төрле матур тавыш чыгарып сайрыйлар.

Наһәвәндә бер чишмә бар. Әгәр бер кеше килеп, ерактан ук «миңа су кирәк» дип кычкырса, ул су үзе аның янына килә, эчеп туйгач, «җитте» дисә, урынына кире китә.

Гиппократның «Зәнд» исемле Аурупа телендәге китабыннан тәрҗемә ителде.

* * *

www.darul-kutub.com

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## *Болгар халкыннан чыккан табигыйн һәм табигатьләр (аларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ирешсен) турында*

### БОЛГАРНЫҢ ИСЛАМ КАБУЛ ИТҮЕ ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Рәсүлуллаһ галәйһиссәлам һиҗрәтнең тугызынчы елында, Хут (Балыклар) йолдызлыгында, изге Рамазанның тугызынчы көнендә, Болгарда ул заманда Айдар хан иде, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен) өч сәхабәне, хак ислам динен өйрәтү өчен, Болгарга җибәрде. Берсе – Габдрахман бине Зөбәер (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын), икенчесе – Зөбәер бине Җәгъдә (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын), өченчесе – Тальха бине Госман (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын). Болгарга килгәч, ул сәхабәләр үзләрен табиб итеп күрсәтеп, кешеләр дәвалап йөрделәр. Ул заманда Волга иделе Болгарның астыннан ага иде. Бараҗ заманында Волга иделе, аннан күчеп, көнбатыштан акты. Ул заманда, ягъни Бараҗ хан заманында, өч йөз туксан алтынчы елда, сәхабәләр килгән вакытта, өйләре биш йөз егерме иде дип әйтәләр. Үзләре утка табыналар иде. Искә алынган сәхабәләр Болгарда күп авыруларны дәваладылар, барысы да терелде. Халык арасында: «Гарәбстаннан табиблар килгән, Мөхәммәд исемле пәйгамбәрнең (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен) яраннары икән. Иманда, диндә һәм әдәптә тиңдәшсезләр»,– дип, исемнәре мәшһүр булды.

Кыскасы, беркөнне Айдар ханның кызы Туйбикә паралич авыруы белән авырый башлады. Ничек кенә дәвалап карасалар да, файдасы булмады. Айдар ханның Бараҗ исемле вәзире бар иде. Ул әйтте: «Әй ханым, гомерең озын булсын, безнең шәһәребезгә Гарәп йортыннан өч табиб килде, дәвалауда тиңдәшләре юк. Әмма диннәре безнеке кебек түгел». Айдар хан әйтте: «Ул табибларны чакыр, килсеннәр, кызым Туйбикәне дәваласыннар»,– диде.

www.darul-kutub.com

Кыскасы, Бараҗ вәзир барып чакырды. Гарәпләр ханның йортына килделәр, кызны күрделәр... «Бу – паралич авыруы, кызны, «хәдәнг» яфрагы белән себерке бәйләп, мунчада чабарга кирәк», – диделәр. Хан сорады: «Ул хәдәнг нинди агач?» – диде. Зөбәер бине Җәгъдә хәзрәтләре төрки теленә бик оста иде, әйтте: «Ул каен агачы»,– диде. Хан әйтте: «Ул агач бездә күп, бәйләгән себеркеләребез дә күп», – диде. Сәхабәләр әйттеләр: «Безгә яңа агачтан алган каен яфрагы кирәк»,–диделәр. Хан әйтте: «Кыш көнендә аны кайдан табарга?» – диде.

Кыскасы, хан әйтте: «Сезнең Гарәп йортында бер Пәйгамбәр чыккан, исеме Мөхәммәд, сез аны беләсезме?» – диде. Сәхабәләр әйттеләр: «Әйе, беләбез, без аның яраннары, аның диненә керергә теләүчеләрне өндибез»,– диделәр. Хан әйтте: «Минем дөньяда күргәнем ошбу кыз бала гына, башка балам юк. Әгәр сез аны терелтсәгез, яңа каен агачыннан себерке бәйләсәгез, мин сезнең динегезне кабул итәчәкмен»,– диде.

Кыскасы, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәердогасы һәм сәламе ирешсен) бу өч сәхабәгә өч әйбер биргән иде. «Сездән могҗиза сорасалар, бу өч әйбердән ярдәм сорарсыз», – дип. Чалма – аны Габдрахман бине Зәбәергә. Кара савыты – аны Зөбәер бине Җәгъдәгә һәм Таяк – аны хәзрәте Тальхага биргән иде (аларга Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын). Сәхабәләр кара савытына таякны кадап куйдылар, аннан соң Габдрахман (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын), Пәйгамбәр галәйһиссәлам биргән чалманы башына урап, ике рәкәгать намаз укыды. Калган ике сәхабә: «Амин»,– диделәр. Ул таяк, озаеп, яшәреп, Аллаһы Тәгалә рөхсәте белән, Рәсүлуллаһның могҗизалы бәрәкәтендә бер зур ботаклы каен булды. Аннан себерке бәйләп, хан кызын мунчага җибәреп чаптырдылар. Кыз шунда ук савыгып, хан сараена йөгереп кайтты. Бу могҗизаларны күреп, ислам диненең дөреслегенә ышанып, Айдар хан иман китерде: пакь мөселман булды. Аннан соң Бараҗ вәзир, калган шәһәр халкы бу могҗизаларны күреп, барчасы мөселман булдылар.

Бу өч сәхабә Шәһри Болгарда өч ел калдылар. Дин һәм шәригать кануннарын өйрәттеләр, Җамигъ мәсҗеде төзеделәр. Халыкка Коръән өйрәттеләр, җомга һәм гает намазлары укыдылар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам биргән таяк белән хөтбә укыдылар. Мәдрәсәләр төзеделәр. Ислам динен өйрәтеп, халык диндә ныклык табып, какшамас булганнан соң өч ел үткәндә, ике сәхабә «Нурлы Мәдинәгә» кайттылар. Хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдә (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) Болгарда калды. Ханның кызы Туйбикәне никахлап алды. Егерме биш ел гомер итеп, укытып, вафаты Болгарда булды. «Аллага шөкер, Аның нигъмәте белән изгеләр шулай үтә».

## БОЛГАРДА ҺӘМ АҢА БУЙСЫНГАН ӨЛКӘЛӘРДӘГЕ ТАБИГЫЙННАР ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Тарих һиҗрәтнең йөз дә туксан бишенче елында Болгарда һәм аңа буйсынган илләрдә хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдәдән (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) белем алган һичбер табигыйн калмады. Инде Болгарның үзендә сәхабәдән дәрес алган табигыйннар турында: әүвәл – Давыт Хафиз Ишай улы. 2 нче – Нәдер Хафиз Бикбай улы. 3 нче – Идашбай Пулад улы. 4 нче – Ишбулат Хафиз Әюббирде улы. 5 нче – Туйчы Хафиз Тукмө-хәммәд улы. 6 нчы – Сифән Әлмәт улы. 7 нче – Кадерлекол Өмедлекол улы. 8 нче – Өмедлекол Мирас улы. 9 нчы – Мирас Кәнҗебай улы. 10 нчы – Ишбулат Шәмгун улы. 11 нче – Байгол Тукбирде улы. 12 нче – Юныс Ишкенә улы. 13 нче – Ишкенә Хафиз Мөрсәлим улы. 14 нче – Ялчыгол Хафиз Мәмәткол улы. 15 нче – Илмәмәт Ишмәмәт улы. 16 нчы – Туркай Хафиз Ай-пулат улы. 17 нче – Ибраһим Хафиз Шәмгун улы. 18 нче – Илтабан Кадергол улы. 19 нчы – Байбакты Имәр улы. 20 нче – Илчегол Ялчыгол улы. 21 нче – Иткусды Дәүләтбай улы. 22 нче – Нәрембай Хафизбай улы. 23 нче – Нәдершаһ Бәдершаһ улы. 24 нче – Хоррәмшаһ Чирмеш иле улы. 25 нче – Госман Кадергол улы. 26 нчы – Бадәм Хоррәмшаһ Чирмеш иле улы. 27 нче – Иделбакты Уразай улы. 28 нче – Уразай Четай улы. 29 нчы

– Алтынбүкән Котлыбай улы. 30 нчы – Җанъегет Бикъегет улы. 31 нче – Җанбакты Котлымәт улы. 32 нче – Үнгән Усман улы. 33 нче – Котлыбай Хафиз улы. Бу искә алынган 33 табигыйн барчасы «Раббымыз сүзен», «Мәңгелекнең вәхиен» яттан өйрәнгән кешеләр. Белмичә калмагыз, боларның барчасының төрбәләре Шәһри Болгарда.

БОЛГАР ӨЛКӘЛӘРЕНДӘГЕ ТАБИГЫЙННАР ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Әүвәл Уралның көнбатыш ягыннан килеп сәхабәдән белем алган «Башкорт» дигән кабиләдән: 1. Аиткол Заит улы, Ай суы буеннан килгән; 2. Котлыбай Дәүләтбай улы; 3. Иткусды Муйнак улы; 4. Итимгән Кылыч улы; 5. Уразбакты Бөрҗан улы; 6. Таймас Таис улы. Болар, Ай елгасыннан килеп, сәхабәдән белем алып кайтып, йортларын мөселман иткәннәр.

Янә Өфе иделеннән килгән табигыйннар. Өфе иделе кушылган җире – Агыйдел. Анда нугай ханы Байчура ханның йорты. Аннан килгән табигыйннарның берсе – Җәянкол Иманкол улы. 2. Иманкол Нәдер улы; 3. Җаманай Сарманай улы. Каберләре Өфе (иделе) тамагында.

Өфе иделе белән Агыйдел кушылган җирдән түбәнрәк, көнбатыш ягында Дим суы койган җирдән ерак түгел Төрмә авылыннан табигыйн Әхмәд Котлымөхәммәд улы. 2. Дим елгасыннан килгән суфи Уразбакты Айдагол улы. 3. Мәскәү Тимерпулат улы. 4. Исан Йосыф улы. 5. Муллагол Әләмгол улы. Аллагуат Ишпулат улы. Боларның каберләре Дим буенда.

Янә Сармәсан, Кармәсаннан килеп белем алган табигыйннар: 1. Ибраһим Исмәгыйль улы. 2. Сөләйман Муса улы. 3. Җәмагол Айдагол улы. 4. Алдар Калдар улы. Боларның каберләре Сармәсан, Кармәсан буенда.

Ак елгасында утырган Тугаш хан авылыннан ике кеше табигыйн булып, Болгарда белем алып кайтып, анда булган нихәтле башкорт һәм мишәр кабиләләрен ислам әһеле иттеләр. Берсе – Морадым Хафиз, икенчесе – Мөхсин Хафиз Юлдаш уллары.

Янә Минзәлә елгасында, Минзәлә елгасы башында Дусем авылында – Дусем, янә Илбакты. Болар иң гыйлемле Болгар табигыйны Нияз уллары.

Янә Ак суының Агыйделгә койган җиренә якында ике табигыйн бар. Берсе – Дауш хан, икенчесе – Көл ел хан, һәр икесе бертуганнар. Болар да башкорт һәм мишәр кабиләләрен ислам әһеле иттеләр. Янә алардан ерак түгел Илбакты Уразбакты улы.

Янә Агыйделнең төньяк ягында, Туймы елгасы тамагында Содумнан, ягъни Алабугадан. «Содум» дип грек телендә алабуга балыгын әйтәләр. Ул Содум бик зур шәһәр иде, аны Искәндәр Зөлкарнәен төзегән, шулай ук Болгарны. Хәзер аларны хәзрәте Мир Тимер җимерде. Янә Алабугадан барган Акбаш Хуҗа Әкбәр Болгар табигыйны. Ул – Корьәнхафиз. Аның юлдашлары:

1. Кәрсан Илмәмәт улы. 2. Әләмгол Муллагол улы. 3. Айдар Аит улы. 4. Юлдаш Мәскәү улы.

Янә Агыйделнең көнчыгыш ягыннан, Алабугадан ерак түгел Мәләкәс авылыннан: 1. Сәйид Сәйдар улы. 2. Тукбай Байгол улы. 3. Җанбакты Уразбакты улы. Болар да табигыйннарның бөекләреннән иделәр.

Янә Агыйделнең көнчыгыш ягыннан: 1. Субай Сабай улы.

2. Иманай Яманай улы. 3. Ишбирде Тукбирде улы. Болар, Субай авылыннан килеп, сәхабәләрдән белем алдылар. Хәзер каберләре анда.

Янә Субай белән бертуган Шинкилче. Икесе дә Барс ханның уллары. Шинкилче хан Болгарга барып сәхабәгә буйсынды. Аның юлдашы Зәй буенда: 1. Байгол Айдагол улы. 2. Атый Җенле улы.

3. Чаллы Туксабай улы. 4. Ак Сарыбай Сары улы. Болар Зәй буеннан барып сәхабәгә буйсындылар. Каберләре Зәй буенда.

Янә Кичү суыннан: 1. Үтәш Илтабан улы. 2. Нәдер Иманкол улы. 3. Яманай Сабанай улы. 4. Нәдершаһ Хоррәмшаһ улы. Хәзер каберләре анда.

Агыйделгә койган Чушым буенда Тубылгы атавы каласында булган: 1. Мирас Иштуган улы. 2. Аит Заит улы. 3. Хаҗи

www.darulkutub.com

Бәйрәм Хаҗҗәкилде улы. 4. Касыйм Әюб улы. 5. Габдрахман Габделманнан улы. 6. Илһам Кәюмарс улы. Барысы да Тубылгы атавы каласында күмелгәннәр.

Чирмешәннең һәр икесендә табигыйн күп. Без күчергән табигыйннар турындагы китапта күрелмәде, әмма хуҗасы әйтте: «Бу ике елгада булган табигыйннарның саны беленмәде, чөнки күбесе, сәхабә кабере янында яшибез дип, Болгарга күчеп киттеләр, күбесе шунда үлделәр»,– диде.

Нократ иделенә койган Шушма буенда булган табигыйннарның хисабы: 1. Хәсәншәех Кадер улы. 2. Балтач Нәдер улы. 3. Салавыч Абайдан улы. 4. Исмәгыйль Абзан улы. Хәзер дә каберләре шунда.

Янә Казан суы буенда, Казан башында: 1. Иштирәк Байтирәк улы. Янә Курсада Гадел Абдул улы. Янә Кәче илендә Зөлмөхәммәд Хаҗи Мөхәррәм улы. Янә Гайшәбикә авылында: Гайшәбикә үзе, Хаҗи Әрәмле (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) кызы. Хаҗи Әрәмле, Мәдинәдә торып, Пәйгамбәребез Мөхәммәдтән (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен) белем алган сәхабә. Янә Хаҗи Әрәмленең (аңа Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) улы Таҗетдин әфәнде. Боларның каберләре Казан суы буенда.

Янә Волганың аргы көнчыгыш ягында, Зөя тамагындагы табигыйннар: 1. Ильяс Муса улы. 2. Касыйм Ибраһим улы. 3. Уразмөхәммәд Кадермөхәммәд улы. 4. Борһан Садырхан улы. Боларның каберләре Зөя тамагында.

Уҗым авылында Фәйзулла Гобәйдулла улы. Күз авылында Таймөхәммәд Динмөхәммәд улы. Мулла илендә Муллагол Айдаргол улы. Нәрембай Әҗем улы. Хәзер каберләре анда. Тәтеш авылында Элгән Үткән улы. Шырдан авылында Сөләйман Каспулат улы. Бадамшаһ Әждан улы, Җөмади Тимербулат улы. Нәдершаһ Сәлим улы. Сәлим Ишкилде улы. Болар мишәр кабиләсеннән, хәзер дә (каберләре) анда. Бигеш авылында мишәрләрдән Тимеш Хаҗи Солтанморад улы. Илһам Ибраһим улы. Симуш Килдебай улы.

www.darulkutub.com

БОЛГАРДАГЫ ТӘБГЫ ТАБИГЫЙННАР ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Бу тәбгы табигыйннар заманында Болгарда ислам дине куәтле булды, мөҗтәһидләр заманнары иде. Хәким хан заманы иде. Тәбгы табигыйннарның саны билгеле түгел. Мәшһүр булган гыйлем эстәүчеләрнең кайберләре Харәземгә чыгып китеп, күбесе Харәземдә һәм Багдадта үлделәр. Монда безнең Болгарга кайтып дәрес биргән Хисаметдин бине Ибраһим «Ысул» китабының «Тәхкыйкы Хисамия»ны язды. Фөругдан «Тимер таш»ны язды. Имам Шәфигый мәзһәбе белән ястү намазын кояш баегач, берәр сәгать үткәч укырга фәтва бирде. Тагын җомга намазында, мисыр (шәһәр) булу шарт түгел дип, имамнан башка өч кеше белән җомга укырга фәтва бирде. Тагын җомганың сөннәт азанын укырга калдырмаска фәтва бирде. Бу өч фәтваны Багдадка җибәреп, имам Әбу Йосыфтан фәтва сорады. Ул заманда Һарун әр-Рәшид иде. Фәтвасында язган: «Йә дустым, миннән бу эш турында фәтва сорама. Синең үзеңнең фәтваң да җитә, сөнни әһелләре өчен. Шулай ук ястү намазы турында Шәфигый мәзһәбе буенча һәм җомга азаны турында Хаҗҗаҗ бине Йосыф сүзе буенча, һәм безнең мәзһәп буенча. Син үзеңнең дәүләтең Болгарда гамәл кылырга хаклысың. Туры юлдан баручыларга сәлам»,– дип фәтва бирде.

Янә тәбгы табигыйн галимнәреннән Габделлатыйф бине Габдулла. «Мәҗмәгыйль Бәһрәйн шәрхе» авторы һәм «Имдадел Фәттах» авторы.

Янә Нух бине Мәрьям мөҗтәһидләрнең олысы. «Могайнел Әхкям» һәм «Фәваидел Фөкаһа» китапларын ул язды. Кабере Болгарда. Танылган имам Хаһәрзадә Болгариның кабере Харәемдә. Янә танылган имам Гайсә бине Абан кабере Болгарда. Янә мөҗтәһидләрдән Әхмәд бине Мөхәммәд бине Әбү Бәкер, «Хизанә» авторы, кабере Болгарда. Янә Муса бине Раһвиянең кабере Болгарда. Ысул һәм фөруг буенча башка мөҗтәһидләрнең Болгарда раберләре күп. Кашгар җиреннән килеп Аллаһ йортына хаҗга Карганда, Бохарадан һәм Харәземнән килеп, Болгарда вафат булган ралим һәм суфиларның Болгар-

www.darul-kutub.com

да каберләре күп. Габдрахман Җаминың кабере дә Болгарда. Хаҗга барганда вафат булган. Янә Мәүләви Хөсрәвиянең һәм Мәүлянә Мохаккак Габделхәкимнең каберләре Болгарда. Башка фазыл һәм изгеләр каберләренең хисабының чиге юк. Болгар тәбгы табигыйннарының тарих һиҗрәтнең 230 елында берсе дә калмады (аларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте киң булсын).

## БОЛГАРДАГЫ ХАТЫН-КЫЗ ТАБИГЫЙННАР ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Бар нәрсәне бар иткән Аллаһы Тәгаләнең хикмәте һәм теләге белән һәм күп бәхетләр бүләк итүе аркасында, хатын-кызлар җәмәгатеннән нихәтле изге сәхабәләрдә укучы булып, ислам диненең фарызлары һәм ваҗибларын һәм бөек дәрәҗәле Коръәнне яттан укырга өйрәнгән беренче кеше хәзрәт Зөбәер бине Җәгъдә никахында булган, өч сәхабәнең могҗизасы белән терелгән Туйбикә Айдар хан кызы иде. Янә Хәдичә Давыт Хафиз кызы. Хафизә Нәдер кызы. Биксолтан хаҗия Уразмәт Хафиз кызы. Фатыйма Кыймөхәммәд кызы, Гөлбикә Туйчы Хафиз кызы. Гөлстан Мирас кызы. Рабига хаҗия Иделбакты кызы. Суфия Үтәгән кызы. Көмешбикә Тәтеш кызы. Адинәбикә Ялчыгол Хафиз кызы. Гөлбостан Алтынбүкән кызы. Алтынбикә Җанбакты кызы. Гаделбану Нәдершаһ кызы. Хәлимә Илмәмәт кызы. Сабира Илтабан кызы. Гөлсем, Хафизә вә Хаҗия Ибраһим Хафиз кызлары. Айсылу Яхшыбай кызы. Болар барчасы – сәхабәләрдән (аларга Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) Коръән өйрәнгән Мәшһүрәләр. Билгесезләре күп (аларның барчасына Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын).

## БОЛГАРДАГЫ ИЗГЕ ШӘЕХЛӘР ҺӘМ БӨЕК ӘҮЛИЯЛӘР ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Инде билгеле булсын, хәзер тарих һиҗрәтнең тугыз йөз сиксән тугызынчы елына, хәтта тугыз йөз туксан тугызынчы елына хәтле әүлиялар турында сөйләнелер, иншаллаһы Тәгалә. Нократ иделенең көньяк ягында аккан Бөре исемле елга бар, Казаклар авылында Көнчыгышта, Көнбатышта мәшһүр булган

www.darul-kutub.com

Аллаһы Тәгалә әүлиясы Бәйраш бине Әбраш суфи бар. Ачык итеп зикер итү хокукына ия иде. Үзе Төркестанда Хуҗа Әхмәд Ясәвидән (аңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булсын) белем алган иде. Китәргә рөхсәт алып Болгар кабиләсенә җибәрелде, үзе Коканд кешесе иде. Шул Бөре елгасы буенда Адай Чирмеш авылында Ишмөхәммәд Тукмөхәммәд улы. Шәех Баба дигән кушамат биргәннәр иде. Ул Хуҗа Бәйрәштан белем алган иде. Күп халык аңа мөрит булды. Ул да ачык итеп зикер әйтү хокукына ия иде. Утыз алты ел мөрит тәрбияләде. Ул арада егерме ел дәвамында суфилар юлыннан бу ысул белән файдаланучы кеше калмады. Ул заманда Яркәндтә шәех Һидаятулла Хуҗа Әхмәд Ясәвинең мөрите бар иде. Болгар халкында суфилыкны белгән кеше калмады, галимнәр наданлыкта калды. Болгарга буйсынган Тәрбирде Чаллысы авылыннан Идрис Зөлмөхәммәд дигән кеше бар иде, Яркәндкә барып, шәех Һидаятуллага мөрит булды. Унбиш ел анда суфилык белеме өйрәнде. Искә алынган суфи Ишмөхәммәд үлгәнгә егерме ел тулгач, ул Идрис хәлифә Болгарга, Тубылга, Өфе, Казан, Сембер өлкәләренә җибәрелде, суфилыктан белем бирер өчен. Өфе йорты аны хурлап, кыйнап җибәрде. Аннан килеп Казан һәм Болгар якларында белем бирде. Бераз халык аннан белем алды. Үзе Тәрбирде Чаллысында вафат булды.

Аннан Яңа Казанның Касыйм шәех Ибраһим улы тәрбияләнеп хәлифә булды. Ул да, Казанда торып, күп халыкны суфилык юлына кертте. Хәзер кабере Казанда. Соңра Фәйзулла әфәнде, Бохарадан килеп, Казанда торды. Ул да унбиш ел халыкка белем бирде. Хәзер кабере Казанда.

Янә Чаллы янында Казаклар авылында Шәгым бине Иштирәк ахун, Багдадтан укып кайтып, Фәйзулла әфәнде урынын алды. Ул да суфилык гыйлеме белән Казан, Өфе, Алатыр, Сембер, Сарытау, Сарайчык һәм Тубыл халкына дин һәм шәригать юлын өйрәтте. Хәзер кабере Тәрбирде Чаллы Казакларда.

Янә Бирдебәк ханның авылында, Тәрбирде Чаллының янында хәзрәте Габдессәлам хаҗи Хәбибулла кабере, Котлы Бөкәш авылында Бохараның мулла Нияз Чукмакый кабере бар. Һәр

www.darulkutub.com

икәве хаҗга барган иде. Бирдебәк хан заманында вафат булдылар. Бү-ләрдә бер каенлык арасында, чокырның югарысына менгәндә, сул кабыргасында өч бөек әүлиянең кабере бар. Берсе – Хуҗа Әсгар, Мәгълүм Хуҗа диләр, икенчесе – Габдулла Хуҗа, Чубар Габдулла дип билгеле, өченчесе – шәех Мөхәммәд.

Багана авылыннан чыккан Байтирәк улы, Багдадта белем алып кайтып, Бүләрдә дәрес әйткән. Янә Чирмешәндә Кизләү Чишмәсендә Хуҗа Мәхдүм задә Йосыф Күргәни кабере бар. Җанбакты авылында мәшһүр галим Дәввани кабере бар. Янә Җанбакты авылында шәех Хөсрәвия кабере, хаҗга барганда вафат булган. Шагыйрь Сәнаинең кабере Иделгә койган Чишмә елгасының тамагында. Янә Кичү буенда, Кичү суы Чишмәгә койган җирендә Тубылгы атавы каласы янында Хуҗа Әхрарның кабере. Зәй тамагында атаклы суфи, «Тәфсир» авторы Хөсәен Вагыйз кабере, хаҗга барганда вафат булган, Бараҗ хан заманында.

Янә Ирнә тамагында Бәйраш ханның йорты. Галим һәм фазыл хан. Аның заманында, Ташкенттан килеп, бер галим-фазыл хан дәрес әйтте. Хаҗга барганда, Бәйраш ханның йортында торды. Ул Нугай ханы иде. Ул галим-фазылның исеме Ирнияз Ширнияз улы, мулла Хафиз әт-Ташкәнди дип танылган иде. Алла «сүзен» (Коръәнне) яттан белүче, Коръән укучы иде. Ирнә тамагында вафат булды.

Янә Минзәлә суының тамагында Мостафа ханның йорты. Анда атаклы суфи Хуҗа Бәйрәм кабере. Янә Агыйделнең ярында, Чаллы суының тамагында Мәүлед Хуҗаның кабере. Агыйдел янында Байчура Чирмеш авылында Төркестанның Хуҗа Әхмәд Ясәви мөрите Хуҗа Әмир Кәлал кабере, хаҗга барганда вафат булган. Янә Алабугада Бәйрәм Хуҗаның кабере. Янә Агыйдел башында Хуҗа Солтан Морадның кабере. Дим суы буенда, Кыпчак авылы янында Хуҗа Тукашның вә Хуҗа Биктәшнең, вә Сөләйман Хуҗаның каберләре. Янә Үршәк суы тамагында атаклы суфи Хуҗа Гыйсмәтулла әс-Сәмәркандинең кабере.

Вәләкин Уралның икенче ягындагы Җаек вә Сакмар буендагы изгеләрнең исеме һәм каберләре язылмады, икенче тәфсилләп язган китабыбыз бар, аннан карарсыз. Әмма Сарайчыкта булган изгеләр турында язам, чөнки бу китапта табигыйннар һәм тәбгы табигыйннар турында бик күп язылды.

Сарайчыкта булган табигыйннар турында. Әүвәл Зәйнелгабидин Уразбакты хан улы. Дәүләтшаһ Хоррәмшаһ улы. Гыйззәтулла Насрулла улы. Гали Госман улы. Муса Сөләйман улы. Давыт Нәдер улы. Болар барысы да Болгарга барып хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдәдән белем алганнар (аларның барысына да Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын).

Вә тәбгы табигыйннардан булган Әднәҗ әфәнде Котлыбай улы. Ширгазый әфәнде Бугазый улы. Котлыбай Дәүләтбай улы. Габдулла әфәнде Гыйззетулла улы. Изге әүлиялардан Бәдретдин Хафиз Госман улы. Котлыпулад Хуҗа Илбакты улы. Башкалары да күп, мәшһүрләрен яздык. «Йә Аллам, безне сөеклеләреңнән һәм изгеләреңнән кыйл».

«ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЯ» КИТАБЫНЫҢ АХЫРЫ

## Хуҗабыз Сәгьдетдин әт-Тәфтазани, хәзрәте Тимер Газый Солтан, киреләк, бозыклык һәм динсезләк дәүләте Болгарның җимерелүе һәм Шәһри Болгарның харап булуы турында

Тарих Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен) сигез йөз алтмыш икенче елында Аллаһы Тәгалә хәзрәте Аксак Тимерне җиңүче итте. Ул кешеләр яши торган җирнең дүрттән беренең күп шәһәрләрен харап һәм һәлак итте. Аллаһы Тәгалә аны бозыклык һәм фетнә кылучы, эчүчеләр һәм ир балалар белән зина кылучыларга яхшы эшне эшләп, бозыклыктан тыю өчен җиңүче итте. Ул Аксак Тимер хәзрәтләре Кытайның көнчыгыш чигендә Тәхте Сөләйман дигән шәһәр янындагы Алмалы дигән авылдан. Ул заманда Кытайның падишаһы Чыңгыз хан иде. Аны ислам диненә

www.darul-kutub.com

өндәде, кабул кылмады, аны үтерде. Кытайның күп шәһәрләрен харап итте.

Ахырда Кытай халкы аңа буйсынды һәм салым түләргә риза булды. Кытай йортына Чыңгыз ханның улы Турымтайны падишаһ итеп куйды. Ул заманда Кызылбашның Мәшһәд дигән шәһәрендә Надир шаһ исемле кеше чыкты, сөнниләрнең күп шәһәрләрен алды, галимнәрне үтерде. Үзенең әшәке мәзһәбенә халыкны өндәде. Ахырында Бохараны, Сәмәркандны һәм Үргәнечне алды, һәм Хиваны алды, ханнарын үтерде. Үзенең ялган мәзһәбенә өндәде. Сөнниләрнең гыйлеме егылды, чөнки сөнниләр аз иделәр. Шигыйлар төркеме арасында чолганышта калганнар иде. Сөнниләр зарландылар, Аллаһы Тәгалә аларның догаларын кабул итте. Хәзрәте Аксак Тимер Кытайның Пекин дигән шәһәренә гаскәре белән сугышка хәзерләнгән вакытта Аллаһы Тәгаләгә «Мәңгелек» Хызырны җибәрде: «Бар, колым Әмир Тимергә әйт, Бохарага барсын, аларны Кызылбаштан азат итсен һәм Надир шаһны үтерсен. Син аның гаскәренең алдында бул»,– дип төшенә керде.

Кыскасы, Хызыр галәйһиссәлам тизлек белән, Мир Тимер хәзрәтнең каласына килеп, аңа бу хәбәрне тапшырды. Мир Тимер хәзрәт Кытай йортыннан гаскәре белән чыкты, гаскәренең санын Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәс иде. Киткәнче Пекин каласын, Нажин каласын һәм Кытайның башка шәһәрләрен алып, ясак түләргә риза булып калдылар.

Кыскасы, Мир Тимер хәзрәт Хызыр галәйһиссәлам белән Бохарага юл тотты. Төркестанга килде. Төркестанның Хуҗа Әхмәд Ясәви Мир Тимернең төшенә керде: «Әй егет, тиз генә Бохарага бар, инша Аллаһы Тәгалә, ул Надир шаһның үлеме синең алдында. Синең башыңнан күп эшләр кичсә кирәк, – диде. – Барлык Бохара халкы сине көтә»,– диде. Бу төшне күреп уянды, рәхмәт сәҗдәсе кылды.

Кыскасы, иртә торып, Төркестанның ханы Нугайбәк ханга күп хәзинә бирде, Хуҗа Әхмәд Ясәви каберенә төрбә куяр өчен. Төркестан ханы гаҗәеп бина куйды, төрле бизәкләр белән, хәзер дә бар. Аннан Мир Тимер хәзрәт гаскәре белән Сәмәркандка

www.darul-kutub.com

юл тотты. Сәмәркандта Надир шаһның бер биге бар иде, аны үтерде. Ул вакытта Надир шаһ Бохарада иде. Аксак Тимер килүен ишетеп, гаскәре белән Бохарадан Мәшһәд шәһәренә качты. Үз урынына Кызылбаштан бер бикне Бохарага куйды, кырык мең гаскәр белән. Ул арада Аксак Тимер Бохарага килде. Шәһәрне камады, ул Кызылбаш биге Аксак Тимер белән ике ай сугышты. Нәтиҗәдә, Аксак Тимер Кызылбаш биген төрлечә газаплап үтерде, калдык гаскәрне Бохараның олыларына кол итеп өләште. Бохарада ике ай торды. Солтан Морад дигән гыйлем өстәүчене Бохарага хан итеп куйды, чөнки ул Солтан Морад хан нәселеннән иде. Бу Солтан Морад бишектә бер бала караучы хатын кулында калган иде. Надир шаһ ул хатыннан сорады: «Кулыңдагы углан кем? – диде, – Сәлим углы түгелме?» – диде. Бала караучы хатын әйтте: «Минем үземнән туган, без коллар», – дип җавап бирде. Надир шаһ аны үтермәде. Шул углан Солтан Морад иде. Аксак Тимер аны Бохарага хан итте. Ант эчте ул, Надир шаһны сөнни итәрмен, кабул итмәсә үтерермен дип.

Кыскасы, Надир шаһ гаскәре белән зур сугыш булды. Бер ел сугышты, нәтиҗәдә, Надир шаһны җиңде, башын кисте, ә шәһәрен җимерде. Китеп Һиндстан чигенә хәтле Кызылбаш шәһәрен харап итте. Кайтып килгәндә, юллары һерат шәһәренә туры килде, Һерат падишаһы хәзрәте Аксак Тимерне гаскәре белән каршы чыгып алды. Шәһәргә кергезделәр, ике ай кунак булды. Соңыннан бер кичә төшендә Хызыр галәйһиссәлам Аксак Тимер хәзрәтнең төшенә керде. Әйтте: «Әй минем йөрәккәем, углан! Тиз юлга чык, Истанбулга бар. Аларның солтаны ир балалар белән зина кыла, каһвә эчеп, тәмәке тарта, җәмәгать намазларыннан калалар. Өйләрендә дә биш тапкыр намазны вакытында үтәмиләр. Аның шәһәрендәге галимнәре дә үзе кебек, ал арны ул гамәлләреннән тәүбәгә өндә»,– диде. Иртә торгач, бу төшне Һерат падишаһына сөйләде, саубуллашып, гаскәре белән Истанбулга юнәлде. Истанбулга килгәч, Истанбул солтаны Мәһди Солтан кала капкаларын бикләде. Илче җибәрде: «Син мөселман, ни өчен минем белән сугыш кыласың»,– диде. Аксак Тимер әйтте: «Син ир балалар белән зина кылудан,

www.darulkutub.com

кәҗә тәкәләрен сөзештерүдән һәм ат белән намазга йөрүеңнән тәүбә ит. Шулай ук синең галимнәрең дә мондый ярамаган эшләр белән шөгыльләнә, алар да тәүбә итсеннәр, мин сезнең белән сугыш һәм талаш кылмам, чөнки мин илһам белән сезгә килдем»,– дип җавап язды. Хәлифә бу җавапны галимнәренә күрсәткәч, галимнәре җавап бирделәр: «Без бу Аксак Тимерне изге һәм фазыл галим дип белә идек. Бу һәм бер шайтан икән. Илһам белән, безне гөнаһлылар дип, сугышырга килгән, илһам безнең мәзһәптә катгый дәлил түгел, без сугышырга тиеш», – дип сугыштылар.

Кыскасы, Аксак Тимер хәзрәте боларның җавабыннан елады, мин Хызыр галәйһиссәламне төшемдә күргәнгә һәм аның әйтүе буенча килеп бәхәстә җиңелдем дип, кичке намаздан соң елап ятты. Төшендә Рәсүл галәйһиссәламне күрде. Рәсүл галәйһиссәлам әйтте: «Йә Мир Тимер, Хызырның сиңа төштә күреп әйткәне хак. Истанбуллыларның ул гамәлләрне кылганы хак. Бу кичә Аллаһы Тәгалә ул ир балалар белән зина кылган Солтанның һәм егерме галимнең җенси әгъзаларын печте», – дип, Мир Тимернең хәзрәте торып, тәһарәтләнеп, Аллаһы Тәгаләнең кодрәтләренә таң-гаҗәпкә калып торды. Уйлап торды, иртә белән торып, галимнәрен җыйды, бу төшне сөйләде. Галимнәр бу төшкә хәйран калдылар. Галимнәреннән берсе әйтте, исеме Гали Кошчы иде: «Бу Истанбулда минем бер таныш галимем бар, Давыт әфәнде. Сәгъдетдин Тәфтазани хәзрәтләрендә бергә дәрестәш булып алты ел бергә тордык. Минем белән бергә күп заман тоз-икмәк ашады. Истанбулда аннан белемлерәк галим юк. Әгәр аның да җенси әгъзасы печелгән булса, миңа әйтер»,– диде. Мир Тимер әйтте: «Йә әфәнде, шәһәр капкалары бикле, син кайдан кереп белерсең?» – диде. Гали Кошчы әйтте: «Инша Аллаһы Тәгалә, белербез»,– диде. Мир Тимер әйтте: «Үзең белгел»,– диде.

Кыскасы, Гали Кошчы хәзрәтләре бер төндә, фәкыйрь киемнәрен киеп, Мир Тимернең гаскәреннән Истанбул каласының туры капка ишегенә килде. Каравылчылар әйттеләр: «Син кем, нинди кеше син?» Гали Кошчы әйтте: «Мин Давыт

әфәнденең колы, Дагстанда сатып алган иде. Мине Тәфтазан авылында укыган вакытта бер төркестанлы хаҗи агу биреп, алдап, сине угыл итәм, дип алып китте. Ахыр мине, колым дип, Кокандта сатты. Ул Коканд хуҗам – Аксак Тимернең гаскәр башлыгы, мине үзенә хезмәт итәр өчен алып килгән иде. Бу кичә уңышка ирештем: качтым. Хәзер ишеттем, Давыт әфәнде Истанбулда, имеш. Мине пәйгамбәребез хакына калага кертегез. Мин Давыт әфәндегә керим, аннан бәхиллек сорыйм»,– диде. Каравылчылар әйттеләр: «Давыт әфәнде – «Айа Суфия» мәчетенең имамы, шәһәребездә аннан белемлерәк кеше юк. Аның колы булсаң, йортын күрсәтербез»,– диделәр. Крепость (стенасы) башыннан аркан ташлап, кала эченә кергезделәр. Давыт әфәнде йортын күрсәттеләр. Таң атканчы, Гали Кошчы хәзрәтләре хәрам капкасында торды.

Кыскасы, мөәзиннәр иртә намазына азан укыганда, иртә намазына чыкканда, Гали Кошчы хәзрәтне Давыт әфәнде хәрам капкасында күрде. Каты елады һәм әйтте: «Йә дустым, бу заманга хәтле кайда булдың, аерылганыбызга утыз ел булган», – дип, икесе елаштылар. Мәчеткә бардылар. Мәчеттән кайтып, Давыт әфәнденең өенә керделәр. Төрле ашамлыклар ашадылар. Каһвәне хәзерләп, савытлары белән Гали Кошчыга куйды. Гали әйтте: «Мин бик туйдым, миңа каһвә кирәкмәс, – диде, – икенчедән, шәехебез суфи Деһкани буенча, бу исерткечләр белән аш ашау һәм эчү – гөнаһ»,– диде. Давыт әфәнде әйтте: «Алай булса, бер зур савыт белән бирәм, бу – каһвә. Безнең Румда моннан кадерле нәрсә юк,– диде.– Чөнки бу ризыкны эшкәртергә ярдәм итә, йокыны һәм җенси дәртне тыя»,– диде. Гали әфәнде әйтте: «Мин авыр йөк булырлык һәм авыр эшкәртерлек ризык ашамадым. Йә нигъмәт хуҗасы Давыт әфәнде. Истанбуллыларның, каһвә эчә-эчә, җенси әгъзалары юкка чыккан дип ишеттем. Бу вакыйга чынмы яки бер әдәпсез шаяннан чыкканмы? Безнең Төркестан илендә бу хәбәр халык телендә киң таралган», – диде. Давыт әфәнде башын түбән салды, оялып, маңгаеннан тир чыкты. Әйтте: «Йә дустым, хәбәрең дөрес, әмма таралган дигәнең – ялган. Белдем (ки), син Мир

www.darulkutub.com

Тимер хәзрәтенең гаскәреннән. Минем үземдә ул вакыйга юк»,– диде. Кичә диванханәдә кәгазьләре күренде. Солтанның һәм егерме галимнең җенси әгъзалары юкка чыккан. Табиблардан сорадылар: «Бу вакыйга бармы, бу нинди авыру сәбәпле, әшәке әйберләрнең кайсыннан яисә бүтән әйберләрдәнме?» – дип сорадылар. Алар җавап бирделәр: «Әшәке әйбердән түгел, бер изгенең могҗизасыннан». Моннан элгәре биш ел элек Казыйзадә хәзрәтләре, тәмәке һәм каһвә хәрам, дип фәтва бирде һәм язу язды. Аны ошбу Солтан Мәһди шәһәрдән кудырды. Әйтте: «Бар, син Госманлы мулласы, синнән фәтва кем сорый»,– дип. Йөзләренә кара ягып җибәрде. Табиблар әйтәләр: «Казыйзадә хәзрәтенең сулышыдыр, башка җаваплары юк», – диде. Мир Тимернең Гали Кошчы хәзрәтләре таныды: «Әйе, мин – Мир Тимернең имамы», – диде. Вә һәм Мир Тимернең төш күргәнен, үзенең шәһәргә ничек кергәнен сөйләде. Давыт әфәнде аны алты кичә кунак итте. Җиденче кичәдә әйтте: «Сине ничек гаскәргә җибәрим, кала капкалары бикле», – диде. Гали әйтте: «Син кайгырма, хәсрәтләнмә, керткән Ходა чыгарыр, туфрак монда язылмаса», – диде.

Кыскасы, сигезенче төндә Гали әйтте: «Йә әфәнде, бу шәһәрдә синең дошман күргән кешең бармы?» – диде. Давыт әфәнде әйтте: «Ул сиңа нигә кирәк?» – диде. Гали әйтте: «Бар булса, барлыгын әйт, хикмәтен сиңа әйтермен»,– диде. Давыт әфәнде әйтте: «Әйе, бар, күршемдә бер Нияз исемле Хуҗа. Эше гел ир балалар белән зина кылуда һәм кәҗә тәкәсе сөзештерүдә. Мин ул Хуҗага яхшы эш эшләргә өндәдем. Ул мине сүкте, сезне Казыйзадә кебек шәһәр дән чыгарырмын, малыңны мал йортына салырмын, дип ант эчте. Чөнки Истанбулда ул Хуҗа кебек бай юк һәм Солтан Мәһдигә аннан якын кеше юк. Аннан моның өчен куркамын», – диде. Гали әйтте: «Таңда мине колым дип базарга алып чыгып, ул Хуҗага сат», – диде. Давыт әфәнде әйтте: «Бу ничек, ярар», – диде. Гали әйтте: «Минем үземнең акылым бар һәм яшем җиткән. Чөнки мин синнән кечкенә вакытта күпкүп белем алдым. Мулла булдым. Имам Малик мәзһәбенчә ярый. Инша Аллаһы Тәгалә, мин сине дошманыңнан коткарырмын»,– диде.

Кыскасы, иртәгесен, кол киеме кидереп, Гали әфәндене базарга алып чыкты. Базар әһеле Давыт әфәнденең базарга чыкканына хәйран булдылар, чөнки һичкайчан базарга чыкканы юк иде. Хәзрәте Гали, аның йөзенә Аллаһы Тәгаләнең юмартлыгы иңсен, сүзенчә: «Бу егет минем колым, миннән китеп күп йөреп кайтты, хәзер таныдым, синең колың дип. Мин күп елдан бирле хезмәттә тормадым, миңа бераз, яшәр өчен, акча кирәк була», – диде. Колдан сорадылар: «Син Давыт әфәнденең колымы?» – дип. Гали әйтте: «Гали, аның йөзенә Аллаһы Тәгаләнең юмартлыгы иңсен, Гали сүзенчә, кол мин»,– дип. Моның мәгънәсен белмәделәр. Гали Кошчыны Давыт әфәнде үзенең күршесе Нияз Хуҗаның улына сатты. Нияз Хуҗаның улы өенә алып кайтты. Нияз Хуҗага әйтте: «Йә ата, Давыт әфәндедән бер кол алдым»,– диде. Нияз Хуҗа әйтте: «Кайда ул кол?» Улы аны китереп күрсәтте. Нияз Хуҗа әйтте: «Әй кол, нинди һөнәрең һәм нинди кәсебең бар?» Кол әйтте: «Кием тегү һәм башмак тегү гыйлемлеген беләм»,– диде. Нияз Хуҗа әйтте: «Бик яхшы, миңа шундый кол кирәк иде»,– диде. Галине тегү эшенә кушты. Моның белән җиде тегүче колы булды. Болар тегү теккәндә, Гали Кошчының Мир Тимердән аерылуына өч ай булды. Мир Тимер хәзрәт елады, бу галимне кайсы угры үтерде икән дип, хәсрәттә булды. Монда исә Гали хәзрәтләре бу алты егет белән кием тегәләр иде. Җомга көн Нияз Хуҗа җомга намазына киткән вакытта, боларның тегү тегә торган өенә ун яшәр углан елап керде. Әйтте: «Йә агалар, бар микән арагызда хат танучы»,– диде. Гали Кошчы әйтте: «Әйе, мин беләм»,– диде. Углан хатны бирде, Гали укыды. Хатта язылган иде: «Бу җенси әгъзасы печелгән, икейөзле һәм Аллаһы Тәгалә алдында хәерче, йә Гали, син аны хуҗасы белән бергә үтер һәм уллары Халид белән Вәлидне дә һәлак ит. Чыннан да, мин сездән риза. Соңыннан туры юлдан баручыга сәлам». Гали сорады: «Бу хатны сиңа кем бирде»,– диде. Углан әйтте: «Төшемдә пәйгамбәребез галәйһиссәлам бирде, – диде. – Тегүчеләр арасында кайсысы хат таныса, ул укып бу хат эчендәгечә гамәл кылсын, – диде. – Мин өммәтләремнән ризамын», – диде. Ул вакытта Гали әйтте: «Йә углан, син ни өчен

елыйсың?» – диде. Углан әйтте: «Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең матурлыгын күреп елыйм, вә икенче анамны төшемдә күреп елыйм, оҗмах киемнәре киенеп, мине ике имчәк арасына алып каты сөйде, маңгаемнан үпте. Бу ике кеше күргәнем кебек дөньяда башка күркәм кеше күргәнем юк иде. Минем анамнан аерыласым килмәде, өнем дип белдем, ә бу төшем икән. һәм анам тагын әйтте: «Өч көннән соң миңа килерсең». Бер кисәк нигъмәт бирде. Бер алтын сарайның эчендә иде. Әйтте: «Бу сарай минеке, моның кебек тагын кырык җирдә сарайларым бар. һәрбер сарайларымда чишмәләр балдан вә судан, һәм сөттән агалар», һәм ул кисәкнең тәме хәзер дә авызымнан китми. «Йә ага, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сиңа нәрсә боерган?» – диде. Гали әйтте: «Әй угыл, безгә әмер ителгән, бу угланның күргән төше рас, аны аңлатып, намазыгызны соңга калдырмагыз»,– дигән. Углан әйтте: «Әй ага, хата сөйләрсең, бу Хуҗа – минем атам. Минем анамны ир балалар белән зина кыйлудан тыйган өчен шәһит итте. Бу Хуҗаны ике агам белән үтерергә кушкан. Син кол түгел, син бу җиһанның олы галимнәреннән. Ике агам хатыннарын ир балалар белән зина кылудан тыйган өчен шәһит иттеләр. Безнең Истанбулда Солтан Мәһди, ир балалар белән зина кылудан тыйган өчен, алты хатынын үтерде», – диде. Гали Кошчы әйтте: «Йә, углан, бу гамәлләрне кайчан кылабыз?» – диде. (Углан) әйтте: «Сез сишәмбе көн кыласыз, чөнки мин дүшәмбе көн кабер иясе булам»,– диде. «Сез сишәмбе көн төн ярымында кыласыз», – дип, атасының бүлмәсенә кереп китте. Гали Кошчы хәзрәтләре юлдашлары белән киңәшкәч, Пәйгамбәребез кушкан эшне үтәргә сишәмбе көн кичне көттеләр.

Кыскасы, Нияз Хуҗа җомгадан кайтты. Шимбә көн углан авырды. Якшәмбе көн ахшам намазыннан соң дөньядан кичте. Кичлек белән кабергә куя алмадылар, дүшәмбе көн кабергә куйдылар.

Кыскасы, бу җиде егет кичке намаздан соң, Аллаһы Тәгаләгә күп мактаулар һәм Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер-догасы һәм сәламе ирешсен) салават әйтеп, ул Нияз

Хуҗаның бүлмәсенә керделәр. Куенында бер малае бар иде, малае белән һәр икесен үтерделәр. Нияз Хуҗаның баш очында һинди кылычы бар иде. Аны Гали Кошчы хәзрәтләре алды. Олы улы Халидны малае белән үтерделәр. Аннан кече улы Вәлидне малае белән үтерделәр. Алтын-көмешләрен алып, төн ярымында чыгып киттеләр. Нияз Хуҗаның йортына ут салдылар. Барып каланың Бирдебәк дигән капкасына килделәр. Каравылчылар әйттеләр: «Сез нинди кешеләр?» Болар әйттеләр: «Без Нияз Хуҗаның коллары, хуҗабызны үтердек, алтын-көмешләрен алдык. Ике улын да үтердек. Хәзер Аксак Тимер гаскәренә керәбез. Сез бездән риза булырлык алтын-көмеш алыгыз»,– диделәр. Бәс, каравылчылар башлыкларына барып әйттеләр. Башлыклары, килеп, болардан күп мал алды. Каравылчылар да риза булырлык кадәрле малларын алып, боларны кала түбәсеннән аркан белән төшереп озаттылар.

Кыскасы, Гали Кошчы хәзрәтләре яраннары белән Аксак Тимер гаскәренә керде. Башыннан үткән хәлләрне һәм Истанбулда ничә төрле гөнаһлы эшләр эшләнелүен һәм женси әгъзалары печелгән галимнәрнең исемнәрен язып, һәм углан биргән пәйгамбәребезнең хатын бергә теркәп, Мир Тимер хәзрәтнең алдына салды. Мир Тимер хәзрәт: «Изге Рәсүлулла дөресен әйткән, һәм без моңа шаһитлар», – дип, рәхмәт сәҗдәсе кылды. Гали Кошчы хәзрәтләренә күп бүләкләр бирде, дәрәҗәсен югары күтәрде. Кыскасы, Аксак Тимер хәзрәтләре Солтан Мәһдигә илче җибәрде. Бу вакыйгаларны язып, үгет һәм нәсыйхәт биреп, тәүбәгә боерды. Солтан Мәһди Мир Тимер илчеләренең колакларын кисеп җибәрде: «Барыгыз, солтаныгызга әйтегез, безнең женси әгъзалар хакында сүз чыга башлаган. «Артын» бирсен, безнең женси әгъзаларыбыз барлыгын-юклыгын белер»,– диде.

Кыскасы, бу ике шаһ җиде ел сугыштылар. Нәтиҗәдә Аксак Тимер Истанбулны хәйлә белән алды. Солтан Мәһдине төрлечә газаплап үтерде. Ул егерме галимен астырды. Үлгәннән соң оят урыннарын карадылар, печелгәнен күрделәр – шоп-шома. Бот төпләренең ите белән тигез, бары тик сидек юлы гына калган –

инә сыяр кадәрле тишек. Солтан Мәһдинең улы Мәсгудне солтан итте. Алты ай Истанбулда калды. Алты айдан соң гаскәре белән Ширванга китте. Ширванда ничәмә төрле гөнаһлы эшләр булса, барысын бетерде. Ширван йортыннан Дагстан йортына китте. Аннан Чистай каласына килде. Аның ханы белән бик дус булдылар, әйтте: «Йортыгыздан бөек галим Тәфтазани еракмы?» – диде. Әйтте: «Тугыз көнлек юлдыр, Андрай каласында тоткынлыкта», – диде.

Кыскасы, Аксак Тимер хәзрәт Андрай каласына гаскәре белән китте. Көннәрдән бер көн Андрай каласына җиттеләр. Шәһәр капкаларын бикле күрделәр, һичбер хәйлә белән керергә белмәделәр. Ханга илче җибәрде: «Ни өчен капкаларны бикләдең?» – (дип). Хан илчеләр артыннан язу җибәрде: «Син карак. Сиңа ни өчен капкаларыбызны ачыйк. Ачыксагыз – китәрсез, минем калам эчендә җиде еллык азык бар»,– дип җавап язды. Мир Тимер хәзрәт дәхи җавап язды: «Минем синең шәһәреңдә эшем юк, һәм мин карак түгел. Аллаһы Тәгаләнең әмере белән бозыклык һәм гөнаһлы эшләрне бетерәм. Син бары тик күренекле галим Тәфтазани белән мине күрештер. Мин аның мөбарәк йөзләрен күрермен һәм дәрес алырмын»,– дип язды.

Кыскасы, хан янә җавап язган: «Бар, юлыңда бул, синең кебек каракка ни галим, ни дәрес»,– дип. Аксак Тимер хәзрәте, ачуланып, иртәгесен гаскәренә әмер итте: «Укларыгызны һәм тупларыгызны калага атыгыз, чөнки бу хан мине юл кисүче дип хөкем иткән. Ни өчен бөек галим Тәфтазани миннән качып, авылын ташлап калага кереп бикләнгән. Шаять хан белән сүзләре бердер»,– дип, ачуланып, калага укны һәм тупны җибәрделәр. Шәһәрнең капкаларын җимерделәр, эченә ярсып керделәр. Ханны тоттылар. Мир Тимернең алдына китерделәр. Хан тәүбә итте, шәһәрне кире үзенә бирде. Бөек галим Тәфтазанины үзе белән алып китте. Ул вакытта Тәфтазани сиксән яшендә иде.

Кыскасы, юллары Әстерханга килеп чыкты. Анда һәм алты ай калдылар, кышладылар. Яз җиткәч, Шәһри Болгарга ирештеләр.

Кыскасы, безнең болгар халкы да бозыклык һәм фетнә белән мәшһүр иде. Галимнәре шәригать хәйләсе белән риба алуга фәтва биргәннәр иде. Зина һәм кеше үтерү кебек башка эшләре күп иде. Әмма Аллаһы Тәгалә саклаган иде, ир балалар белән зина кылу юк иде. Җомгадан калдылар, биш вакыт намаздан соң укый торган догаларны калдырдылар. Бүзә хәләл дип фәтва бирделәр. Шәһәр юк дип җомга намазын калдырдылар. Имам Шәфигый сүзе сүз түгел дип, аны сүктеләр. Гает намазын куйдылар, Аллаһы Тәгаләгә фетнәче булдылар. Аллаһы Тәгалә шуның өчен Аксак Тимер хәзрәтне җиңүче итте. Ул заманда Болгарда Бикчура хан иде. Мир Тимер хәзрәт Бикчура ханга илче җибәрде: «Ни өчен җомга вә гает укымыйсыз?» – дип. Хан галимнәренә әйтте: «Мир Тимер хәзрәткә ничек җавап бирерсез?» – дип. Галимнәре әйттеләр: «Китаплар белән җавап бирербез»,– дип. Болгар галимнәре җавап бирделәр: «Бу Болгар шәһәр түгел»,– дип. «Викая» һәм «Һидая» һәм башка еш кулланыла торган текстларның гыйбарәтләрен салдылар. Мир Тимер хәзрәте җавабында язды ки: «Сез ни өчен «Валваҗа», «Тимер таш» һәм «Кания» һәм башка китапларга карамыйсыз, сезгә авылда җомганың тиешлегенә әмер итмешләр. Тагын «Алты хәдис» китапларында шәһәр шарт булу күренмәде»,– диде. һәм дә «Дөррел Асар» дигән китапта «Шәһәрнең Җамигъ мәчетендә генә җомга уку һәм йөзне көнчыгышка бору» дигән сүзләр – хәдис түгел, бары тик сәхабә сүзе генә. Ул сәхабә билгесез, кем икәне билгеле түгел һәм бу хәдис «Алты хәдис» китабында табылмады. Шулай ук «Дөррел Асар» шәрехендә әйтелә ки, күренекле имам Ногман бине Сабит хәзрәтләре, бу урында имам Әгъзам хата ясый, дип, «Мөҗтәһиднең хатасы гафу ителә», – дип. Шулай ук Рәсүл хәзрәтләре җомга намазын һәм гает намазын үзеннән гайре өч кеше белән укыды, дип. һәм башка шундый җаваплар язып, Болгарга илче җибәрде. Болгар галимнәре әйттеләр: «Син Имам Әгъзамны хатага санадың, «җомга һәм көнчыгышка борылу тиеш түгел» дигән сүзне хәдис түгел, дидең. Без «Дөррел Асар» дигән китапның сүзен тотмыйбыз. Без төгәл белдек, ул китап «могътәзилиләрнеке».

Без сине бу вакытка хәтле изге кеше дип белер идек. Ә син шулай ук «могътәзили» икәнсең».

Белеп торыгыз: «Дөррел Асар» дигән китап «могътәзили» түгел. «Алты хәдис» китабы дигәнем: берсе – «Сахихе Мөслими», икенчесе – «Сахихе Бохари», өченчесе – «Мәсабих», дүртенчесе – «Мишкят», бишенчесе – «Мөбарәк», алтынчысы – «Мөшарәк». Ул заманда безнең Болгарда Харәзем һәм Бохара галимнәре кәлям гыйлеме белән һәм мантыйк, һәм фәлсәфә фәннәрен укырлар иде. Чөнки бөек галим, остазыбыз Тәфтазани «Гакаид шәрхен» язды. Аның укучылары мулла Хайали һәм мулла Әхмәд Җәнди хәзрәтләре «Хашия»сен төзеделәр. Мантыйк фәнендә «Тәһзиб»не төзеде, һәм аңа барча шәкертләре, галимнәре «Шәрех» язып, кайсылары шәрехләргә «Хашия» язып, бу өч өлкәдә хәдис фәне гамәлдән чыкты. Хикмәт фәне белән сүз көрәштереп, «Хикмәтел Гайн» һәм «Хикмәтел Һидая» уку һәм укыту белән мәшгуль булдылар. Бу хәдис фәне Дагстан йорты белән Мисыр йортында калды. Бу өч өлкә галимнәре хәдис фәнен белмиләр иде. Бәс, Аксак Тимер хәзрәт, Болгар (галимнәренең) бу сүзләрен ишетеп, гаскәренә әмер итте: «Укларыгызны һәм тупларыгызны атыгыз, Бөек һәм Олуг Аллаһ белән ант итәм, бу Болгар шәһәренең урынын юк итеп харап итәрмен»,– дип ант эчте. Өч көн эчендә шәһәребезне харап итеп юкка чыгарды. Гаскәренең санын Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәс иде. Таш калабызны туп белән ваттырып Волга төбенә салды. Бикчура ханның унике вәзире белән башларын кистерде. Энҗе кебек кызларын һәм хатыннарын, кол итеп, гаскәрләренең башлыкларына бирде. Утыз алты галимне дарга астырды. Калган халыкка бер атна эчендә читкә китәргә боерды. «Бу урында тормагыз»,– дип хөкем чыгарды.

Җанбакты карт нәселе белән чыкты, Җанбакты авылы булды. Вә янә безнең Мөслим бабай нәселе белән Ташбилге елгасына төште, Ташбилге авылы булды. Тәтеш карт нәселе белән Агыйдел ярына чыкты, Тәтеш авылы булды. Мамадыш авылы белән Нократ иделенә төште, Мамадыш авылы булды. Кайберләре Казан суының тамагына Яңа Казанга күчеп киттеләр. Кайсыла-

ры Уралның көньяк-көнчыгышына, Сарайчыкка күчтеләр. Кайсылары кыргыз халкына керделәр. Галәмнең чиксез якларына таралдылар.

Кыскасы, тарих һиҗрәтнең сигез йөз алтмышынчы елында мөхәррәм аенда, җомга көн, җомга намазыннан соң, румия аеның Җүзәнең егерме җиденче көнендә (март аеның) Болгар харап булып юкка чыкты, дөньяда иseме калды: «Чынлап та, без Аллаһыныкы һәм, чынлап та, Аңа кайтабыз» (Коръән, 2:156). Ул заманда Болгарны харап итте. Халкын галәмнең төрле ягына таратты. Тагын Агыйдел ярында Кашан дигән шәһәр бар иде. Аны һәм шәһәрнең нигезен бетереп, шәһәр халкын галәмнең төрле ягына таратты.

Кыскасы, Мир Тимер хәзрәте, Болгарны һәм Кашанны харап иткәч, сугышыр өчен, Мәскәүгә китте. Ул вакытта Мәскәүдә хан урыс Иван Вачилий улы иде. Аны исламга өндим дип, гаскәре белән күчте. Көннәрдән бер көн урысның Владимир дигән каласына җиттеләр. Анда кундылар. Кич белән Хызыр галәйһиссәлам Мир Тимер хәзрәтенең төшенә керде. Әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән Мәскәү йортын дингә өндәргә сиңа әмер юк. Кайт, фәкыйһ Әбүл-Ләйс Сәмәрканди кабере эчендә сиңа урын. Инде кабереӊ анда», – дип, күзеннән югалды. Мир Тимер хәзрәте, иртүк торып иртә намазын укыгач, бөек галим Тәфтазани хәзрәтенә төшен сөйләде. Бөек галим Тәфтазани әйтте: «Йә солтаныбыз, әмер булмаса – бармыйк, чөнки ләгънәт төшкән шайтан пәйгамбәрләр сурәтенә керә алмас».

Кыскасы, ул көн якшәмбе көн иде. Гакраб (чаян) аеның әүвәлге көне урысларның Покрауы иде (23 октябрь). Чиркәүләренә теләү әйтергә кергән көннәре иде. Мир Тимер хәзрәтләре боларның чиркәүләре янына килде. Чиркәү күршесендә урысның кара байталы бар иде. Урыслар чиркәүдән чыкканда, урысның шул кара байталын алып, ике арт ботыннан тотып атты. Чиркәүнең манарасы егылды. Ул байтал чиркәүнең икенче ягына чыгып, сөякләре көл булды. Ул байтал төшкән җирдән Аллаһы Тәгалә бер күл чыгарды, Аксак Тимер гаскәре ул күлдән су алып тәһарәт алсын өчен. Чөнки ул Владимир

каласының елгасы юк иде. Урыслар кое белән тереклек итәләр иде. Бүгенге көндә дә ул мөбарәк күл бар. Урыслар аны шакшы күл дип эчмиләр. Ул чиркәүгә дә кермәсләр, Аксак Тимер пычратты дип.

Кыскасы, Владимир каласыннан Сәмәркандка кайтырга йөз бордылар. Юллары Яңа Казанга төште. Ул заманда Яңа Казанның ханы Илһам хан иде. Мир Тимер киләсен ишетеп каршы алды. Яңа Казанга керделәр, гаскәрләрен тирә-якка тараттылар. Ике ай үзе вәзирләре белән, бөек галим Тәфтазани белән һәм башка галимнәр белән торды. Үзе вәзирләре белән тирә-якта булган табигыйннар каберләренә зиярәт итте. Әүвәл Казан суының башында булган табигыйн Иштирәк Байтирәк улына. Курсада Гадел Абдул улына. Кәче илендә Зөлмөхәммәд Мөхәррәм улына. Янә Гайшәбикә авылында Гайшәбикәнең үзенә, атасы Хаҗи Әрәмле каберенә, улы Таҗетдин әфәндегә. Нократ Шушмасында булган Хәсәншәех Кадер улына. Балтач Нәдер улына. Салавыч Абайдан улына. Исмәгыйль Абзан улына.

Зөя тамагында Ильяс Муса улына. Касыйм Ибраһим улына. Уҗым авылында Фәйзулла Гобәйдулла улына. Күк Күз авылында Колмөхәммәд Динмөхәммәд улына. Надир шаһ Сәлим Ишкенә улына. Бикташ авылында Тимеш хаҗи Солтан Морад улына. Ибраһим Илһам улына. Симеш Килдебай улына. Бу барча табигыйн (аларның барысына Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын) күбесенә Яңа Казанда торып зиярәт кылды.

Кыскасы, Мир Тимер хәзрәте Казаннан Содумга, ягъни Алабуга шәһәренә килде. Ул заманда Алабуганың ханы Илбакты хан улы иде. Үзе һичбер дин белмәгән хан иде. Аны дингә чакырды, кабул итмәде. Ул Содум бер зур шәһәр иде, аның астын өскә китерде. Шәһәрләрен һәм калаларын җимереп Агыйдел эченә куйды. Үзләрен әсир итте, калганнарын тирә-яктагы галәмгә таратты.

(Үзе) Туймы тамагында булган табигыйннар каберен зиярәт итте. Әүвәл Акбаш кызына зиярәт итте. Кирсан Илмәмәт улына, Әләмгол Муллагол улына, Айдар Аит улына. Юлдаш

Мәскәү улына. Аннан Иделне чыгып, Мәләкәс авылының Сәийд Сәйдар улына, Тукбай Байгол улына, Җанбакты Уразбакты улына, Иманай Юнай улына, Ишбирде Тукбирде улына, Мәләкәс авылында ятып зиярәт итте. Гаскәре Агыйдел буенда Агый халкында ятты.

Кыскасы, кыш көне булды, кар явар вакыт булды. Ирнә суының тамагы Зөягә коя. Ул урында Бәйраш ханның улы иде. Аксак Тимер аңа хат язды: «Мин сиңа кышларга киләм», – дип. Бәйраш хан хат язды: «Әйдә, солтаным, Аксак Тимер хәзрәте, баш өсте. Атабыз-анабыз сиңа фида булсын, кабул итәрем, туйдыручы Аллаһы Тәгалә»,– диде. Бәйраш хан Баграш суы буенда, ул Ирнәгә коя. Ул суның бер биек тавы бар. Ул тауның башына бер олуг сарай төзеделәр. Ул сарай тәмам булгач, Мир Тимер хәзрәтне өндәде, гаскәре белән килде. Баграш суының буе гаскәр булды. Бәйраш хан, Зәйдән гаскәре белән каршылап, тау башындагы сарайга китерде һәм кергезде: «Колың Бәйраш синең хәзрәтеңә кышлык сарай төзеде, кабул итсәгез – торырсыз»,– диде. Аксак Тимер сарайны хуплады, Бәйраш ханга күп хәзинәләр бирде.

Кыскасы, ул кыш анда кышлады. Мулла Хафиз әт-Ташкәнди каберенә зиярәт итте. Минзәлә суының тамагы Ак суына коя. Анда Мостафа ханда кунак булды. Күренекле суфи Хуҗа Бәйрәм каберенә зиярәт итте. Чаллы суы тамагында Агыйдел ярында Мәүлед Хуҗага зиярәт итте. Аннан Байчура Чирмеш авылында Хуҗа Әмир Кәлалга зиярәт итте.

Кыскасы, кайтып, Баграш суы буенда Бәйраш хан төзегән сарайга керде. Кышладылар. Җүзәнең уникенче көнендә Аксак Тимер гаскәре белән кузгалды. Бәйраш хан белән саубуллаштылар. Бәйраш хан, аңа ияреп, Акның Тугаш хан авылында ике бик олы табигыйн каберләре бар иде: бере – Морадым Хафиз, икенчесе – Мөхсин Хафиз Юлдаш уллары, анда хәтле бергә барып зиярәт итте. Аннан Мир Тимер хәзрәтләре саубуллашып Сәмәркандка китте, Бәйраш хан Зәйгә кайтты.

Кыскасы, Аксак Тимер хәзрәтләре Уралны чыгып кыргыз халкына керде. Ал арны дингә өндәде һәм төрекмән халкын

өндәде. Ислам кабул иткәннәргә йортларын бирде, үзләреннән хан куйды. Кабул итмәгәннәрне кол итеп әсир кылды.

Кыскасы, Аксак Тимер хәзрәтләре Сәмәркандта өч ел солтан булды. Дүртенче ел мөбарәк Рамазан аеның егерме җиденче кичәсендә җыелып Хәнәфи галимнәренең фәтвасы белән Кадер кичәсе иде. Мир Тимер хәзрәтләре мәңгелек йортка күчте. Бөек галим Тәфтазани гает көнендә вафат булды. «Әйтәләр, чынлап та, без Алланыкы, чынлап та, Аңа кайтачакбыз». Тарих һиҗрәтнең тугыз йөз икенче елы иде, Эт елы иде.

## ЧОРНЫҢ БЕРДӘНБЕРЕ ТУРЫНДАГЫ ФАСЫЛ

Остазыбыз бөек галим Тәфтазани тарих һиҗрәтнең сигез йөз егерменче елында дөньяга килде. Элекке заманда Тәфтазан белән Андрай каласы бар иде, Тәфтазан бер мәхәллә иде. Бер заман Андрай каласына ваба керде. Ягъни чума белән шәһәрнең өчтән икесе һәлак булды. Хәзер авыл булып калды. Бөек галим Тәфтазани егерме ике яшендә бөек галим дәрәҗәсенә иреште.

Әүвәл «Тасрифы Зәнҗани»га шәрех язды. Егерме дүрт яшендә «Мөтаввәлне» төзеде. Алтмыш яшендә Харәземгә барып дәрес әйтте. Өч ел анда «Тәлвих Хашияи Тәүзыйх»ны төзеде һәм «Тәһзибе мантыйк»ны төзеде. Харәземнән кире Тәфтазанга кайтты. Ахыр гомерендә сиксән яшенә җиткәндә, Мир Тимер хәзрәтләренең имамы булды. «Шәрхе Тәлхыйсы Мөтаввәлне» Мир Тимер хәзрәт өчен кыскартты. Чөнки Аксак Тимер хәзрәте үлгәнче дәрес алмакны һәм сабак алмакны куймады. Үлгән вакытта, «Мишкят» шәрифтән Хаҗ китабын укыганда, 63 яшендә иде. «Әйтәләр, чынлап та, без Алланыкы, чынлап та, Аңа кайтачакбыз».

Бу рисаләгә «Тәварихы Болгария» дип исем бирдек. Фәкыйр Хисаметдин бине Шәрәфетдинне хәер-догагыздан онытмасага иде. Тарих һиҗрәтнең тугыз йөз туксан икенче елында Ташбш авылында мөхәррәм аеның 15 нче көнендә Җүзәнең һәм уньи көнендә Тычкан елында бу рисалә тәмам булды.

www.darulkutub.com

# ТЕКСТНЫҢ ТРАНСКРИПЦИЯСЕ

## РИСАЛӘ' И ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЙӘ ВӘ ЗИКРЕ МӘҮЛӨНА ХӘЗРӘТЕ АКСАК ТИМЕР ВӘ ХАРАБЕ ШӘҺРИ БОЛГАР

Бу китап Казан Университетының тәбыгханәсендә басма улынмышдыр Исхак Әхмәд Сафа углы Хөмзиннен хараҗаты илән 1902 нче елда.

Дозволено цензурою С.-Петербург 1 апреля 1902 г. Казань Типолитография Императорского Университета 1902.

## *ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЙӘ*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

Әлхәмдү лилләһи раббил-галәмин вәссаләтү вәс-сәлам галә рәсүлиһи Йөхәммәд вә алиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Әмма бәгьдү, бу фәкыйрел-хәкыйрь, калилел бидагать вә кәсирел-бәталәт Хисамеддин бине Шәрәфеддин әл-Болгари әйдер ки, хадисате шөһүре румийәнең бәйанләре вә хәвадис журлары Ситабе мәлхәмәдә[1] бәйан улынды, шәмди шөһүре гарәбийәнең исемләрене вә вәҗһе тәсмийәләрене, сәгыд вә нәхесләрене мөстәкыйлен бәйан әйләмәк ләзим улды. Вә дәхи кәвакибе сәбганең сәгыд вә нәхесләрене бәйан әйләмәк мөһим улынды вә дәхи бу китабә йазмак лязим улынды. Безнең Шәһри Болгарның мөселман улдыгы заманында сәхабә'и кирам ризванә Аллаһы

[1] Мәлхәмә – гарәпчәдән «героик поэма, эпопея» дип тәрҗемә ителә. Мөслиминең андый китабы булганмы, юкмы – билгеле түгел. М. Госманов авторның мондый китабы булуына шикләнә (Усманов, 1972: 150).

www.darul-kutub.com

Тәгалә галәйһим әҗмәгыйндән тәгълим вә тәхсыйль идән табигыйн вә табигатьләрне бәйан итмәк, вә анлардан соңра әүлийә'и гыйзам вә мәшаихы кирам бу дийарда «йәрдер, айларны бәйан әйләмәк әмре газыйм улынды. Вә анлар кайу йирләрдә вә кайу илләрдә мәдфүн улындылар. Бу китаб ике мәкалә үзренә улынды. Әммәкаләтел-үлә фи гаҗаибел-мәхлукат, вәл-мәкаләтес-санийә Мәкаматәт-табигыйн вәт-табигать. Бу китаб тәмам улынды Ташбилге карьсендә Шәһри Болгарның чурәсендә, тарих һиҗрәтнең тугыз йөз илле сигездә[2] галлямәи Тәфтазани[3] заманында ирде. Аның мәдрәсәсеннән укып ым заманында тәвабигы Болгарийәнең мәшаихләре, төрки теле берлә мәкамате табигыйндән вә гараибе галәминдән бер рисалә йазмага бойырдылар. Аларның илтимасларына имтисалән бу нөсхәнең тәсвиденә шоруг әйләдем.

### Әлмөкаләтел-үлө фи гажаибел мөхлукать
### Фасыл физ-заманы

Заманны буйлә тәгъриф итмешләрдер: «Әз-заман гыйбарәт ган микъдари ил-фәләкил-әгъзам». Йәгъни заман див кичә вә көндезнең килеб китдегенә дийерләр, әмма микъдары хәрәкәте әфляк иләдер. Корун. Корун мөнкасим улыр, аны вакыт дийерләр. Сәгадәт вә шәкавәт һәр икесе заман илә кәсеб улыныр.

### Фасыл фил-әййам

Йәүмел-җомга – сәгыддер, хаҗҗүл-мәсакиндер, вә йәүме васләтдер вә йәхме никахдыр, нитәк ки Адәм галәйһиссәлам илә Хәүва разыйаллаһү ганһа, вә Бәлкыйс илә Сөләйман галәйһиссәлам, вә Йосыф галәйһиссәлам илә Зөләйха, вә хәзрәте Муса галәйһиссәлам илә Сафура, вә хәзрәте Мөхәммәд

---

[2] Тугыз йөз илле сигез – милади белән 1551 ел.

[3] Тәфтазани – Сәгъдетдин Мәсгуд бине Гомәр әт-Тәфтазани (1322 – 1389/90), мәшһүр галимнең дин буенча язылган китаплары татарлар арасында бик популяр булган.

галәйһиссәм илә Хәдичә вә Гайшә разыйаллаһу ганһүмә җомга көн никах кыйлынды. Вә Адәм галәйһиссәлам дөнйага җомга көн килде вә җомга көн оҗмахга керде вә җомга көн оҗмахдан чыкды. Вә җомга көн алты кәз йөз бең адөмләрне Аллаһы Тәгалә җәһәннәмдәй азад идәр. Вә һәркем җомга көн тырнак киссә малы чук ула вә гомере зииадә ула.

Йәүмес-сәбет. Шимбә көн. Мәкер вә хәйлә көнедер вә йәүме нәхесдер, зира ки ул көн әмбийәләрдән алты кешейә тәшам улынды: бере Салих вә бере Нух, вә бере Гайсә, вә бере Муса, вә бере Мөхәммәд галәйһиссәламдер. Ләкин бу көндә ау ауламак мөбарәкдер. Вә һәркем шимбә көндә тырнак киссә бармагы мәҗрух ула.

Йәүмел әхәд. Йәкшәмбе көн. Гайде нисаридыр, дөнйа көненең әүвәледер. Ул көн гыймарәт башламак баглар вә агачлар дикмәк көнедер. Ул көн йире, вә нөҗүме вә арызы вә сәмаваты вә мәназил вә боруҗләре ул көн яратды. Вә һәр кем ул көн тырнак киссә, малының бәрәкәте китә.

Йәүмел-иснәйн. Дүшәмбе көн. Мөбарәк көндер. Хәзрәт рисаләтемез саллаллаһү галәйһи вә сәлләм ул көн тугды. Вә Җәбраил галәйһиссәлам ул көн вәхи килтерде. Вә һәм ул көн дөнйадан үтде. Вә җәмигъ өммәтләренең гамәлләре ул көн пәйгамбәрә гарыз улыныр. Вә дәхи Ибраһим галәйһиссәлам Кәгъбәне ул көн йабды. Вә Муса галәйһиссәлам Тура мөнаҗатә ул көн чыкды. Сәфәргә ул көн чыкмак мөбарәкдер. Ул көн тырнак кисмәк һәм мөбарәкдер.

Йәүмел-сөляса. Сишәмбе көн. Хайванатлары сишәмбе көн йаратды. Нәхес көндер, зира (ки) ул көн хәзрәте Хәүва хәйз күрде. Вә Кабил Һабилне үлтерде. Вә Җирҗис вә Зәкәрийә, вә Йахйа галәйһимүс-сәламләрне ул көн шәһит итделәр. Ул көн кан көнедер, хәҗамәт вә фәсыд ул көндә мөбарәкдер. Вә һәр кем ул көндә тырнак киссә, гамь вә госсадан кортымайа.

Йәүмел-әрбагa. Чәһаршәмбе көн. Камилел-хәйрдер, әмма хәммамә мөбарәкдер. Вә йәүме нәхесдер. Гуҗ бине Ганык, вә Фиргавен вә Нәмруд, вә Гад, вә Сәмуд кауме бу көндә һәлак улмышлардыр. Вә һәр кайу айның ахыр чәһаршәмбесе гайать

нәхсидер. Йуныс галәйһиссәлам бу көндә балык карнында мәхбус улды. Ибраһим галәйһиссәламне Нәмруд лә‌гыйн бу көн утка атды. Йосыф галәйһиссәлам бу көн зинданә дахел улды. Бу көн тырнак кисмәк һәм нәхесдер.

Йәүмел-хамис. Пәнҗешәмбе көн. Мөбарәкдер. Хак Тәгалә нуры вә нары, җәннәтне вә җәһәннәмне бу көндә йаратды. Вә таләбе хаҗат көнедер. Вә вакты бөкрәсендә бәрәкать берлән өммәте үзрә рәсүл галәйһиссәлам дога кыйлмышдыр: «Аллаһөммә, барик ли фи өммәти би бөкрәтил-хамиси вә сәбтиһим»,– див. Рәсүлулла галәйһиссәлам ул көн Мәккәне ачды. Вә Муса галәйһиссәлам Мисырны ул көндә ачды. Йосыф галәйһиссәлам ул көн Мисырда падишаһ улды. Йагъкуб галәйһиссәлам илән ул көн күрешделәр. Исмәгыйль галәйһиссәлам ул көн дөнйайә килде. Ул көн һәр кем икенде илә ахшам арасында тырнак киссә, рәнҗегидә шифа була.

### Фасыл фиш-шөһүр

Бу фасылда гарәби айларны белдерер. Бер йыл өч йөз илле дүрт көндер. Фарсийәдин бер йылда унбер көн нәкыс улыныр.

### Мөхәррәм

Йыл башыдыр гарәбләр катында, әмма гаҗәмләр катында Нәүруз, йәгъни Хәмәл йыл башыдыр. Сәбәбе вәҗһе тәсмийә билгарәбийә улдыр ки, әүвәл ады Сорйанда вә Йунанда «Дәнбас» ирде. Мөхәррәм улдыгы ки, гарәбдә ике шаһ җәнг әйләделәр ки, бере Гамир атлы ирде вә берсе Сафуан атлы ирде. Бу Гамир гайать гыйлем-хикмәт ийәсе ирде. Сафуан галиб улыб аны кател әйләде вә каумене әсир әйләде. Фәрехендән бу айны Мөхәррәм куйды. Үзендән гайре зире хөкемендә улан гарәбләрә сугыш кыйлмакны хәрам әйләде. Илә улса ул ай «Мөхәррәм» улынды. Унынчы көндә Йуныс галәйһиссәлам балык карынындан чыкты. Хак Тәгалә Гарешне вә Көрсине вә мәләке әрбәганы ул көндә йаратды. Атамыз Адәм галәйһиссәлам ул көндә тәүбә әйләде. Нух галәйһиссәлам сиксән кеше илә Җуди тагына кимәдән

чыгыб ул көн карар әйләде. Вә Идрис галәйһиссәлам ул көндә күккә агды. Уд(т) Ибраһим галәйһиссәламә ул көндә гөлстан улды. Карунны ул көндә йир йотды. Йосыф галәйһиссәлам казугдин ул көн чыкды. Иагъкуб галәйһиссәлам күзе ул көн ачылды. Дауд галәйһиссәлам вә Йахйа галәйһиссәлам вә Искәндәр ул көндә җиһанә килделәр. Вә Сөләйман галәйһиссәлам ул көндә тәхетә агды. Вә Әййүб галәйһиссәлам ул көндә зәхмәтендән кортылды. Вә Йуныс галәйһиссәлам кауме ул көндә газабдан имин улдылар. Вә бер ривайәтдә хәзрәте Хөсәен ул көндә шәһит улды. Вә Гайсә галәйһиссәлам хәзрәте Мәрьйәмдән ул көн тугды, һәм ул көндә күккә агды. һәркем ул көндә күзенә сөрмә чиксә аслан агырыкы күрмәйә. Вә Мөхәррәмнең уналтынчы көнендә «бәйтел-мөкаддәс» кыйбла улды. Унйиденче көн әсхабе фил әбабил кауме илә һәлак улыб әһле Мәккә нәҗат улдылар.

## Сәфәр

Әүвәл ады Сорйанда вә Йунанда «Бәрнас» иде. Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр ки Гаднан кабиләсе гарәбдә гайатьдә баһадир вә җәнг ийәсе кешеләр ди. Бу айны мөбарәк күреб җәнг итмәгә кидерләр ди. Әлкыйсса, бу бәни Гаднандан бер Габдешшәмс дидеги шаһның мәшрикъ зәминдә бер дошманы вар иде, Фәрәнг шаһларындан иде. Ул шаһга бу ай эчендә җәнг идеб кальгаларыны хараб әйләде вә галиб улыб, гавамләрене әсир идеб вөзара’и әкябирләрене зинданә салды. Вә йөзләре сары улдыкдан көзен улдырды илә улса бу айның ады Сәфәр улсын, диде. Бу ай гакраб бөрҗендә икән, мө- нәҗҗимләр катында шәүм вә нәхесдер. Никах кыйлмак вә бина әйләмәк мәмнугъдыр, димешләр гайре бер вәҗләрдә улса мәмнугъ дүгелдер, димешләр. Әмма гыйндәш-шәригать бу айда һәр нә хәйерле улан гамәлләргә шоруг итмәк сәгыддер. Бу айны шәһре мозаффар димәкләре илә һәм мәшһүрдер. Бу айның әүвәл көнендә йәзидиләр хәзрәте Хөсәйен разыйаллаһу ганһүнең башын кисеб алдылар вә Димашкка илтделәр. Йәзид аның башындан бәхиллек теләде, ул мөбарәк башдан аваз кил-

де: «Разыйна би казаи Аллаһү Тәгалә вә хөкмиһи. Вә әна лән нәмит мин фигъляк вә шәүмик бәл би хөкмиһи. Ля нәдгый дәма’ина минки фи йәүмил-кыйамәти», – див. Бәс шуның өчен Йәзидә ләгънәт әйләмәк җаиз улмады. Йегерменче көнендә ул башны кире Хөсәйен разыйаллаһу ганһүнең тәненә илтделәр. Ул баш кире тәненә әүвәлге кеби улашды, илля бугазында башны кисдеге җәрахәте калды. Дәште Кәрбәладә дәфен әйләделәр. Сәфәрнең йегерме алтынчы көнендә, тарих һиҗрәтнең илле алтынчы йылы ирде, Куй йылында мөбарәк җомга кичәсендә иде.

## Рабигыль-әүвәл

Бу айның әүвәл ады Сорйанда вә Йунанда «Хуан» иде. Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр кем, Пәйгамбәремезнең Кәнанә исемле йөкчәк бабасы вар иде, гарәбләр шаһы иде. Бер көн ул Кәнанә вәзирләре илә, йазның әүвәлге айы ирде, сәфәрә чыкды лар илә күрделәр ки, сәчакләр ачыл мыш. Вә чамәнләрне күрделәр илә, күрделәр ирсә бәс айның адыны «Рабигыль-әүвәл» куйдылар. Бу ай мөбарәк айдыр. Мөхәммәд галәйһиссәлам бу айның сигезенче көнендә Мәдинәдә мәкам иденде. Унынчы көнендә Хәдичә’и Көбра разыйаллаһу ганһаны никах әйләде. Йегерме икенче көнендә Фатыйма разыйаллаһу ганһа вөҗүдә килде. Йегерме өченче көнендә хәзрәте рәсүлулла галәйһиссәламның вафаты булды. Вә хәзрәте Әбу Бәкер ул көндә вафат итмешдер.

## Рабигыль-ахир

Мәзкүр гарәбләрнең шаһы Кәнанә сәфәрдән рөҗуг итдекләрендә чәчәкләр камил улмышларыны күрде, йаз айының ахыры иде. Бу ай «Рабигыль-ахир» улсын, диде. Әүвәл ады Йунанда вә Сорйанда «Рәбкан» ирде. Ул көндә Йосыф бине Хаҗҗаҗ Кәгъбәне вә Хәрамне тәмам әйләде. Бу айның ун¬дүртенче көнендә намаз фарыз улынды. Йегерме бишенче көнендә зәкять айате инеб зәкять фарыз улды. Утызында шәһре Рамазан рузасы фарыз улынды. Бәгъзиләр шәһре Рамазан рузасы Рәҗәб айында фарыз улынды диерләр.

www.darulkutub.com

## Җөмадиәл-әүвәл

Бу айның ады Йунанда вә Сорйанда «Хәнин» дийерләр ди. Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр ки, гарәбнең бәни Гаднан угылларындан Закур шаһ мәгъриб дийарының бер Кәран адлы Әфрәнҗ шаһы илә җәнг идәр өчен Йәмәндән чыгыб мәгъриб зәминнең Лита дигән кальгасыны алыб гаскәре илә кундыкларында көзнең әүвәле ирде. Ул кичә гайать суык улды, сулар туңды. Болар аслан суның туңганыны күргәнләре юк ирде. Санигы галәмнең гаҗәб сангатене күреб тәгаҗҗеб идеб, бу айның адыны Җөмадиәл-әүвәл диделәр. Бу айның сигезенче көнендә Гали кәрамә Аллаһы Тәгалә вәҗһәһ дөнйага килде, унбишенче көнендә дөнйадан үтде. Чәһаршәмбе көннең кичәсендә тәмам госел идеб вә намаз кыйлыб беткәнләрендән соң, галәме гайбдән бер кызыл тәвә зоһур улыныб, хәзрәте Галине ул дәвәйә артдылар, күтәреб алыб Бәкыйг гүрстанының бер почмагында фәрештәләр дәфен итделәр. Шәмди кабере Бәкыйгдадыр. Кабере сәтер улынмакда Аллаһы Тәгаләнең сер газыймы вардыр, бәндәләр аны идракъ идә белмәзләрдер. Бу айның өченче көнендә җомга көн ирде, хәзрәте Гомәр разыйаллаһу ганһу Ислам илә мөшәррәф улынды. Вә шул көндә Кәгъбә'и Мөкәррәмәнең эчендәге потларны пакь әйләде. Шул көндә өйлә намазыны җәмагать булыб Кәгъбә'и Мөкәррәмәдә укыдылар. Ул заманда кырык мөселман булды. Бу айның унбишендә хәзрәте Хәмзә илә хәзрәте Габбас разыйаллаһу ганһума мөселман улдылар.

## Җөмадиәл-ахир

Бу айның ады Сорйанда вә Йу нанда «Зәбед» иде. Вәҗһе тәсмийә билгарәбийә улдыр ки, йугарыдагы шаһе гарәб Закур дийары Әфрәнҗдән кайтдыклары заманда әрмәнленең Ник дидеге кальгасында гаскәре илә кундылар. Көз айының ахыры ирде, ул көндә әүвәлге көз айындан зийадә суык улыб сулары зийадә туңыб тордыгыны күреб әйтделәр, бу ай «Җөмадиәл-ахир» улсын, див. Мәгънәсе: «һәза әҗмәде минәл-ахир»

димәкдер. Бу айның әүвәл көнендә Җәбраил галәйһиссәлам вәхи килтерде: «Икъра биеми раббикә» сүрәсе иңде. Тугызынчы көн хәзрәте Җәгъфәр Садикъ дөнйайә килде. Унбишенче көн Әберһә мәлгун Кәгъбә’и Мөкәррәмәне йакмага килде. Утызынчы көн Пәйгамбәремез галәйһиссәлам Кәгъбәне йабды.

**Рәҗәб**

Бу айның ады Сорйанда вә Йу нанда «Мөнфасыл» иде. Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр ки, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең җаһилийәт заманында Һашим дидеге йөкчәк бабасы бар иде, гарәб кабиләләренең газыйм шаһы ирде. Вә һәм гайре мәмләкәтләрә, Гөрҗестанә вә Румстанә вә һәм Барстанә вә Фәрәнгестанә хөкеме йөрер ирде. Бер көн Румстанә сәфәрә чыкды, йулы Румның Салийан дидеги кальгасында душ улды. Ул кальганың сахраларында гәшт идеб йөрдекләрендә бер тагга бенделәр. Ул тагның исеме Каләндәр тагы дийерләр, бик гайать йөкчәк тагдыр. Ул таг Салийанның каршысында ирде. Ул тагның башында бер чишмә чыкмыш ирде, бик мөбарәк судыр, чыкдыгы йирдән аваз белән чыгар ирде. Аның суындан әтрафындагы илләр мәразларындан шифа эстәрләр иде. Бу Һашим шаһына бер көн эч агыргы пәйда булды, ул чишмәнең суыны эчеб шифа табды. Ул арада Рәҗәб айы тугмыш иде, көнеш тәмам батмыш иде. Үз теленчә агаз идеб әйде: «Ма һәза рәҗәбел-мөрәҗҗәб, шифа’ина мин һәзал-гайн әу мин һәзалһилял», – диде. Шул әҗәлдән бу айга «Рәҗәб» дийелде. Гарәби мәгънәсе будыр: «Бу ни гаҗәб, олуг вә кадерле дарудыр. Безнең шифа тапмагымыз бу чишмәдәнме, йуксә бу йаңа тугдыгы айданмы», – диде. Бу айның әүвәл көнендә Нух галәйһиссәлам кимә йабды. Йиденче көнендә хәзрәте Нухның пиче төбендән су чыкды. Йегерме йиденче көнендә Пәйгамбәремез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗга горуҗ әйләде. Йегерме сигезенче көнендә хәзрәте рисаләт саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә нөбөввәт вирелде. Йегерме тугызынчы көнендә хәзрәте Госман разыйаллаһу ганһү шәһит улды, димешләр.

www.darul-kutub.com

## Шәгъбан

Бу айның әүвәл ады Сорйанда вә Йунанда «Гадел» ирде. Сәбәбе вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр ки, гарәбнең бәни Тәмим дидеги кабиләсендә бер шаһ вар иде, ады Нәүфәл бине Вәрака дийерләр иде. Гайатьдә олуг шаһ ирде, үзе голүме фәлсәфийәнең маһиры ирде. Заманында андан галимел-хикмәт вәл-фәлсәфә йук ирде. Галәмнең кадимене исбат әйләмеш ирде. Бер көн ул шаһе фәлсәфийә сәфәрә икъдам әйләде. Килеб йуллары Тарабстан диңгезендә душ улды. Җөрҗан дидеги кальгада гаскәре илән кунак булдылар. Җөрҗан шаһы аны сәйре сахра идеб шекярә чыкды лар. Шекяр кыйлдыклары хинендә каршыда күзләренә бер йөкчәк таг күренде. Җөрҗан шаһы әйде: «Әй, сәйидел-гарәб, халя шул тагның башына чыгалык, анда бер чишмә вардыр. Башы бердер, унике бүлек булыб агарлар, һәр бүлек сулары һәрберсенә гайредер. Бер бүлеге бик суыкдыр, бер бүлеге эсседер, кайу бүлегедә сөт ләззәте бардыр, кайу бүлегедә гамбәр исе бардыр, кайу бүлеге кара рәнгдер, кайу бүлеге кызыл рәнгдер, кайу бүлеге сәм катлыдыр, кайу бүлеге су булыб агар, кара таш булыб туңар». Буны күреб, тәгаҗҗеб идеб Нәүфәл бине Вәрака әйде: «Әй, шаһе Җөрҗан бине Рөстәм бине Бәлгам, бәнем бүсер зәхмәтем бардыр, бу чишмәләрнең каныгы бүлегендән эчмәгә әмер идәрсең»,– диде. Җөрҗан шаһы әйде: «Гамбәр исе килгәне бүлегендән эчкел»,– диде. Чунки шаһе гарәб эчде дәр халь шифа табды, бүсере уылыб дөберендән чыкды. һәм ул арада көнеш батмыш иде, Мөнфасыл ай тәмам ул мыш иде, үз теленчә дога әйләде: «Аллаһөммә әҗгал һәзаш-шәһра мөбарәкән инни шәфитү һәзиһиш-шогуб». Төрки мәгънәсе улдыр ки: «Әй, Бари Ходайа, бу айны мөбарәк кыйгыл, барча бәндәләреңә, мин тәхкыйк шифа табдым бу шогубләнеб торгучы чишмәдән»,– диде. Шогуб дидекләре бүлек булыб таралыб китдеге нәрсәгә дийерләр. Шул әҗәлдән бу ай «Шәгъбан» булды. Бу айда хәзрәте Муса галәйһиссәламгә Тиһ сахрасында ман вә сәлва күкдән инде. Өченче көнендә хәзрәте Хөсәйен анадан тугды. Дүртенче көнендә хәзрәте Хәсән тугды. Унбишенче көн «Бәраәт» кичәсе вакыйг булды. Уналтынчы көн «Кәгъбәйә» на-

маз өчен тәваҗҗоһ итделәр, әүвәлдә Коддесә тәваҗҗоһ идәрләр ди. Йегерме бишенче көнендә хәзрәте Гомәрнең вафаты булды.

## Рамазан

Бу айның ады Сорйанда вә Йу нанда «Туан» ирде. Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр ки, хәзрәте Исмәгыйль заманында бәни Харҗәм дидеги бер залим шаһ Хәбәш дийарында хоруҗ итде, так ки хәзрәте Исмәгыйльнең йирене алыр өчен. Күб гаскәре илә килделәр. Чунки Хәбәш шаһы сиңа җәнг илә килде дийарыңны хараб әйләмәгә диделәр, Исмәгыйль галәйһиссәлам аның илә җәнг идәргә Мәккә җәмагате илән чыгыб, ул Харҗәм гаскәрене тар-мар әйләделәр, бәгъзиләрене үлдереб, калдыкларыны кол идеб. Ул көн хәребдә бик каты эссе ирде, ибтидаэ горрә’и шәһре Рамазан ирде, хәтта ки айакларының диресе эсселекдән пешеб кабарыб каты зәгыйфь улдылар. Мәккә әгърабләре нида итеб әйтделәр ки: «Ва Рамазан, ва Рамазан, әхрака колубәна бил-гатәш вә әкъдаәмәна бил-хәрр». Мәгънәсе төрки теленчә: «Ай-вай, йанды безнең йөрәкләремез сусамак илән вә айакларымыз ком вә таш эсселеге берлән». Шәмди шул әҗәлдән бу айны «Рамазан» див ат вирделәр. Бу айның әүвәл көнендә Коръән ләүхел-мәхфуздән иңдерелде бәйтелмәгъмурә, Пәйгамбәремез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә. Кирәк саен Җәбраил галәйһиссәлам андан үгрәнеб пәйгамбәр галәйһиссәламгә укыр ирде. Өченче көнендә Ибраһим галәйһиссәламгә «Зәнд» дигән сахеф иңде. Дүртенче көнендә хәзрәте Гайсәйә «Инҗил» иңде.

## Шәүвәл

Бу айның ады Сорйанда вә Йунанда «Туван» иде. Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр ки, гарәбнең бәни Гайс дидеги кабиләсендә Борһан бине Әнус дидеги шаһ гайатьлә олуг ирде. Һәрбер хайванат вә хәшәрате арызның кәйфийәте җомагларыны карар өчен һәрбер таг сахрада вә урманда йөреб дившердегендә йулда килер өчен бер доррә җәмагатьләрне

күрде, йәгъни чебен җәмагатьләрене, доррә әнвагыннан бер чебендер, диңгез кенаренда чук улыр, рәнге йәшелдер. Анларның фәрҗе канаты астындадыр. Мөзәккәренең аләты мәгъһүд урындадыр. Боны күреб тәгаҗҗеб идеб әйтде: «Ма һәзаш-шәүвәләтә әййел-җомаг. Фәрҗәһү тәхтә әҗнихәиһ». Йәгъни: «Бу ни гаҗәб җомагдыр, фәрҗе канаты астындадыр», – див, тәгаҗҗеб итде. Боны күрдеге хиндә горубе шәмес ирде, зира ки ул чебенләр койаш баткач уйнарлар. Ул арада йаңа ай күренде, йәгъни «Туван» айы тәмам улмыш ирде. Бу гаҗаиб кодрәте күрдегем, шуның өчен бу айның ады «Шәүвәл» улсын, диде. Бу айның әүвәл көне нәхесдер һәм гайеддер, гыйбадәтдән гайре гамәл идәргә мәмнугъдыр. Йиденче көнендә хәзрәте Хәмзәне шәһит итделәр. Йегерме йиденче көнендә Бәдәр газасы улды.

### Зуль-кагъдә

Бу айның ады Сорйанда вә Йунанда «Вәзна» ирде. Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр ки, Пәйгамбәремез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөкчәк бабасы Габдешшәмс[4] бине Габделманнаф дийерләр ирде. Җәмигъ робгы мәскүнне үзренә табигъ итдермәк һәвәсендә ирде. Бер көн бу фикер илә йатды. Бу Вәзна айында дийаре мәгърибә варайун, андагы падишаһлар бәңа бәйгать бирсенләр, хараҗә разый улсын лар, йәки үзем кеби көнешкә гыйбадәт итсенләр, йәгъни бәнем динемдә улсынлар, див. Шул фикер илә йатды, хабә китде. Шул кичәдә дөшендә хәзрәте Газраилне күрде, билә ки боның кеби һичбер хуб сурәтне дөнйада күрдеге йук ирде. Габдешшәмс сорды: «Йа, сахибел-җамал вәл-кәмал, сән кем сән вә сәне кем дийерләр, Тәңре дүгелме сән»,– диде. Газраил галәйһиссәлам әйде: «Мән сәнең кеби кол мән, ил ля Мәләкел-мәүт див бәне әйтерләр, йәгъни барча мәхлукатлар җаныны вә һәм атаң-анаң җаныны бән алдым»,– див әйтде. Габдешшәмс әйтде: «Бу койаш Тәңре дүгелме»,– диде. Хәзрәте Газраил әйтде: «Дүгелдер,

[4] Габдешшәмс – татар риваятьләрендә бу сюжет Болгар шәһәре белән бәйләнгән: Габдешшәмес төшендә Хызыр галәйһиссәламне күреп ислам диненә күчә һәм Габдрахман исемен ала.

бәлки Аллаһы Тәгалә улдыр Халикы көллү шәй’вә Разаккы көллү хәйдер». Габдешшәмс әйтде: «Бән ул Тәңрийә иман килтерәмен, иман гарыз әйлә»,– диде. Газраил галәйһиссәлам әйде: «Әшһәдү әл-ля Иляһә иллаллаһ, вә әшһәдү әннә Газраил Нәбиуллаһ дигел»,– диде. Иман гарыз кылдыкы өчен Газраил Нәбиуллаһ»,– диде. Бәс Габдешшәмс көнеш гыйбадәтеннән кайтыб гыйбадәте Рахманә икърар вә тасдыйк әйләде. Хәзрәте Газраил әйде: «Йә, Мәлик, синең исемең Габдерахман улсын, бәнем исемем һәм гыйндаллаһ Габдерахмандыр», – диде. Гозер димәк габед мәгънәсенәдер, ил димәк Аллаһ мәгънәсенәдер, Сорйанийәдер. Бәс Габдерахман әйде: «Бәнем җанымны качан алырсың, та ки бән үлем истигъдадында үләйем»,– диде. Хәзрәте Газраил башыны куйы салыб тәфәккер үзрә калды вә айагының биш бармагыны күргәзеб гаиб улды. Падишаһ нә кадәр фәлсәфийүн вә мөнәҗҗимләр вә фалгуйләрене йагындырды, дөшене йуратмак өчен, хәтта ки бер ай боның дөшене тәэвил идәргә гаҗиз улдылар. Бәгъзиләре биш йыл димәклә вә бәгъзиләре биш йөз йыл димәклә тәэвил әйләделәр. Әлхасыйль иттифак тәкъбир улмайуб бер ай бу мөтәваль үзәрендә улдылар, хәтта ки «Гуван» айы тәмам улыб, йегерме тугызынчы көнендә Аллаһы Тәгалә хәзрәте Хызыр зендене йибәрде: «Баргыл, ул колым Габдерахманның дөшене тәэвил әйләгел вә һәм Хәбибем Мөхәммәд галәйһиссаләт вә сәлам аның нәселендән килмәгене можде биргел»,– диде.

Әлкыйсса, Хызыр галәйһиссәлам барды. Шаһ йокысындан уйганды, күрде ки бер дивана йөрер, кулында бер кечерәк балтасы вардыр. Ул дивана падишаһга илтифат итмәйенчә тәхетенең айагыны балта илә чабарга керешде. Падишаһ хәзрәте бик сабыр әһлендән ирде, каравылчыларга чагырмайеб, акрын әдәб берлә: «Йа, фәлан, сән бәнем тәхетемнең айакларыны кисмәгел, зира ки атала- рымыздан калган мирасдыр, зиннәте китмәсен», – диде. «Кил, бәнем йәнчүгеме чабкыл», – див айагыны сузды. Дивана андан игъраз идеб арлы-бирле карады, йөрде, күрде, падишаһның кул йуа торган алтын тасы вар иде, аңа барыб бәүл әйләде. Падишаһ әйде: «Зинһар, әй, фәлан, ул тасга бәүл

кыйлмагыл, зира ки, аталарымыздан калган мирасдыр, бәгъдәттагам анда кулларымызны йуармыз, аны мөләүвәс итмәгел, кил бәнем таҗыма бәүл әйләгел»,– диб, башындан таҗыны алыб хәзрәте Хызырның үгендә куды. Бәгъдә Хызыр галәйһиссәлам тәбәссем идеб шаһга сәлам вирде вә әйтде: «Аллаһы Тәгаләнең колларындан бер колымын, сәнең төшеңне тәэвил кыйлмага йибәрелдем. Бәнем исемем Хызырдыр, вә дәхи синең нәселеңдән бер пәйгамбәре Хак килер. Ул дөнйа вә ахирәт падишаһы улыр, исеме Мөхәммәд улыр. Габдуллаһ углыдыр. Һашим углының Габдел-Маннаф дидеге углының ыругындан килер», – диде. «Шәмди дөшеңне тәэвил кылаейы. Нә кадәр голуме фәлсәфә белдеге галимләреңне өндәгел, вә дәхи нә кадәр мөнәҗҗим вә әсхабе көһһанәләреңне вә мәшаих- ләреңне өндәгел, анлар алдында тәэвил кылаейы»,– диде. Бәгъдә падишаһ голяма’э фәлсәфине, вә мөнәҗҗимләрне вә каһинләрне җәмыг әйләде вә әйтде: «Бәнем мәгъһүд дөшеме ничек тәэвил идәрсезләр. Анлар әйтделәр: «Әзгасе әхламдыр, әзгасы әхламә тәэвил йукдыр»,– диделәр. Шаһ газаб идеб: «Барчаларыңызны хөрмә ботагына асармын»,– диде. «Бунчә йыллардан бирле бәйтел-малдан сезләрне тәрбийәт идәмен, мәнем дөшем ничек әзгасе әхлам улсын, зира ки бән дөшемдә Мәләкел-Мәүтне күрдем, ул бәңа Аллаһы Тәгаләнең вәхданийәтен үгрәтде»,– див сикереб кылыч алыб тордыгында хәзрәте Хызыр галәйһиссәлам бер фәкыйрь сурәтендә торыб: «Йа падишаһе гарәб, ачыгланмагыл, зира ки, анлар да бәндәләрдер. Аллаһы Тәгалә белдермәгәнне анлар белмәсләр, утыргыл, төшеңне тәэвил идәйен»,– диде. Барчалары ултырдылар вә әйтде: «Йа, падишаһ, ул Мәләкел-Мәүтнең бармак күрсәтмәге синең гомереӊ күблегендән вә азгылыгындан хәбәр бирмәк дүгелдер, бәлки будыр, биш нәрсәне Аллаһы Тәгаләдән гайреләр белмәс димәкдер. Ул биш нәрсәнең берсе – Кыйамәт көненең кайу заманда вә кайу фасылда, вә кайу көндә булмагыны Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәсләрдер. Икенче бармагы ишарәтдер, йагмур йагмагыны кайу айда вә кайу көндә, вә кайу сагатьдә йагмагыны Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәсләрдер. Өченче бармагы ишарәтдер, хамилә ха-

тын лар вә хайванатлар хәмелендә уланлар иркәкме йа тешиме, карамы-кызылмы булмакларыны Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәсләр. Дүртенче бармагы ишарәтдер һич нәфес белмәс иртәгә ни кәсеб кыйласын Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәсләр. Бишенче бармагы ишарәтдер бәни Адәм кайу йирдә үләчәгене вә качан үләчәгене белмәсләр, мәгәр Аллаһы Тәгалә белер»,– димәкдер. Шул әҗәлдән Аллаһы Тәгалә Коръәндә «Локман сүрәсе»ндә[5] хәбәр бирде: «Иннә Аллаһу гыйндәһү гыйлмус-сагати вә йөнәззилел-гайсә вә йәгъләму ма фил-әрхами вә ма тәдри нәфсүн ма за тәксибу гадан, вә ма тәдри нәфсун би әййи әрзый тәмут»,– див бу тәэвилне калдыкдан соңра Хызыр галәйһиссәлам халык арасындан гаиб улды. Белделәр ки, Хызырдыр. Ул арада Гуван айы тәмам улмыш иде, йаңа ай күрделәр. Габдерахман дийаре мәгърибә вармагындан, анларны батыйль динә дәгъват итмәгендән тәүбә идеб, хәребдән когуд итде. Вәзна айына «Зуль-кагъдә» див исем вирде. Бу айның дүртенче көне әсхабе Кәһеф мәгарәйә керде. Бишенче көне Ибраһим галәйһиссәлам Кәгъбәне бина әйләмәгә башлады. Иденче көнендә Фиргавен ләшкәре илә Нилдә һәлак улды.

### Зуль-хиҗҗә

Бу айның ады Сорйанда вә Йу нанда «Бәрдан» ирде. Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр ки, Исмәгыйль галәйһиссәлам углы Әдбән ирде. Хаҗ кылмак өчен Шамдан Мәккә йә килде. Ул заманда Мәккәдә хәзрәте Ибраһимның сохофы илә гамәл кылгучы бер әгъләм вар иде, исеме Әйүб иде. Ул чыгыб җәмагате илә хәзрәте Әдбәнне каршы алыб тәгъзыйм итделәр. Ул көндә Вәзна айы тәмам улмыш ирде. Әйүб Әгъләм әйтде: «Халя йә шаһа Әдбән бине Исмәгыйль галәйһиссәлам хаҗ айының ахырыдыр. Бу Бәрдан айының ун көнендән ары хаҗ булмас»,– див бойырылды. «Бабаң Ибраһим галәйһиссәлам китабы «Зәндә» исемледер, андаг бондаг маукутдыр»,– диде. Ул арада йаңга ай күренде, Әдбән хәзрәтләре үз теленчә дога әйләде: «Ахырыһа «зил-хиҗҗә»,– диде, йәгъни бу ай хаҗ айларының ахырыдыр,

[5] «Локман сүрәсе»ндә – Коръән (31:34).

димәк улды. Бәрдан айыны «Зуль-хиҗҗә» димәк илә исем бирде. Унынчы көн бәйрәм көнедер, Гарәфә җомга көнгә туры килсә, Хаҗе әкбәр дийерләр.

## Килдек үземезнең икълим бәйанына

Әликълимүс-сабигъ, йәгъни йирнең йиденче бүлеге. Йәгъни йиденче уралы бәйанындадыр. Бәхре һиндидән бәхре Фарсә варанчадыр, йәгъни Хаҗи Тархан диңгезендән Хытай диңгезенә варанчадыр. Бу икълим Камәр йолдызының тәрбийәсендә булыр, алты уралның күркәмрәгедер. Мәнфәгать вә нәзаһәт әсбабы чуклыгындан. Аның өчен чишмәләре вә әнһарләре вә агачлары чукдыр, вә сулары зийадә ләзиз вә сәһлел-мосагыйддыр. Вә иген нигъмәтене Аллаһы Тәгалә йагъмур суы илән сугарыр. Вә бу икълимнең мәшрикъ тарафы Мийач нәһерендәндер, йагъни Уралның шәркый җанбедер.

Хәтта ки Хытай илә Хытайның Пикин дидеги кальгасындан. Суык хаузның кыйбла тарафындан, урысның Архан кальгасы[6] кыйбла җанибендән варыб Лена дәрйасына чыгар. Андан дийаре мәгърибкә керер. Әфрәнҗнең Буляк дидеге кальгасындан, Рим йиренең сәрхәдде Латыш кальгасындан килеб пуляк йиренә чыгар. Пуляк йорты бетәмамә килеб Дуна суының мәшрикъ тарафына Кийав кальгасына килер. Андан Гөрҗестан вә Дагстанә091 уграйеб Дуна вә Ана кальгаларындан Тәбтәрә дәрйасының аргы әтрафы илә килеб Кубан дәрйасының башындан Хаҗи Тархана уграр. Уралның кыйбла җанибендәге башыдыр. Шәркый җанибендәге башы Хытай йортының Пикин дидеге кальгасындадыр. Йәгъни бу икълимдә, йәгъни йитенче уралда мәтләгышшәмс вә һәм кичә вә көндезнең сәгатьләре мөхтәлифдер. Хытайның Пикин дидеге кальгасындан вә Нанждан вә Исбадан кальгасында вә һәм Лякур вә Бакур кальгаларында әкъсаре ләйальдә тугыз сәгатьдән ким улмаздыр, хәтта Йахут халкына чыкканча андан Уралның шәркый тарафында Тубыл суы-

[6] Архан кальгасы – Архангельск шәһәре, 1613 елга хәтле Ново-Холмогор исемен йөртә.

на килгәнче, Ангар дәрйалары вә Әртеш суы вә Тубыл суы, вә Уй суы, вә Мийач суы бу икълиме сабигъдан сайламаздыр, зира ки анлар Уралның шәркый тарафында улмышлардыр. Ан ларны икълиме садистан сайелыр, йәгъни алтынчы уралның сәрхәддедер. Вә һәм Җайык суы вә һәм Сакмар, вә Сарайчык суы икълиме садисның бер тараф сәрхәддедер, йәгъни алтынчы уралның гарби тарафындагы чигедер. Имде йитенче уралдагы әнһар гыйзамларны вә мәшһүр суларны зикер идәлем. Мәгълүм улынадыр ки, Уралның гарби тарафындагы сәрхәдде, йәгъни Уралның гарби тарафындан чыккан Ак Иделдер, Архан тагындан чыккандыр, Өфе иделе гарби тарафындагы Уралгы тагындан чыкандыр. Әй суы Тагынай тагындан чыккандыр. Чулман иделе җанибе шимальдән Суык хаузның кыйбла җанибендән чыккандыр.

## Әнһаре мәшһүрләр бәйанында

Бу Уралның гарбийәсендән бәйан идәлем: нәһре Кыйгудыр, Әй дәрйасына койар. Әй дәрйасы Өфе иделенә койар. Таныб дидеге вә һәм Бөре дидеге йыл га Ак иделгә койар. Узан йылгасы Өфе иделенә койар. Нәһре Бази, Сәрмәсан Кармәсан Ак иделгә койар. Нәһре Сөн һәм Ак иделгә койар. Нәһре Ак һәм анда койар. Нәһре Мәллә Акка койар. Ирәнә вә һәм Зәй йылгасы бергә кушылыб Ак иделгә койар. Мәшһүр йылгалардан Ак идел Чушмысы дийерләр вә һәм Кичү дидеге йылга Ак иделгә койарлар. Чулман иделе һәм Нократ иделе һәм Ак иделгә койарлар. Ак иделнең Чулман иделе илән кушылдыгы йирдә бер таг вардыр, Йүнчә тагы дийерләр. Анда бер чишмә вардыр, аны чишмә’и «Риҗалел-гайб» дийерләр. Анда риҗалел-гайбнең котыбын дәфен әйләмешләрдер, исеме Габдессамаддыр, рахимәһү Аллаһы Тәгалә. Җанибе шимальдән Ак идел илә Чулман иделенә койган йылгалар чукдыр, әмма мәшһүр улан йылга Иш суыдыр вә һәм Туймы йылгасыдыр. Чирмешән йылгасы икедер: берсене Олуг Чирмешән дийерләр, икенчесе Кече Чирмешән дийерләр, Ак иделгә койгандыр. Самар йылгасы Вулгы иделенә койгандыр. Нәһре Кинәле Са-

www.darul-kutub.com

мар йылгасына койгандыр. Вулгы иделенең гарби тарафындан койган йылгалары чукдыр, мәшһүре Мәскәү йылгасыдыр. Ул Ак иделгә койгандыр. Ак идел килеб Ука иделене вә Чулман иделене вә Нократ иделене җәмыг идеб, Мишә тагындан бик аз түбән Вулгы иделенә койгандыр. Вә йәнә мәшһүр нәһре Зөйәдер вә һәм нәһре Суйдыр. Вә һәм нәһре Вулгыга җанибе шимальдан килеб койган йылганың мәшһүре Илләтдер вә һәм Казан йылгасыдыр вә һәм Мишә йылгасыдыр. Җанибе кыйбладан чыгыб Нократ иделенә койган Бөре йылгасыдыр. Мәгърибдән мәшрикъ сари агыб килер; боны Нократ Чушмысы дийерләр, мәшһүрдер. Гайре мәшһүр йылгалар чукдыр, барыны йазмак мөмкин дүгелдер. Хәким Бталимиусның «Атлас» дигән тәварихында күргүзелмешди Байане әкалиме сәбгасендән бу урында тәрҗемә улынды.

## Фасыл фи гаҗаибел әбхар[7]

Бәхре Мохит. Диңгезләрнең олугы Мохит дәрйасыдыр. Мөштәринең тәрбийәсендә. Барча галәме ул капламышдыр. Шийлә зикер улынды: бәхре Мохит даирәсен күрмәк өчен Мисыр шаһы Хуҗа Бәйрәм бер көймә төзетте, алты йыллык азыклары берлә биш йөз кемсәне җибәрде, анларга бер хас рәис кушты; ады Диңгез угылы димәклә мәшһүр иде вә җитмеш ике төрле телдән белер ирде. Ул көймә берлә бер йыл киттеләр, диңгездән гайрене күрмәделәр. Искәндәр заманы ирде. Искәндәр әмере илә бу Хуҗа Бәйрәм шаһ аны җибәрмеш иде. Бардыклары заманында җәмагате мисрый бер көймә күрделәр, каршы вардылар, җәнг иттеләр, ала алмадылар. Бәгъдә сүзләштеләр, бере беренең телене белмәде. Хак җәллә вә галә бунлар көймәсенә Илйас галәйһиссәламне җибәрде. Ул мисрыйларга: «Нә кешесез, вә нә вилайәтнең сез?» – дәйү сурдыкларында әйтте: «Безләрнең шаһымыз Искәндәрдер, җәмигы робгы мәскүннең хөкеме аның әлендәдер». Анлар Искәндәрнең

7 Фи гажаибел әбхар – диңгезләрнең гаҗәп хәлләре турында. Бу бүлек 1902 елгы басмада юк, шуңа күрә текст «Борынгы татар әдәбияты» (1963) китабыннан алынды (457 – 462 б.).

www.darul-kutub.com

намене вә нишанене белмәделәр, бу мисрыйларны кунак итеп үзләренең шәһәрләренә алып бардылар; бер йылгача бунларый зыйәфәт итеп, бәхре Мохитның атауларыны вә шәһәрләрене күргезделәр: ничә атаулар вә ничә карйәләр вә ничә шәһәрләр вардыр мисрый гаскәренә күргезеп кайтардылар. Ул атауларны Йаңа дөнйа димәклә исем вирделәр. Мисрыйлар кайтып Искәндәргә хәбәр вирделәр. Искәндәр бу кыйссаны аңладыктан газиз Аллаһы Тәгаләнең кодрәтене белеп сәҗдәйә варып әйтте: «Йа, Рабби, сәнең кодрәтеңне вә галәмләреңнең күплегене бу гариб бәндәң кайдан белсен?» – дәйү әбсәм улды. Мохит атауларыны вә андагы гаҗаибләрне бу рисаләгә язмак мөмкин булмадыгы өчен, куйылды.

**Бәхре Чин**

Зөхәл тәрбийәсендәдер. Бу бәхре Чин бәхре Мохита олашмыштыр. Мәшрикъ тарафыннан Каләзмә варанча, аннан мәгърибә варанчадыр. Дөнйада бәгъдә бәхре Мохит бу диңгездән олуг диңгез йуктыр. Гаҗаибләре чукдыр. Аллаһы Тәгалә ул диңгездә аккошлар йаратмыш. Ул кошлар Аллаһы Тәга- ләйә бу зикерне әйтерләр: «Ля иляһә илля әнтә вә әнтә Халикыйна вә Разикыйна»,– дийерләр. Вә йәнә һәр төрле тәганни илә әлхан идәрләр: ишедән гашыйклар рәкыс итеп җан тәслим итәр. Ул диңгез унбиш көн хәрәкәт әйләмәз, шийлә торыр. Ул кошлар даим йомырка салырлар вә балалар очырырлар; ул диңгездән чыга белмәзләр. Вә дәхи анда бер атау вардыр. Ул атауда очар кәдиләр вардыр. Канатлары йарканат кеби йонсыздыр. Вә дәхи ул атауда сычканнар вардыр. Мышыктан олуг. Ул кәдиләр ул сычканнары шекяр идеб йийәрләр, варырлар, тизәк итәрләр, ул тизәк «кабәлә» дидеге мөшек улыр. Вә дәхи ул атауда адәмиләр вардыр. Кеми кызыл тәнле вә кеми йәшел тәнле; канат илә очарлар. Вә дәхи анда өч төрле тутый вардыр: берсе – ак, вә бере – кызыл, вә бере – йәшел. Вә дәхи кяфур йыгачы андадыр. Ул йыгачның түбәсене уйсалар, су чыгар, кяфур улур, вә төбен уйсалар, су чыгар, туңар, җәмед улыр. Вә бак-бак йыгачы андадыр; көнәш баткач, ул йыгачлар «Бак, бак!» тәйү

www.darul-kutub.com

чыгрышырлар; таң тугач набуд булырлар. Вә дәхи ул диңгездә нурдан кошлар вардыр, кийеккә биңзәр. Агызларындин күбек атарлар. Ул күбек кан улыр, ул каннан мөшек улыр. Вә дәхи ул диңгездә бакалар вардыр, йегерме карыш бийеклеге. Качан йомырка браксалар, һәр берсе мең йомырка брагырлар; артык вә әксек улмаз. һәр кайу йомыркасына нәзар әйләсәләр, ул йомыркадан бака улыр, вә кайу сына нәзары төшмәсә, йомырка калыр, бака хасыйль улмаз.

## Бәхре Һинди

Готард тәрбийәсендәдер. Фарис диңгезе илә Зәнҗи диңгезе бу җирдә җәмыг улгандыр. Ул диңгездә йегерме мең атау вардыр. Ул атауларның берсенең ады «Таил»дер. Ул «Таил» атавында бер халык вардыр. Йөзләре калканә биңзәр. Вә сачлары ат койрыгы кебидер. Телләрендә «Ля иляһә ил ля Аллаһ» дәйү зикер әйтерләр. Вә Сәнбеле һинди анда улыр. Анда сандал агачы чук улыр. Ул атауда бер чишмә вардыр. Көндез акканы ак таш улыр вә кичә акканы кара таш улыр. Вә дәхи анда атау бардыр. Кичә көндез кеби нур бирер. Вә анда нур бардыр. Ут кеби йанар. Вә дәхи бер атау вардыр. Ул атауда ат башлы, сыгыр айаклы адәмләр вардыр, адәм сурәтендә, әмма башлары йуктыр...

## Бәхре Фарис

Бу диңгез Шәмес тәрбийәсендәдер. Мөбарәк диңгездер. Алты ай мәгърибдән мәшрика агар. Вә дәхи ул диңгездә ике гәрдаб вардыр. Унрайан көймәләр чыкмазлар, анда һәлак улырлар. Ганбәр вә йакут ул атауда күптер. Ул атауда бәни адәм вардыр. Ул ганбәрләре алырлар. Вә һәм йакутлары алыб, Һиндстанә килеб сәүдә кылырлар. Вә ул диңгезнең икенче исеме – Ганбәридер, мәшһүрдер.

www.darul-kutub.com

## Бәхре Калзәм[8]

Бу диңгез Миррих тәрбийәсендәдер. Калзәм дидекләре бер шәһәрдер. Хикәйәтне шийлә бәйан идәрләр. Әүвәл заманда Калзәм арасында олуг ил вар иде. Ул заманның падишаһына Сөләйман Хакыйкый дийерләр иде. Идрис галәйһиссәлам шәригатендә иде. Калзәм шәһәрене Идрис галәйһиссәлам шә¬ригатенә өндәде. Кабул әйләмәделәр. Анларны ул падишаһ шәһәре берлә хараб иттерде: Калзәм диңгезене казыттырыб, ул шәһәрне урыныннан агыздырттырды. Аннан Йәмәнә уграды, аннан Җиддәйә уграды, вә Сиданә, аннан Бәхре Мохита уграды. Вә анда бер төрле балык вардыр. Өстендә төкләре вардыр, ак мамык кеби. Гаурәтләр аны алыб иңерләб җеб әйләйеб тукырлар, кафтаннары улдыр. Ул Илнең халкыны Сәмәхи дәйү нисбәт идәрләр. Ул бәхре Калзәмә Бәхре Зәнҗидәйү һәм әйтерләр. Ул диңгезнең мәүҗе йуктыр, вә күбеге йуктыр. Төбеннән йаз әййамендә гакыйклар чыгар. Аны гакыйкы йәмәни дийерләр.

## Бәхре Мәгъриб

Бу диңгез Зөһрә тәрбийәсендәдер. Анда бер олуг балык вардыр. Аны айу балыгы дийерләр. Йөзе адәм йөзенә биңзәр. Ак сакалы вардыр. Гәүдәсе койрыгына биңзәр, һәр айның урта гатерендә коры йиргә чыгыб ултырыр, Ходага зикер әйтер. Зикерләре будыр, «Сөбханәкә ма газзамакә иннәкә вә ля Иляһә гайрикә», дәйү. Ахшам улачак ул балыклар диңезә кереб китәрләр. Ул диңгездә бер атау вардыр, бер хауз вардыр. Ул хаузның киңлеге бер айлык йулдыр. Ул хаузда бер ноугы балык вардыр. Колаклары вардыр. Саг колагының өстенә «Ля Иляһә илля Аллаһ» йазылмыштыр. Вә сул колакларының өстенә «Мөхәммәдер-рәсүлуллаһ» йазылмыштыр. Ул хауза «би-назыйр» дийәрләр. Аның суының хасыйәте улдыр ки, һәркем утка пешкән улса, ул пешмеш кешене ул хауза салсалар, тиз заман сыйххәт табыб, тәнләре әүвәлге кеби ула. Вә дәхи бер карыны ач кеше суыннан эчсә, бер һәфтәйә дик нәфесе иштиһан тагам итмәйәчәк.

---

[8] Бәхре Калзәм – Кызыл диңгез.

## Бәхре Җөрҗан

Бу диңгез Камәр тәрбийәсендәдер. Мәшрикътан чыгар. Бу диңгездә таг кеби аждаһалар вардыр. Вә бу диңгездә атаулар вардыр. Атауларында адәм сурәтле җенләр көн-төн ашамак-эчмәк вә чалгу чалмакта вә рәкыс дәүран әйләмәктә. Бу җеннәрнең шәһәренә «Магин» дийерләр. һинд лөгатенчә «Оҗмах назыйре» димәктер. Вә бу атауда әнваг җимеш йыгачлары чуктыр. Вә чишмәләре сөттән вә хәмердән акмыштыр. Өрмийә галәйһиссәлам анларны дәгъват итмәгә варды. Анлар аның сүзен кабул әйләмәделәр. Әгәр безгә сәнең оҗмах, тәмуг дидеге сүзең рас булса, безгә дөнйада оҗмах вирсен. Ахирәттә тәмуг берлә газап әйләсен, диделәр. Өрмийә галәйһиссәлам анларның сүзләрене Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләйә гарыз әйләде. Аллаһы Тәгалә анларның газабына тәэхир итеп Исрафил галәйһиссәламнең һәлак сурына дәген оҗмах нәзыйре кылды вә әнваг чишмәләр агызды. Анларның әгъдаде йөз сиксән мең мөзәккәр, йөз сиксән мең мөәннәстер. Углан тугмак улмаз, вә һәм карый улмазлар, илля йәүмил-фөзаг анлар гыйшгашрәттәдер. Безнең төркидә ул шәһәрне «Барсаң – кайтмас» дийерләр. Хәзрәт Искәндәр Зөлкарнәйн ул шәһәрә уградылар. Хак Тәбарәкә вә Тәгаләнең гаҗәеп сонгына багыб сәҗдә әйләде. Бу мәкаләнең эчендәге гаҗаиб Бократның «Атлас» китабыннан нәкыиль улынды.

## (Фасыл фи) бәйани гаҗаибел-җибаль[9]

Мәккәдә Әбу Кобәйес тагына бенеб куй башыны йисәләр ул кемсәгә һәргиз җиһанда эт өрмәйә, дешләмәйә. Вә дәхи Әндәлис тагында кызыл сыр вә кибрит әхмәр улыр, айерук җирләрдә улмаз. Вә һәм ул тагның башында бер хауз вардыр, терекөмеш андан чыгар. Исемене «Терекөмеш» күле дийерләр. Сыйнда бер таг вардыр, «Әнгәр» тагы дийерләр. Ул тагның башында куй башы кебек алтын-көмешләр вардыр. Качан ул ал-

[9] Фи бәйани гаҗаибел-жибаль – таулардагы гаҗәп хәлләр турында. Шулай ук «Борынгы татар әдәбияты»ннан (1963) алынды (464 б.).

тын лары фәкыйрь алса, һәлак улырлар. Хәрамзадә улан байлар алалар, һәлак улмазлар, интифаг алырлар. Вә һәм хәлалзадә улан байлар алса һәм һәлак улырлар. Вә һәм Сәмәркандтә бер таг вардыр. Йаз көнендә кар йагар, гайать суык улыр. Кыш көне гайать эссе улыр. Нәснә агмаз. Вә дәхи Кирманда бер таг вардыр. Адына Сур тагы дийерләр. Ул тагда бер наугы ак алача ташлар вардыр. Ул ташның берсене бер кемсәнә әленә алса, «өфф« дисә, ул таш эченнән бер адәм сурәтле таш чыгар. Ул сурәт улан ташка «өфф» дисәләр, ком улыр, «өфф» димәйен суга салсалар, һәнүз адәм сурәтендә дорыр. Качан судан алып, йәнә «өфф» дисәләр, асыл ак алача ташка кайтыр, дийәрләр. Вә дәхи Тыйбарыстанда бер таг вардыр: «Мәрҗан» тагы дийерләр. Ул тагда болыт килеб, йагъмур йагса, йагъмур булыб иңәр, кара таш булыб туңар. Ул ташлар дүрт, йә алты, йә сигез пучыклы улыр. Ул ташларә үтмәс балталары, пычаклары салсалар өч кичә вә көндез анда тотсалар, үткен улыр, корычлы улыр. Вә дәхи һөрмездә бер таг вардыр. Ул таг башында бер чишмә вардыр. Аны «Чишмәи рәхмәт» дийерләр. Качан бер кеше «Йә һү» дисә, ул су торыр, акмаз. Вә дәхи «Йә мән һу» дисә, агар, йулына китәр. Исфаһанда бер таг вардыр. Ул тагның өстендә бер йылга вардыр. Качан койаш тугса, ул йылга мәшрикътан мәгърибә агар, качан койаш иңсә, мәгърибтән мәшрика агар.

## Фасыл фи гаҗаибел-гойун[10]

Әзәйҗанда бер чишмә вардыр. Аның суыны алыб калыбка койсалар, туңар, таш улыр. Әзәйҗан халкының таш савытлары вә казанлары айлардандыр. Ширазда бер таг вардыр. Аның бер чишмәсе вардыр. Качан ул чишмәйә нәҗес салсалар, ул су мәүҗә килер. Ул салган кеше ардыннан дәшер. Әгәр йетәрсә гарык итәр; итмәзә – кире урнына китәр. Әгәр көнендә ун кәз идәрләсә, илә идәр. Җөрҗанда бер чишмә вардыр. Аның йулында кырмыскалар вардыр. Актыр. Әгәр берәү су алмага барган-

[10] Фи гажаибел-гойун – чишмәләрнең гаҗәп хәлләре турында. «Борынгы татар әдәбияты»ннан алынды (466 б.).

да, ул кырмыскаларның берсене үлдерсәләр вә суны тулдырып савытлар берлән алып кайтсалар да, ул су савыты буш булыр. Исфаһан илә Шираз арасында бер чишмә вардыр. Ул чишмәдән бер савыт илә су алсалар, ул суны бер йирә куйсалар, сыгырчык кошлар җәмыг улырлар, һәртөрле әлхан илә аваз вирерләр, ул суны алган кеше илтеп куйганчы. Вә дәхи Наһәвәндә бер чишмә вардыр. Әгәр бер кеше килсә, йырактин чыгарса, «бән суга мохтаҗмын» дисә, килер, ул су алдына дөшәр, ул суны эчсә, «йитәр» дисә, ул су урынына китәр. Бондан гайре гаҗәбе фитрате Аллаһ чуктыр. Барыны йазмак мөмкин дүгелдер. Бократның «Зәнд» дидеге китабыннан, лөгате фәрәндән тәрҗемә улынды.

## Әл-мәкаләтес-сания фит-табигыйн[11] вәт-табигать[12] мин әһлил-Болгар рахимәһүм Аллаһу Тәгалә

### 1нче фасыл. Болгарның Ислам кабул итүе

Тарих һиҗрәте рәсүлуллаһи галәйһиссәламнең тугызынчы сәнәсендә[13] Хут йолдызында, Рамазан мөкәррәмәнең тугызынчы көнендә, Болгарда ул заманда хан атал мыш кемсәнә Айдар хан ирде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм өч сәхабәне тәблигы Ислам вә дине хак өчен Болгара йибәрде. Берсе Габдерахман бине Зөбәйер разыйаллаһу ганһү, икенчесе Зөбәйер бине Җәгъдә разыйаллаһу ганһү, вә өченчесе Тальхә бине Госман[14] разыйаллаһу ганһү ирде. Чунки ул сәхабәләр Болгара килделәр, үзләрене табиб шәкелендә кыйлыб, табибчылык кыйлыб йөрделәр. Ул заманда Вулгы иделе Болгарның астындан агар ирде. Бараҗ хан заманында Вулгы иделе андин күчеб мәгъриб тарафындан акды. Ул заманда, йәгъни Бараҗ

---

[11] Табигыйн – сәхабәләрдән ислам динен кабул итеп, белем алган ирләр, иярченнәр.

[12] Табигать – сәхабәләрдән ислам динен кабул итеп, белем алган хатын-кызлар, иярченнәр.

[13] Тугызынчы сәнә – милади белән 630 ел.

[14] Габдрахман бине Зөбәйер, Зөбәйер бине Җәгъдә, Тальхә бине Госман – Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләре арасында андый кешеләр булмаган.

www.darul-kutub.com

хан заманында тарих өч йөз туксан алтыда өйләре биш йөз йегерме иде димешләр, үзләре атәшпәрәст ирделәр. Мәзкүр сәхабәләр Болгарда чук мәразләрә дару кыйлдылар, һәр кайусы шифа табдылар. Бунларның исемләре мәшһүр улды, бийлә див: Гарәбстандан табиблар килгән, Мөхәммәд дидеге пәйгамбәрнең саллаллаһу галәйһи вә сәлләм йаранларыдыр. Әмма иманәтдә вә дийанәтдә вә әдәбдә нәзыйрлары юкдыр, див. Әлкыйсса, бер көн Айдар ханның кызы Туйбикәгә фалиҗ зәхмәте пәйда булды, һәр ни гыйлаҗ идеб уңалмады. Айдар ханның Бараҗ дидеге вәзире бар ирде, әйтде: «Әй, ханым, йәшең озак булсын, безнең шәһәремездә гарәб йортындан өч табиб килгән, табиблыкда нәзыйрлары йукдыр. Әмма динләре безем кеби дүгелдер». Айдар хан әйде: «Ул табибларны өндәгел, килсеннәр, кызым Туйбикәгә гыйлаҗ әйләсенләр», – диде. Әлкыйсса, Бараҗ вәзир барыб өндәде. Ул гарәбләр ханның йортына килделәр, кызны күрделәр. «Бу фалиҗ зәхмәтедер, боңа хәдәнг йафрагындан дуркә бәйләб хәммамда чапмак кирәк», – диделәр. Хан әйде: «Ул хәдәнг кайу йыгачдыр»,– диделәр. Зөбәйер бине Җәгъдә хәзрәтләре төрки теленә бик остад ирде, әйде: «Ул кайен йыгачыдыр»,– диде. Хан әйде: «Ул йыгач бездә чукдыр, – диде, – бәйләгән дуркәләремез дә чукдыр»,– диде. Сәхабәләр әйделәр: «Безгә йаңа агачдан алган кайен йапрагы кирәкдер»,– диделәр. Хан әйде: «Кыш көнендә аны кайдан табмак кирәк»,– диде. Әлкыйсса, хан әйде: «Сезнең гарәб йортында бер пәйгамбәр чыкмыш, адыны Мөхәммәд дийерләр, сез аны белермүсез», – диде. Сәхабәләр әйделәр: «Бәли белермүзләр, аның йаранларымыз, аның диненә кабул кылгучыларны өндәрмез»,– диделәр. Хан әйде: «Бәнем дөнйада күрдегем ошбу кыз балам ирде, гайре балам йукдыр, аңа шифа кыйлсаңыз вә йаңа чавыл йафрагы илә дуркә багласаңыз, бән сезнең динегезне кабул идәрмен», – диде. Әлкыйсса, Пәйгамбәремез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бу өч сәхабәгә өч нәрсә бирмеш иде. «Сезләрдән кәрамәт эстәдекләрендә бу өч нәрсәдән истимдад кыйласызлар»,– див. «Гамамә» – аны Габдерахман бине Зөбәйерә бирмеш иде, вә «дәват» – аны Зөбәйер бине Җәгъдәйә бирмеш иде, вә «тай-

ак» –аны хәзрәте Тальхәйә бирмеш иде, разыйаллаһу ганһүм. Чун бонлар ул дәватны куйеб, дәватә тайакны кадаб куйдылар, хәзрәте Габдерахман разыйаллаһе ганһү, Пәйгамбәр галәйһиссәлам бирдеге гамамәне башына чолгаб ике рәкәгать намаз кыйлды. Бу ике сәхабә «амин» диделәр. Чун ул тайак озайеб, йәшәреб, бәрәкәтендән бонларә бер олуг ботаклы чавыл улды. Андан дүркә баглаб хан кызыны хәммамә йибәреб чапдырдылар. Дәрхаль ул кыз сыйххәт табыб хан сарайына йегереб кайтды. Бу могҗизатларны вә кәрамәтләрне күреб, дине Исламның сыдкына тасдикъ идеб, Айдар хан иман килтереб пакь мөселман улды. Андан Бараҗ вәзир, калган шәһәр җәмагатьләре һәм бу айатьләре күреб, барчалары мөселман булдылар. Бу өч сәхабә Шәһри Болгарда өч йыл калдылар. Дин вә әхкям үгрәтделәр, җомга вә гайед укыдылар. Пәйгамбәремез галәйһиссәлам вирдеге тайак илән хотбә укыдылар вә мәдрәсәләр бина әйләделәр. Чункем дине Исламны үгрәтеб, халаикъ диндә росух табыб, сәбати тапдыклары бәгъдендә өч йыл морурында ул ике сәхабә Мәдинә’и Мөнәввәрәйә кайтдылар. Хәзрәте Зөбәйер бине Җәгъдә разыйаллаһу ганһү Болгарда калды. Ханның кызы Туйбикәне никахлап алды. Хәзрәте Зөбәйер бине Җәгъдә разыйаллаһу ганһү йегерме биш йыл гомер идеб, тәгълим биреб, вафаты Болгарда улды. Әлхәмдүлилләһи би нигъмәтиһи тәтәмәс-салихат.

### Фасыл минәт-табигыйн фил-Болгар вә тәвабигыйһи

Хәзрәте Зөбәйер бине Җәгъдә разыйаллаһу ганһүдән тәгълим алган табигыйнләрнең заманлары, тарих һиҗрәтнең йөз дә туксан бишенче йылында[15] һичбер табигыйн калмады Болгарның үзендә һәм табигы булгучы илләрендә. Имде Болгарның үзендә улгучы сәхабәдән дәрес алган табигыйнләр бәйанын- дадыр. Әүвәл – Дауд Хафиз Ишай углы. 2 нче – Нәдер Хафиз Бикбай углы. 3 нче – Идашбай Пулад углы. 4 нче – Ишбулад Хафиз Әйүббирде углы. 5 нче – Туйчы Хафиз Тукмөхәммәд углы. Ал-

[15] Йөз дә туксан бишенче йыл – милади белән 810 – 811 еллар.

тынчы – Сифән Әлмәт углы. 7 нче – Кадерлекол Өмидлекол углы. 8 нче – Өмидлекол Мирас углы. 9 нчы – Мирас Кәнҗебай углы. 10 нчы – Ишбулат Шәмгун углы. 11нче – Байгол Тукбирде углы. 12 нче – Йуныс Ишкенә углы. 13 нче – Ишкенә Хафиз Мөрсәлим углы. 14 нче – Йалчыгол Хафиз Мәмәткол углы. 15 нче – Илмәмәт Ишмәмәт углы. 16 нчы – Туркай Хафиз Айпулат углы. 17 нче – Ибраһим Хафиз Шәмгун углы. 18 нче – Илтабан Кадергол углы. 19 нчы – Байбакты Имәр углы. 20 нче – Илчегол Йалчыгол углы. 21 нче – Иткусды Дәүләтбай углы. 22 нче – Нәрембай Хафизбай углы. 23 нче – Нәдершаһ Бәдершаһ углы. 24 нче – Хоррәмшаһ Чирмеш иле углы. 25 нче – Госман Кадергол углы. 26 нчы – Бәдәм Хоррәмшаһ Чирмеш иле углы. 27 нче – Иделбакты Уразай углы. 28 нче – Уразай Четай углы. 29 нчы – Алтынбүкән Котлыбай углы. 30 нчы – Җанъйегет Бикъйегет углы. 31 нче – Җанбакты Котлымәт углы. 32 нче – Үнгән Усман углы. 33 нче – Котлыбай Хафиз углы. Бу зикер улындыгы 33 кемсәнәләр табигыйнләр барчасы кәляме Раббани Вәхийе Самәданины йад алган кемсәнәләрдер. Гафләт улынмайә, бонларның төрбәләре барчасы Шәһри Болгардадыр.

### Фасыл фит-табигыйн мин нәвахийел-Болгар

Әүвәл Уралның җанибе гарбисендән килеб сәхабәдән тәгълим алган башкорт дидеге кабиләдән. 1. Аиткол Заит углы, Ай суы буйындан килгәндер. 2. Котлыбай Дәүләтбай углы. 3. Иткусды Муйнак углы. 4. Итимгән Кылыч углы. 5. Уразбакты Бөрҗан углы. 6. Таймас Тайс углы. Бонлар Ай дәрйасындан килеб сәхабәдән тәгълим алыб кайтыб йортларыны мөселман әйләндермешләрдер, рахимәһүм Аллаһы Тәгалә. Йәнә Өфе иделендән килгән табигыйнлар. Өфе иделе кушылган йире Ак иделдер. Анда нугай ханы Байчура ханның йортыдыр. Андан килгән табигыйнның берсе Җәйәнкол Иманкол углы. 2. Иманкол Нәдер углы. 3. Җаманай Сарманай углыдыр. Каберләре Өфе тамагындадыр. Өфе иделе берлә Ак идел кушылган йирдән түбәнрәк гарби тарафындан Дим суы койган йирдән йырак дүгел Төрмә авылындан табигыйн Әхмәддер Котлымөхәммәд углы.

Вә һәм шул Дим дәрйасындан килгән суфи Уразбакты Айдагол углы, Мәскәү Тимерпулад углыдыр. Йәнә Исан Йосыф углы, Муллагол Әләмгол углы, Аллагуат Ишпулат углы. Бонларның каберләре Дим буйындадыр. Йәнә Сармәсан Кармәсандан килеб тәгълим алган табигыйнлар: Ибраһим Исмәгыйль углы, Сөләйман Муса углы, Җәмагол Айдагол углы, Алдар Калдар углы. Бонларның каберләре Сармәсан Кармәсан буйындадыр. Ак нәһерендә ултырган Тугаш хан авылындан ике кемсәнә табигыйн улыб Болгарда тәгълим алыб кайтыб анда булгучы нә кадәр башкорт вә мишәр таифәләрене ислам әһеле кыйлдылар. Берсе – Морадым Хафиз, икенчесе – Мөхсин Хафиз Йулдаш угланларыдыр. Йәнә Минзәлә йылгасында, Минзәлә йылгасының башында Дусем авылында Дусемдер, йәнә Илбактыдыр. Бонлар Нийаз углыдыр, әгъләм табигыйне Болгардыр. Йәнә Ак суының Ак иделгә койган йиренә йакын ике табигыйн вардыр. Берсе Дауш хандыр, берсе Көлел хандыр, һәр икесе бер тугмалардыр. Бонлар һәм башкорт вә мишәр таифәләрене әһле ислам әйләделәр. Йәнә анлардан йырак дүгелдер Илбакты Уразбакты углы табигыйндыр. Йәнә Ак иделнең шималь тарафындан Туймы йылга тамагында Содумдан, йәгъни Алабугадан, Содум Йунан лөгатенчә алабуга балыгыны әйтерләр. Ул Содум бик олуг шәһәр иде, аны Искәндәр Зөлкарнәйн бина әйләмеш вә һәм Болгарны. Халя анларны хәзрәте Мир Тимер вәйран әйләде. Йәнә Алабугадан барыб Акбаш Хуҗа Әкбәр табигыйны Болгардыр, вә һәм хафизе Кәламуллаһидыр. Аның йулдашлары: Кәрсан Илмәмәт углы, Әләмгол Муллагол углы, Айдар Аит углыдыр. Йәнә Йулдаш Мәскәү углы. Йәнә Ак иделнең шәркый тарафындан, Алабугадан йырак ирмәс, Мәләкәс авылында Сәйид Сәйдар углы, Тукбай Байгол углы, Җанбакты Уразбакты углыдыр. Бонлар һәм табигыйнларның газизләрендин ирде. Йәнә Ак иделнең шәркый тарафындан Субай Сабай углы, Иманай Йаманай углы, Ишбирде Тукбирде углы Субай авылындан килеб сәхабәдән тәгълим алдылар табигыйн лардыр. Шәмди каберләре андадыр. Йәнә Субай илә Шинкилче бер тугма, һәр икесе Барс ханның углан лары ирде.

www.darulkutub.com

Шинкилче хан һәм Болгара варыб сәхабәгә бәйгать бирделәр. Анының йулдашы Зәй буйында Байгол Айдагол углы, Атый Җенле углы, Чаллы Туксабай углы, Ак Сарыбай Сары углы. Бонлар Зәй буйындан килеб сәхабәгә бәйгать бирделәр. Бонлар һәм табигыйн лардыр, каберләре Зәй буйындадыр. Йәнә Кичу суындан Үтәш Илтәбан углыдыр, Нәдер Иманкол углы, Йаманай Сабанай углы, Нәдершаһ Хөррәмшаһ углы. Шәмди каберләре андадыр. Ак иделгә койган. Чушым буйында Тубылгы атавы кальгасында улган: Мирас Иштуган углы, Аит Заит углы, Хаҗи Бәйрам Хаҗҗәкилде углы, Касыйм Әйүб углы, Габдерахман Габделмәннан углы, Илһам Кәйумарс углы, барчалары Тубылгы атавы кальгасында дәфен улынмышлардыр. Чирмешәннең һәр икесендә табигыйн чукдыр. Без нәкыйль итдеге мәкалате табигыйнда улан китабда күрелмәде, әмма сахибе әйде: «Бу ике нәһердә улан табигыйнларның гадәдләре беленмәде, зира ки чугы сәхабә каберенә мөҗавир улайык див Болгара күчеб килделәр, күбрәгенең вафаты андадыр»,– диде. Нократ иделенә койдыгы Шушма буйында улган табигыйнларның хисабы: Хәсәншәйех Кадер углы, Балтач Нәдер углы, Салавыч Абайдан углы, Исмәгыйль Абзан углыдыр. Шәмди каберләре андадыр. Йәнә Казан суы буйында Казан башында Иштирәк Байтирәк углы. Йәнә Курсада Гадел Абдул углы. Йәнә Кәче илендә Зөлмөхәммәд Хаҗи

Мөхәррәм углыдыр. Йәнә Гайшәбикә авылында Гайшәбикә үзедер, Хаҗи Әрәмле разыйаллаһе ганһү, кызыдыр. Хаҗи Әрәмле Мәдинәдә торыб Пәйгамбәремез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмдән тәгълим алды, сәхабәдер. Йәнә Хаҗи Әрәмле разыйаллаһу ганһүнең углы Таҗеддин әфәндедер. Бонларның каберләре Казан суы буйындадыр. Йәнә Вулгының аргы шәркый тарафында Зөйә тамагында табигыйнлар. Илйас Муса углы, Касыйм Ибраһим углы, Уразмөхәммәд Кадермөхәммәд углы, Борһан Садырхан углы. Бонларның каберләре Зөйә тамагындадыр. Уҗым авылында Фәйзулла Гобәйдулла углыдыр, Күк Күз авылында Каймөхәммәд Динмөхәммәд углыдыр. Мулла илендә Муллагол Айдагол

www.darul-kutub.com

углыдыр. Нәрембай Әҗим углы, шәмди каберләре андадыр. Тәтеш авылында Элгән Үткән углыдыр. Шырдан авылында Сөләйман Каспулат углыдыр, Бадамшаһ Әҗдан углы, Җөмади Тимерпулат углы, Нәдершаһ Сәлим углы, Сәлим Ишкилде углы. Бонлар мишәр таифәсендәндер. Шәмди андадыр. Бигешт авылында мишәрләрдән Тимуш Хаҗи Солтанморад углы, Илһам Ибраһим углы, Симуш Килдебай углыдыр.

## Фасыл фи бәйани тәбгы табигыйн минәл-Болгар

Бу тәбгы табигыйн[16] заманында Болгарда дине Ислам куәтле булды. Мөҗтәһидин заманлары ирде. Хәким хан заманы ирде. Тәбгы табигыйн гадәдләре намәгълүмдер. Мәшһүр улан таләба’и гыйлемдән бәгъзиләре Багдад вә бәгъзиләре Харәзм чыгыб китеб чугы Харәзмдә вә Багдадда вафат улдылар. Бонда безнең Болгара кайтыб дәрес әйткән Хисамеддин бине Ибраһим «Ысул» китабының «Тәхкыйкы Хисамийә»не тәсниф әйләде. Фөругыдан «Тимер ташы»ны тәсниф әйләде. Болгарда әкъсарел-ләйалдә имам Шафигый мәзһәбе берлән йәстү намазыны бәгъдәл-мәгъриб берәр сәгать үткәч укымак илә фәтвә бирде. Вә дәхи җомга намазында мисыр шарт имәсдер, имамдин башка өч кеше берлән җомга үтәмәгә фәтвә бирде. Вә дәхи җомганың сөннәт азаныны укымак калдырмаслык берлән фәтвә бирде. Вә бу өч фәтвәне Багдада гарыз идеб имам Әбу Иосыфдан фәтвә эстәделәр, ул заманда хәлифә Һарун әр-Рәшид ирде. Фәтвәсендә йазмыш ки: «Йа шәрикәна ма таләбтә минни фәтвә фи һәзал-әмр. Йәкфә фәтвәкә галә мәзһәби әһлис-сөннәти вәлҗәмагати. Фә иннә каулеш-Шафигый рахимәһү Аллаһу Тәгалә фи хаккыйл- гаша’и вәл-Хаҗҗаҗ бине Йосыф фи хаккый әзани сөннәтүл-җомгати каулу мәзһәбина. Вә галәйкәл-гамәл фи бәләдикәл-Болгар. Вәс-сәлам галә мин әтбәгыйл-һөда», див фәтвә вирмешләр. Йәнә голәма’и тәбгыт-табигыйндан Габделлатыйф бине Габдуллаһдыр. Сахибе «Шәрхе мәҗмәгыль

[16] Тәбгы табигыйн – сәхабәләрдән белем алган иярченнәрдән белем алган иярченнәр.

www.darul-kutub.com

Бәхрәйн» вә сахибе «Имдадел-Фәттах »дер. Йәнә Нух бине Мәрйәм[17], мөҗтәһидләрнең олугыдыр. Китабе «Мөгаййенел-Хөкям»ны вә «Фәваидел-Фокаһа»ны ул тәсниф әйләде. Кабере шәмди Болгардадыр. Мәгруф имам Хаһәрзадә Болгариның каберләре Харәзмдәдер. Йәнә мәгъруф Гайсә бине Әбандер[18], каберләре Болгардадыр. Йәнә мөҗтәһидләрдәндер Әхмәд бине Мөхәммәд бине Әбу Бәкер Болгарда «Хизанә» сахибедер, каберләре Болгардадыр. Йәнә Муса бине Раһвийәнең кабере Болгардадыр. Вә гайре мөҗтәһидләр фил-осул вәл-форуг Болгар каберстанында чукдыр. Вә бәгъзиләр Кашгар зәминдән килеб, зийарате бәйтуллаһ үзрә хаҗ бардыгында вә кайтдыгында Бохараның вә Харәзмнең суфилары вә галимләренең вафаты улдыкларының хисабы йукдыр. Вә һәм Габдерахман Җаминең[19] кабере Болгардадыр, хаҗ бардыкда вафат ул мышдыр. Йәнә Мәүләви Хөсрәвийәнең, йәнә Мә үл ана Мохаккак Габделхәкимнең каберләре Болгардадыр. Вә гайре фазыл вә салихларның каберләренең ниһайәте йукдыр. Тәбгы табигыйны Болгар тарих һиҗрәтнең 230 нчы йылында[20] һич берсе калмады, вафат улдылар, рахимәһүм Аллаһы Тәгалә рәхмәтән васигатән.

### Фасыл фи бәйанит-табигатил-Болгарийә

Хикмәте Бари Тәгаләнең икътизасы илә вә кәүкәбе сәгадәт бәхшаләренең мосагыдәтеилә хаватин зөмрәсендән ничә вә ничәләр сэхабэ’и кирамләрә талиб улыб, дине Исламның фәраизы вә ваҗибатене, вә Коръән газыймеш-шаэннең кыйраәт вә тилявәтене мөшафиһать үгрәнгәнләрнең ибтидасы, хәзрәте Зөбәйер бине Җәгъдә разыйаллаһу ганһүнең тәхтә никахында улан Туйбикә Айдар хан кызыдыр. Йәгъни, өч сәхабәнең кәрамәте илә сыйххәт табкан. Йәнә Хәдичә Дауд Хафиз кызы.

---

[17] Нух бине Мәрйәм – 789 елда вафат була.

[18] Гайсә бине Әбан – 835 елда Багдад шәһәрендә вафат була.

[19] Габдерахман Җами – мәшһүр Иран шагыйре һәм галиме Габдрахман Җами. 1414 елда һерат шәһәрендә туа һәм 1492 елда шул ук шәһәрдә күмелә.

[20] 230 нчы йыл – милади белән 844 – 845 еллар.

Хафизә Нәдер кызы. Биксолтан хаҗийә Уразмәт Хафиз кызы. Фатыйма Кыймөхәммәд кызы. Гөлбикә Туйчы Хафиз кызы. Гөлстан Мирас кызы. Рабига хаҗийә Иделбакты кызы. Суфийә Үтәгән кызы. Көмешбикә Тәтеш кызы. Адинәбикә Йалчыгол Хафиз кызы. Гөлбостан Алтынбүкән кызы. Алтынбикә Җанбакты кызы. Гаделбану Нәдершаһ кызы. Хәлимә Илмәмәт кызы. Сабира Илтабан кызы. Гөлсем, Хафизә, вә хаҗийә Ибраһим Хафиз кызлары. Айсылу Йахшыбай кызы. Бонлар барчалары сәхабә разыйаллаһу ганһүмдән Коръән үгрәнгән мәшһүрәләре йазылды. Намәгълүмләре чукдыр, ризванә Аллаһу галәйһим әҗмәгыйн.

## Фасыл фи бәйанил-мәшаихил-кирам вәл-әүлийа’и-гыйзам фил-Болгар

Шәмди мәгълүм ула ки, тарих һиҗрәтнең тугыз йөз сиксән тугызына[21] варанча улан әүлийәләр бу фасылда ирад улыныр иншаллаһу тәгалә, бәлки тугыз йөз туксан тугызына[22] варанча әүлийәләр ирад улыныр. Әүлийәи Аллаһы Тәгалә мәшһүр фил-мәшрикъ вәл-мәгъриб. Нократ иделенә кыйбла җанибендә аккан йылга вардыр, исеме Бөредер, Казаклар авылында Бәйраш бине Әбраш суфи вардыр. Ул «зикре җәһрийәнең» сахибыдыр. Вә изен вирелмеш кешедер. Үзе Төркестанда Хуҗа Әхмәд Йәсәви рахимәһү Аллаһуның талибләрендәндер. Мөрәххәс улыныб Болгар таифәсенә җибәрелде. Үзе Ку кан кешесе иде, андан тәгълим алды. Шул нәһре Бөренең буйында Адай Чирмешнең авылында Ишмөхәммәд Тукмөхәммәд углыдыр[23], аты «Шәйех Баба» див ләкаб куймышлар. Ул Хуҗа Бәйрашдан тәгълим алыб халкы газыйм аңа мөрид улды лар, һәм үзе зикре җәһрийәләрдән ирде. Ул утыз алты йыл мөрид тәрбийә кыйлды. Ул арада йегерме йыл бетмәмә ул өслүб үзрә сөлүкнең йулындан тәсаввофны белгән бәһрәмәнд кемсә калмады. Ул заманда Йәркәндә шәйех

[21] Тугыз йөз сиксән тугызы – милади белән 1581 ел.

[22] Тугыз йөз туксан тугызы – милади белән 1590–1591 еллар.

[23] Ишмөхәммәд Тукмөхәммәд углы – 1795 елда әле исән була.

һидайатуллаһ Хуҗа Әхмәд Йәсәвинең мөриденең мөриде вар иде. Болгар таифәсендә тәсаввоф белгән кемсәнә калмады, голәма заляләтдә калды, ул шәйех һидайатуллаһ мөрид улыб китде. Болгар тавабигында Тәрбирде Чаллысы авылында Идрис Зөлмөхәммәд углы. Ул Идрис Йәркәндә китде, варыб шәйех һидайатуллага мөрид улды. Унбиш йыл андан әдәбе тәсаввофны үгрәнде. Мәзбүр суфи Ишмөхәммәд вафатындан соңра йегерме йыл тулгач, ул Идрис хәлифәне Болгара, вә Тубылга, Өфе, Казан вә Сембер вилайәте тәвабигъларына йибәрелде, тәсаввофдан тәгаллем вирер өчен. Өфе йорты аны хурлаб вә кыйнаб йибәрделәр. Андан килеб Казан вә һәм Болгар әтрафларына тәгълим бирде. Бераз җәмагать андан тәгълим алдылар. Үзе Тәрбирде Чаллысында вафат улды. Андан Йаңа Казанның Касыйм Шәйех Ибраһим углы тәрбийәләнеб хәлифә улды. Ул һәм Казанда торыб күб җәмагатьне тәсаввоф йулына салды, шәмди кабере Казандадыр. Ул вафат улдыгыдин соңра Фәйзулла әфәнде Бохарадан килеб Казанда торды. Ул һәм унбиш йыл халаикъка тәгълим бирде, шәмди кабере Казандадыр. Йәнә Чаллы корбендә Казаклар авылында Шәгым бине Иштирәк ахунд Багдаддан укыб кайтыб, каиме мәкам, хәлифәте Фәйзулла әфәнде улды. Ул һәм гыйльме «Каль» вә «Халь» илә Казан, Өфе, вә Алатыр вә Сембер вә Саратау вә Сарайчын вә Тубыл халкына дин вә шәригать йулыны үгрәтде. Шәмди кабере Тәрбирде Чаллы Казаклардадыр. Йәнә Бирдебәк ханның авылында Чаллы Тәрбирденең корбендә Бохараның хәлифә’и хәзрәте Габдессәлам хаҗи Хәбибулла кабере вардыр, Котлы Бүкәш авылында Бохараның мулла Нийаз Чукмакый кабередер, һәр икәве хаҗ бардыкларында Бирдебәк ханның заманында вафат улдылар. Бүләрдә бер кайынлык арасы чокырның йугарысында менгәндә, сул кабыргасында өч әүлийә’и гыйзамның кабере вардыр. Берсе – Хуҗа Әсгардер, Мәгълүм Хуҗа дийерләр. Икенчесе – Габдулла Хуҗадыр, Чубар Габдулла димәклә мәгъруфдер. Өченчесе – Шәйех Мөхәммәддер. Багана авылындан чыккан Байтирәк углыдыр. Багдадда тәгълим алыб кайтыб Бүләрдә дәрес әйткәндер. Йәнә Чирмешәндә Кизләү

чишмәсендә Хуҗа Мәхдүм задә Йосыф Күргәнинең кабере вардыр. Җанбакты авылында галлямә’и Дәвванинның кабередер. Йәнә Җанбакты авылында шәйех Хөсрәвийәнең кабередер. Хаҗ бардыкларында вафат улмышдыр. Шагыйрь Сәнаиның кабере Иделгә койган Чишмә йылгасының тамагындадыр. Йәнә Кичү буйында, Кичү суы Чишмәгә койган йирендә Тубылгы атавы кальгасы корбендә Хуҗа Әхрарның кабередер. Зәй тамагында Гариф билләһи сахибе Тәфсир Хөсәйен Вагыйзыйның кабередер, хаҗ бардыкда вафат улмышдыр. Бараҗ хан заманында ирде. Йәнә Ирнә тамагында Бәйраш ханның йортыдыр. Галим фазыл хандыр. Аның заманында Ташкәнддән килеб бер галим фазыл хан дәрес әйтде, хаҗ бардыкда Бәйраш ханның йортында торыб. Ул нугай ханы ирде. Ул галим фазылның исеме Ирнийаз Ширнийаз углыдыр[24]. Мулла Хафиз әт-Ташкәнди димәклә мәшһүрдер. Хафизе Кәляме Раббани вә кораэ иде. Ирнә тамагында вафат улмышдыр. Йәнә Минзәлә суының тамагында Мостафа ханның йортыдыр. Анда гариф билләһи Хуҗа Бәйрамның кабередер. Йәнә Ак иделнең йарында Чаллы суының тамагында Мәүлед Хуҗаның кабередер. Йәнә Ак идел корбендә Байчура Чирмешнең авылында Төркестанның Хуҗа Әхмәд Йәсәвинең мөриде Хуҗа Әмир Кәлалның кабередер. Хаҗ бардыгында вафат улмышдыр. Йәнә Алабугада Бәйрам Хуҗаның кабередер. Йәнә Ак идел башында Хуҗа Солтан Морадның кабередер. Дим суы буйында Кыпчак авылының каберендә Хуҗа Ту кашның вә Хуҗа Биктәшнең вә Сөләйман Хуҗаның каберләредер. Йәнә Үршәк суы тамагында Гарифулла Хуҗа Гыйсмәтулла әс-Сәмәркандинең кабередер. Вә ләкин Уралның икенче тарафындагы Җайык вә Сакмар буйындагы авылларның исем вә каберләре йазылмады. Безләрнең үзгә йортлар бәйанында улган вә һәм әкалимләр бәйанында улган икенче тәфсыйлән йазган рисаләмез вардыр, андан карайасыз. Әмма Сарайчыкда улан вәлиләрне бәйан идәлем, аның өчен бу рисалә табигыйн вә тәбгы табигыйнлар бәйанында галә

[24] Ирнийаз Ширнийаз углы – 1790 елда Оренбург шәһәре янындагы Каргалы бистәсендә һәлак була.

www.darul-kutub.com

хәддиһи йазылмышдыр. Сарайчыкда улан табигыйнлар зикер улыныр. Әүвәл Зәйнелгабидин Уразбакты хан углы, Дәүләтшаһ Хоррәмшаһ углы, Гыйzзәтулла Насрулла углы, Гали Госман углы, Муса Сөләйман углы, Дауд Нәдер углы. Бонлар барчалары Болгара варыб хәзрәте Зөбәйер бине Җәгъдәнең Талибларыдыр, разыйаллаһу ганһүм әҗмәгыйн. Вә тәбгы табигыйнлардан улан Әднаҗ әфәнде Котлыбай углы, Ширгазый әфәнде Бугазый углы, Котлыбай Дәүләтбай углы, Габдулла әфәнде Гыйзәтулла углыдыр. Әүлийәи кирамдән Бәдреддин Хафиз Госман углыдыр, вә Госман Хафиз Гайедкол углы, Хуҗа Габделбакый Диванкол углы, Котлыбулад Хуҗа Илбакты углыдыр. Вә гайреләр чукдыр, мәшһүрләрене йаздык. «Аллаһөммә әҗгальнә мәга зөмрәти өхиббаикә вә әүлийәикә».

Хатимәтел рисаләтел Болгарийә фи зикри мәүлана Сәгъдеддин әт-Тәфтазани вә хәзрәте Тимер Газый Солтан вә тәхрибел Биладел-гыйнадийа вәл-фискател-мораддәт вә харабы Шәһри Болгар

Тарих һиҗрәте нәби саллаллаһу галәйһи вә сәлләмдән сигез йөз алтмыш икенче йылда[25] хәзрәте Аксак Тимерне[26] Аллаһы Тәгалә хәзрәте мөсәлләт идеб бу робгы мәскүндән күб шәһәрләрне хараб вә һәлак әйләде, фисык вә гыйсйан кылдыгы шәһәрләрә вә бәче базлара вә һәм эчкечәләрә вә занилара Аллаһы Тәгалә әмре мәгъруф вә нәһи мөнкәр идәр өчен мөсәлләт әйләде. Ул Аксак Тимер хәзрәтләре Хытайның шәркый сәрхәдденә варыб, Тәхте Сөләйман дидеге шәһәрнең карибендә Алмалы дигән авылдандыр. Ул заманда Хытайның падишаһы Чыңгыз хан[27] ирде. Аны дине Ислама дәгъвәт әйләде, кабул кыйлмады. Аны үлтерде. Хытайның чук шәһәрләрене хараб әйләде. Ахырда Хытай халкы аңа бәйгать бирделәр вә хараҗә разый улдылар. Хытай йортына Чыңгыз ханның углы Турымтайны падишаһ куйды. Ул заманда Кызылбашның Мәшһәд дидеге шәһәрендә Надир шаһ исемле кемсәнә хоруҗ әйләде. Әһле сөннәтнең күб

---

[25] Сигез йөз алтмыш икенче йыл – милади белән 1457 – 1458 еллар.

[26] Аксак Тимер – 1405 елда үлә.

[27] Чыңгыз хан – 1229 елда ук вафат була.

шәһәрләрене алды, вә голәмадан улгучыларны кател әйләде. Үзенең бәд мәзһәбенә халыкны дәгъвәт әйләде. Ахырында Бохараны вә һәм Сәмәркандне вә Үргәнечне алды, вә Хиваны алды вә хан ларны үлтерде, үзенең батыйль мәзһәбенә өндәде. Әһле сөннәт вәл-җәмагать гыйльме йыгылды, зира әһле сөннәт улан җәмагать аз иделәр, равафиз горуһы тигрәсендә чолганмыш иде. Әһле сөннәтләр зарилык әйләделәр. Аллаһы Тәгалә анларның догаларыны кабул әйләде, хәзрәте Аксак Тимер Хытайның Пикин дидеге кальгасына гаскәре илә газа кыйлырга йарагланыб тордыкы заманда Аллаһы Тәгалә Хызыр зәндәне йибәрде: «Баргыл, колым, Әмир Тимергә айгыл, Бохарага барсын, анларны кызылбашлыкдан халас әйләсен вә һәм Надир шаһны[28] үлтерсен. Син аның гаскәренең мөкаддәмендә улгыл»,– див дөшенә керде. Әлкыйсса, Хызыр галәйһиссәлам кальгасына тизлек үзренә килеб хәзрәте Мир Тимерә бу хәбәрне бәйан әйләде. Хәзрәте Мир Тимер Хытай йортындан гаскәре илән чыкды, хәден Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәздер. Гакыйбәт Пикин кальгасыны, вә Нажин кальгасыны вә Хытайның гайре кальгаларыны алыб харaҗә разый булыб калдылар. Әлкыйсса, хәзрәте Мир Тимер Хызыр галәйһиссәлам илә газәме Бохара әйләде. Төркестана уграды. Төркестанның Хуҗа Әхмәд Йәсәви Мир Тимернең дөшенә керде: «Әй, егет, тизлек үзрә Бохарага варгыл, иншаллаһы Тәгалә, ул Надир шаһның үлмәге синең алдыңдадыр. Синең башыңдан күб эшләр кичсә кирәкдер,– диде.– Җәмигъ Бохара халкы сиңа мөнтазырлардыр», – диде. Бу дөшне күреб уйганды, сәҗцәи шөкер кылды. Әлкыйсса, иртә торып Төркестанның ханы ул заманда Нугайбәк дигән хан иде. Аңа чук хәзинә вирде, хәзрәте Хуҗа Әхмәд Йәсәвинең каберенә астана бина әйләмәк илә. Төркестан ханы гаҗаиб бина әйләде ки, әнваг зиннәт илә, әлхаль бардыр. Андин хәзрәте Мир Тимер Сәмәркандкә гаскәре илә газәм әйләде. Сәмәрканддә Надир шаһның бер биге бар ирде, аны үлтерде. Ул заманда Надир шаһ Бохарада ирде. Аксак Тимер килерене ишедеб гаскәре илә Бохарадан кальгайы Мәшһәдә качды. Үз урынына Кызылбашдан бер биге Бохарайа куйды, кырык мең гаскәр илә. Ул арада Аксак

[28] Надир шаһ – Иран хөкемдары, 1747 елда һәлак була.

www.darulkutub.com

Тимер Бохарайа килде, кальганы хисар идеб. Аксак Тимер илә ул Кызылбаш биге ике ай җәнг әйләде. Гакыйбәт Аксак Тимер ул кызылбаш бигене әнваг газаб илә үлтерде. Калдык гаскәрне Бохараның олугларына кол итеб тәкъсим итде. Бохарада ике ай сакин улды. Солтан Морад дидеге талибел гыйлемне Бохарайа хан әйләде, зира ки ул Солтан Морад хан нәселендән ирде. Надир шаһ ул угланның атасы Сәлим ханны үлтермеш ирде. Бу Солтан Морад бишекдә бер дайә кулында калмыш ирде. Надир шаһ ул дайәдән сорады: «Кулыңдагы углан кем угланы? – диде.– Сәлим угланы дүгелме?» – диде. Дайә әйде: «Бинем үземдән тугандыр, без коллармыз»,– див җаваб вирде. Надир шаһ аны үлтермәде. Шул углан Солтан Морад ирде.

Аксак Тимер аны Бохарайа хан әйләде. Ант эчде: «Ул Надир шаһны әһле сөннәт идәрмен, кабул әйләмәсә, үлтерермен», – див. Бохарадан чыгып китде газме Мәшһәд әйләде. Әлкыйсса, Надир шаһ гаскәре илә газыйм җәнг улды. Бер йыл сугышды гакыйбәт Надир шаһ галиб улыб башыны кисде вә шәһәрне хараб әйләде. Китде сәрхәдце Һиндстанә дигән Кызылбаш шәһәрләрене барсыны хараб әйләде. Кайтыб килдеге заманда йуллары Һәрат шәһәренә уграды. Һәрат падишаһы хәзрәте Аксак Тимерне гаскәре илә каршы чыгыб алды. Шәһәргә кергезделәр, ике ай кунак әйләде. Бәгъдә бер кичә төшендә Хызыр галәйһиссәлам хәзрәт Мир Тимернең дөшенә керде. Әйде: «Әй, җегәр кошым, углан, тиз рәванә улгыл Истанбулә вар. Анларның солтаны бәчебазлык кыйладыр вә һәм каһвә эчеб, челемкәш улыб, җәмагать намазындан калалар вә һәм өйләрендә фәраизе хәмсәнең вакытларыңдай үткәрәләр вә һәм шәһәрендә галим голәмасы шиләдер. Анларны ул әгъмалләрендән тәүбәйә өндәгел»,– диде. Чун иртә торыб бу дөшне Һәрат падишаһына сөйләде. Видаг әйтеб гаскәре илә газме Истанбул әйләде. Чунки Истанбулә ирешде. Истанбул[29] солтаны ул заманда Мәһди Солтан[30] ирде. Аксак Тимер килдегене ишетеб кальга капуларыны баглатды вә илче йибәрде бу илә див: «Син мөселмансын, нә

[29] Истанбул – элеккеге Константинополь шәһәре төрекләр тарафыннан бары тик 1453 елда гына басып алына.

[30] Мәһди Солтан – төрек патшалары арасында андый кеше юк. Аксак Тимер төрек солтаны Баязит белән сугыша.

үчүн бәнем илә җәнг идәрсен»,– див. Аксак Тимер әйде: «Син бәчебазлыкдан вә кәҗә тәкәләрене сөзештереб уйнамакдан вә гайре ат илә намазә вардыкындан тәүбә ит вә дәхи галим-голәмаң буна мәгкуль әгъмалләр илә мөттәсыйф ирмеш, анлар һәм тәүбә әйләсенләр, мин сезнең илә җәнг вә җидал әйләмәм», – диде. «Зира бән Илһам илә сезләрә килдем», – див җаваб язды. Чун бу җавабы хәлифә голәмаларына күргәзде голәмалар җаваб әйделәр: «Бу Аксак Тимерне безләр галиме зейл-фазыл вәл кәрамәт див ишетмеш ирдек бу һәм бер шайтан ирмеш. Илһам берлә безләрне әһле бидгать див җәнг әйләмәгә килмеш»,– див. «Илһам безнең мәзһәбдә, дәлиле катгый дүгелдер, җәнг әйләмәк безләрә важиб улды», – див җәнг әйләделәр. Әлкыйсса, хәзрәте Аксак Тимер боларның җавабында йыглады: «Бән Хызыр галәйһиссәламне дөшемдә күрмәк илә вә аның әйтмәге берлә килеб мөлзәм улдым»,– див бәгъдәл гаша’ йыглаб йатды. Дөшендә Рәсүл галәйһиссәламне күрде вә әйтде: «Йа, Мир Тимер, Хызырның сиңа дөшдә күреб әйтәчәк сүзе хакдыр, Истанбуллар ул әгъмалләрне кыйлмаклары хакдыр. Бу кичә Аллаһы Тәгалә ул бәчебазлык кыйлгучы Солтанның вә һәм йегерме кәттә голәмаларындан улгучыларның аләтләрене мәмсух әйләде – диб Мир Тимернең күзендән гайеб улды». Мир Тимер хәзрәте торыб госел әйләб Аллаһы Тәгаләнең кодрәтләренә таң-гаҗәибкә калыб торды. Тәфәккер әйләде. Иртә берлә торыб галим-голәмасыны җәмыг әйләде. Бу дөшне сөйләде. Голәмалары бу дөшкә хәйран калдылар. Голәмасындан берәве әйде, исеме Гали Кошчы[31] ирде. «Бу Истанбулда минем бер ашна галимем бардыр,– диде,– Дауд әфәндедер. Сәгъдеддин Тәфтазани хәзрәтеләрендә бергә дәресдәш улыб алты йыл бергә торыб идек, – диде. – Зира бәнем илә күб заман тоз вә икмәк йийеб ирдек».

«Истанбулда андан әгъләм әфәнде йукдыр, аның һәм аләте мәмсух улса ул бәңа әйтер»,– диде. Мир Тимер әйде: «Йа, әфәнде, шәһәр капулары баглыдыр, Син кайдан кереб белер-

[31] Гали Кошчы – мәшһүр Урта Азия математигы һәм астрономы Галәэтдин Гали бине Мөхәммәд Кошчы, 1474 елда төрек солтаны Мәхмүдкә кунак булып килгән. Истанбулда үлә.

сен»,– диде. Гали Кошчы әйде: «Иншалла Тәгалә белермез»,– диде. Мир Тимер әйтде: «Үзең бел гел»,– диде.

Әл кыйсса, Гали Кошчы хәзрәтләре бер төндә фәкыйранә кийемләрне кийеб Мир Тимернең гаскәрендән Истанбулның кальгасының туры капу ишегенә килде. Каравылчылар әйделәр: «Син кемсең, нә кешесең». Гали Кошчы әйде: «Мин Дауд әфәнденең колымын, Дагстанда сатыб алган ирде бәне, Тәфтазан авылында укыб тордыкы бәне бер Төркстани хаҗи агу биреб алдаб сине угыл бала идәрмен, – див алыб китде. – Ахыр бәне колым, – див, – Куканә сатды. Ул Кукан хуҗам Аксак Тимернең сәргаскәредер. Бәне үзенә хезмәт итәр өчен алыб килгән иде. Бу кичә зафәр табдым, качдым, шәмди ишетдем. Дауд әфәнде сезнең Истанбулда имеш. Бәне пәйгамбәремезнең гыйшкына кальгайа кергезең, бән Дауд әфәндийә керәйем, андин бәхиллек теләйем»,– диде. Каравылчылар әйделәр: «Дауд әфәнде мәсҗеде Айа Суфийаның имамыдыр, шәһәремездә андин олуг данишмәнд йукдыр,– диделәр. Аның колы улсаң йортыны күргәзайен», – тиделәр. Кальга башындан аркан ташлаб кальга эченә кергезделәр, Дауд әфәнде йортыны күргәзделәр. Таң атканча Гали Кошчы хәзрәтләре хәрәм капу сында торды. Ә л кыйсса, мөәзинләр иртә намазына азан укыды. Иртә намазыны чыкдыкда Гали Кошчы хәзрәтене Дауд әфәнде хәрәм капусында күрде. Катигъ йыглады вә әйтде: «Йа, шәрик, бу замана дигән кайда идең. Утыз йылдыр фирак улганымызга», – див икесе йыглашдылар. Мәсҗедә вардылар. Мәсҗеддән кайтыб Дауд әфәнденең өйенә керделәр. Әнваг нигъмәтләр йийделәр, бәгъдәл-тагам Дауд әфәнде каһвә аләтләренең истигъдадында улды. Каһвәне хәзерләб савытлары берлә Гали Кошчыйа куйды. Гали әйде: «Бән зийадә тук булыб ирдем, бәңа каһвә кирәкмәз,– диде.– Икенче шәйхемез суфи Деһканийә бу сәкәрҗәләр белән истигъмалел – тагам вәл шәраб бидгатьдер», – диде. Дауд әфәнде әйде: «Андаг ирсә бер олуг савыт илә бирәйен, зира ки, бу каһвә, безнең Румда бундан кадерле нәрсә йукдыр»,– диде. «Зира ки, бу һәзәм тагамдыр, манигыль-нәүм вәл-шәһвәтдер»,– диде. «Бән һәзәм улырлык, агыр йөк булыр-

лык тагам йииймәдем»,– диде. Йәнә Гали әфәнде әйде: «Йа, вәлиел-нигъмәт Дауд әфәнде, истанбуллылар каһвә эчә-эчә зәкәрләре мәмсух улган див ишетдем, айа бу вакыйга чынмыдыр»,– диде,– йәки бер шайан биәдәбдән чыкканмыдыр. Безнең дийаре Төркестанда бу хәбәр мөтәватирә йакындыр»,– диде. Дауд әфәнде башыны түбән салды, ойалыб. Маңгайындан тир чыкды. Әйтде: «Иә, шәрик, хәбәрең растдыр, әмма кариб мөтәватир димәкең йалгандыр»,– диде. «Белдем ки, син Мир Тимер хәзрәтенең гаскәрендәнсең. Бәнем үземдә ул вакыйга йукдыр»,– диде. Түнә көн диван ханәдә күренде кәгазьләре, солтанның һәм йегерме голәмасының аләтләре мәмсух улынган табиблардан сорадылар, бу вакыйга вармыдыр, бу ни зәхмәт сәбәбле, әсбабе сийә зарурииәнең канкасыннандыр ки иәки гайре әшиаданмы див сүәл әидәнләрдер ки. Анлар җаваб биргәнләр, бу хәл әсбабдан гайредер, бәлки бер вәлинең кәрамәтендәндер див. Бундан элгәре биш йыл мөкаддәм Казыйзадә хәзрәтләре дәхан вә каһвә хәрам див фәтвә бирде вә һәм рисалә дөзеде. Аны ошбу Солтан Мәһди шәһәрдән кудырды. Әйтде: «Вар, сән госманлы мулласы, йиреңдә тор, синдән фәтвә кем сорайдыр»,– диб, йөзләренә кара йагыб йибәрде. Табиблар әйтәләр: «Хәзрәте Казыйзадәнең нәфеседер, дип гайре җаваблары юкдыр»,– диде. Вә һәм Мир Тимернең Гали Кошчы хәзрәтләре икърар әйләде. Бәли, Мир Тимернең имамымын диде, вә һәм Мир Тимернең дәш күрдекләрене вә һәм шәһәргә үзенең ничек кердегене бәйан әйләде. Дауд әфәнде аны алты кич кунак әйләде, йитенче кичәдә әйде: «Сине нә хәл илә гаскәргә йибәрәлем, кальга капуглары баглыдыр»,– диде. Гали әйде: «Сән кайгырмагыл вә гамь йимәгел, керткән Хода гына чыгарыр. Туфрак монда йазылмаса»,– диде. Әлкыйсса, сигезенче төндә Гали әйде: «Йа, әфәнде, бу шәһәрдә синең вармы сине дошман күргән»,– диде. Дауд әфәнде әйде: «Ул сиңа нигә кирәк», – диде. Гали әйде: «Вар улса барлыкны әйткел, әгәр булса, хикмәтене сиңа әйдәрем»,– диде. Дауд әфәнде әйтде: «Бәли, бардыр. Күршемдә бер Нийаз исемле Хуҗа. Эше даим бәчебазлык илә вә кәҗә тәкәсене сөзешдереб, каһвә эчмәк илә

www.darulkutub.com

намазыны фаут идәдер. Бер кәррә бән әйтдем, ул Хуҗайа, әмре мәгъруф әйләдем. Ул бәне сүкде». Әйтде: «Бән сезне Казыйзадә кеби шәһәрдән чыгарырмын, малыңны бәйтел-малга салырмын»,– див ант эчде. «Зира ки, ул Хуҗа кеби Истанбулда бай йукдыр вә һәм Солтан Мәһдигә андан йакын кемсәнә йукдыр. Андан бу хәл эчендә хауфнәгем»,– диде. Гали әйде: «Таңда бәне колым див базарга алыб чыгыб, ул Хуҗага саткыл»,– диде. Дауд әфәнде әйде: «Бу ничек җаиз була»,– диде. Гали әйде: «Бән үзем гакыл вә балигым, чунки синдән кечек вакытда күб-күб тәгълим алдым, мулла улдым, имам Мәлик мәзһәбенчә җаиздыр, иншалла Тәгалә сине дошманыңдан халас идәрем», – диде. Әлкыйсса, иртәгесен, кол кийемене кидереб Дауд әфәнде базарга алыб чыкды. Базар әһле Дауд әфәнденең базарга чыкканига хәйран булдылар, зира ки һәргиз базарга чыкканы юк ирде: «Хәзрәте Гали, кәррәмә Аллаһу вәҗһәһ кауленчә колымдыр. Бу йегет миндән китеб-йөреб кайтды, шәмди икърар кыйлды синең колың – мин диб әйтәдер. Мин күб йылдан бирле хезмәткә тормадым, – диде. – һәм миңа бераз хараҗ кирәк ула»,– диде. Колдан сорадылар ки: «Син Дауд әфәнденең колымысың»,– див. Гали әйтде: «Гали, кәррәмә Аллаһу вәҗһәһ кауленчә кол ымын»,– див. Бу мәфһүмне белмәделәр. Гали Кошчыны Дауд әфәнденең күршесе Нийаз Хуҗаның углына сатды. Нийаз Хуҗаның углы өйенә алыб килде. Нийаз Хуҗага әйтде: «Йа ата, бер кол алдым Дауд әфәндедән», – диде. Нийаз Хуҗа әйтде: «Кани ул кол?» Углы аны килтереб күргәзде. Нийаз Хуҗа әйтде: «Әй, кол, нә һөнәрең вә нә кәсебең бар». Кол әйде: «Кийем текмәк вә башмак текмәк гыйлемлеген белермен»,– диде. Нийаз Хуҗа әйтде: «Бик хуб улыр, миңа шундак кол кирәк иде», – диде. Галине тегү эшенә кушды. Буның берлә йите тегүче колы булды. Чун бонлар тегү текделәр, хәзрәте Мир Тимердән Гали хәзрәтләренең айерылдыгына өч ай булды. Хәзрәте Мир Тимер йыглады, бу галимне кайу угры үлтерде икән, див, хәсрәттә улды. Әзин җаниб, чунки Гали хәзрәтләре ул алты йегет берлә кийем текәрләр ирде. Җомга көн Хуҗа Нийаз җомга намазына китдеге вакытда бонларның тегү тегә торган өйенә ун йәшәр

углан йыглаб керде, әйтде: «Йа, агалар, вармыдыр ки араңызда хат тангучы», – диде. Гали Кошчы әйтде: «Бәли мин белермен»,– диде. Углан хатны бирде, Гали укыды. Хатда йазылмыш ки: «һәза мәмсухел-аләт мин мөнафикъ вә лят гыйндаллаһилмөтәгалин. Йа Гали, укътүлүһ мәга сахибүкүм вәкътүлү ибниһ әл-Хәлид вә әл-Вәлид. Фә инни разыйн минкүм. Сөммә әссәламу галә мән иттәбәгаль-һөдә», димеш. Гали сорады: «Бу хатны сиңа кем бирде»,– диде. Углан әйтде: «Биңа дөшемдә Пәйгамбәремез галәйһиссәлам бирде»,– диде. Вә әйтде: «Тегүчеләр арасында кайусы хат таныса, ул укыб, бу хат эчендәге илә гамәл әйләсен,– диде, – мин өммәтләремдәй разыймын»,– диде. Чунки Гали әйтде: «Йә, углан, син ни өчен йыгларсың»,– диде. Углан әйтде: «Җәмале нөбөввәтне күреб йыглармын, вә икенче, анамны дөшемдә күреб йыглармын, оҗмах кийемләре берлә кийенеб, бәне ике имчәге арасына алыб каты сүде, маңлайымдан үпте. Бу ике кемсәнә кеби җиһанда күркәм кемсәнәләрне күргәнем йук ирде»,– диде. «Бән анамдан айырыласым килмәде, өнем див белдем. Халянки дөшем имеш, вә дәхи анам әйтде: «Өч көндин соң миңа өләшерсең»,– диде, бер локмә нигъмәт бирде. Бер алтын сарайның эчендә ирде. Әйтде: «Бу сарай бәнемдер, боның кеби дәхи кырык йирдә сарайларым бардыр», – диде, «һәрбер сарайларымда чишмәләр балдан вә судан вә сөддән акгандыр, вә ул локмәнең ләззәте әлхаль агызымдан китмәндер»,– диде. Әйтде: «Йа, ага, Пәйгамбәремез галәйһиссәлам сиңа нә бойырмышдыр». Гали әйтде: «Әй, угыл, безгә әмер иткәндер, бу угланның күрдеге дөше растдыр, аның аркасында намазыңызны вакытындан тәэхир итмәңез дигәнләрдер», – диде. Углан әйтде: «Әй, ага, хата сөйләрсең, бу Хуҗа бәнем атамдыр, бәнем анамны шәһит әйләде бәчебазлыкдан мәныгъ әйләдеге өчен, бу Хуҗаны ике агам илә үлтермәгә кушкандыр. Син кол дөгелсең, бу җиһанның кәттә голәмасындансың, вә һәм ике агам бәчебазлыкдан хатынлары мәныгъ әйләдекләре өчен хатынларыны шәһит итделәр. Безнең Истанбулда Солтан Мәһдине хатынлары бәчебазлыкдан мәныгъ кыйлганлары өчен алты хатыныны үлтерде»,– диде.

www.darulkutub.com

Гали Кошчы әйтде: «Сәмигъна ватагъна»,– диде. Гали әйтде: «Йа, углан, бу гамәлләрне кайу көн кыйлайык»,– диде. Әйтде: «Сезләр сишәмбе көн кыйласызлар, зира ки бән дүшәмбе көн кабер ийәсе ул ырым,– диде,– сезләр сишәмбе көн төн йарымында кыйласызлар», – диб атасының бүлмәсенә чыгыб китде. Чунки Гали Кошчы хәзрәтләре йулдашлары илә мошәвәрәт әйләделәр, Пәйгамбәремез бойырган эшне кыйлайык, сишәмбе көн кичәсене көтделәр. Әлкыйсса, Нийаз Хуҗа җомгадан кайтды, шимбә көн углан агырды, йәкшәмбе көн ахшам намазындан соң дөнйадан кичде. Кичлек берлә кабергә куйа алмадылар, дүшәмбе көн кабергә куйдылар.

Әлкыйсса, бу йите йегет бәгъдәл-гаша’ Аллаһы Тәгаләйә күб сәналар вә Пәйгамбәремез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават идеб ул Нийаз Хуҗаның бүлмәсенә керделәр, куйнында бер бәчесе вар иде, бәчесе илә һәр икесене үлтерделәр. Баш очында Хуҗаның һинди кылычы вар иде, аны Гали Кошчы хәзрәтләре алдылар. Олуг углы Халидне бәчесе берлә үлтерделәр, андин кече углы Вәлидне бәчесе берлә үлтерделәр, алтын вә көмешләрне алыб төн йарымында чыгыб китделәр. Хуҗа Нийазның йортына ут салдылар, барыб кальганың Бирдебәк дидеге капуга килделәр. Каравылчылар әйтделәр: «Сезләр нә кешеләрсез». Бунлар әйтделәр: «Безләр Нийаз Хуҗаның колларымыз, Хуҗамызны үлтердек, алтын вә көмешләрене алдык һәм ике угылны үлтердек, шәмди Аксак Тимер гаскәренә керәрмезләр, сезләр бездән разый улырлык алтын вә көмеш алыңызлар»,– диделәр. Бәс каравылчылар башлыкларына барыб әйтделәр, башлыклары килеб болардан күб мал алды вә һәм каравылчылар разый булырлык кадәр малларны алыб бонларны кальга түбәсендән аркан илә төшереб озатдылар.

Әлкыйсса, Гали Кошчы хәзрәтләре йаранлары илә Аксак Тимер гаскәренә керде. Башдан үткән эшләрне вә һәм Истанбулда ничәмә төрлек бидгатьләрне вә һәм аләтләре мәмсух улган галимләрне исемләре илә йазыб вә углан бирдеги Пәйгамбәремезнең хатыны бергә теркәб Мир Тимер хәзрәтнең алдына салды. Хәзрәте Мир Тимер: «Садака рәсуллаһил-

www.darul-kutub.com

Кәрим вә нәхнү галә зәликә минәш-шаһидин»,– див сәҗдәи шөкер әйләде. Гали Кошчы хәзрәтенә чук Вазыйфалар бирде, мәртәбәсене боләнд әйләде.

Әл кыйсса, Аксак Тимер хәзрәтләре Солтан Мәһдигә илче йибәрде бу вакыйгаларны йазыб, үгет вә нәсыйхәт биреб тәүбәйә бойырды. Солтан Мәһди Мир Тимернең илчеләренең колакларыны кисеб йибәрде: «Барыңыз, Солтаныгызга әйтегез, безнең аләтләремезгә сүз тыга башлаган, дөберене бирсен, аләтләремезнең барлыгын вә йуклыгын белер», – диде. Әл кыйсса, бу ике шаһ йите йыл җәнг әйләделәр, гакыйбәтдә Аксак Тимер Истанбулны хәйлә илә алды. Солтан Мәһдине әнваг газаб берлә үлтерде. Әүвәл йегерме галимләрне астырды, бәгъдә үлгәннәрендән соң гаурәт урнын карадылар, мәмсух улганын күрделәр, шоб-шомадыр, бот төпләренең ите берлә бәрабәрдер иләл бәүл йулы калган игәнә сыгар кадәре тишекдер. Солтан Мәһдинең углы Мәсгудне Солтан декде. Алты ай Истанбулда калды, бәгъдә алты айдан соң гаскәре илә Ширванә китде. Ширвандә ничәмә төрлик бидгатьләр вар исә катигъ әйләде. Ширван йортындан Дагстан йортына китде, андин Чистай кальгасына килде, аның ханы илә бик дуст улдылар. Әйде: «Йортыңыздан галлямәи Тәфтазани йыракмы?» – диде. Әйтде: «Тугыз көнлек йулдыр, Әндрай кальгасының тәсаррыфындадыр», – диде.

Әл кыйсса, хәзрәте Аксак Тимер Әндрай кальгасына гаскәре илә китде. Көнләрдә бер көн Әндрай кальгасына йитделәр. Шәһәр капугларыны баглык күрделәр, һичбер хәйлә илә керергә белмәделәр. Ханга илче йибәрде: «Нә өчен кальгаларны багладыңыз?» Хан илчеләр артындин йазу йибәрде: «Син караксың, сиңа нә өчен кальгаларымызны ачалык. Ачыксаңыз китәрсезләр, бәнем кальгам эчендә йите йыллык азыгымыз бардыр»,– див җаваб йазды. Мир Тимер хәзрәте җаваб дәхи йазды: «Бәнем синең шәһәреңдә эшем йукдыр вә һәм мин карак ирмәзмен, Аллаһы Тәгаләнең әмре илә катыйгыль золмәт вәл бидгать кыйламын, әлгаллямәи Тәфтазанине бәнем илә күрешдергел, бән аның мөбарәк йөзләрен күрермен вә һәм дәрес алырмын»,– див җаваб йазды.

www.darul-kutub.com

Әлкыйсса, хан йәнә җаваб йазган: «Бар, йулында йөргел, синең кеби каракга ни галим, ни дәрес»,– див. Хәзрәте Аксак Тимер ачыгъланыб иртәгесен гаскәренә әмер әйләде: «Укларыңызны вә тупларыңызны кальгайа атыңыз, чунки бу хан бәне каттагыть тарыйк див хөкем әйләгән, нә өчен галлямәи Тәфтазани бәндән качыб, авылны ташлаб кальгайа кереб бикләнгән, шайать ки, хан илә сүзләре бердер»,– див ачыгъланыб кальгайа ук вә тубны йибәрделәр, шәһәрнең капуларны йимерделәр, эченә голу кыйлдылар, ханны тотдылар, Мир Тимернең алдына китерделәр. Хан тәүбә әйләде, шәһәрне кире үзенә бирде, галлямәи Тәфтазанины үзе берлә алыб китде. Ул заманда галлямәи Тәфтазани сиксән йәшендә ирде.

Әлкыйсса, йуллары Хаҗи Тарханга уграды, анда һәм алты ай калдылар. Кышладыр. Йаз фасылында Шәһри Болгара ирешделәр.

Әлкыйсса, безнең Болгар әһле һәм фисык вә гыйсйан илә мәшһүр ирделәр вә голәмалары хәйләйе шәргы берлә рибаның хәлийәтенә фәтвә биргәнләр ирде вә гайре зина кеби вә кеше үлтермәк кеби эшләр чук ирде. Ил ля Аллаһы Тәгалә саклаган ирде, бәчебазлык гамәлләре йук ирде. Җомгадан калдылар, аукат-е хәмсәнең артындин укый торган аурадларны калдырдылар, вә бүзә вә ма кыйсмә хәл ал див фәтвә бирделәр. Мисыр йук див җомга намазыны куйдылар. Имам Шафигый сүзе сүз дүгел див аны дошман итделәр. Гайед намазыны куйдылар, Аллаһы Тәгаләгә гасый улдылар, Аллаһы Тәгалә шуның өчен Аксак Тимер хәзрәтене мөсәлләт кыйлды. Ул заманда Болгарда Бикчура хан ирде. Мир Тимер хәзрәте Бикчура ханга илче йибәрде: «Нә өчен җомга вә гайед укымазсызлар?» Хан голәмаларына әйтде: «Мир Тимерә нә җаваб бирерсезләр?» Голәмалары әйделәр: «Китаблар илә җаваб бирермез»,– диделәр. Болгар голәмалары җаваб бирделәр: «Бу Болгар мисыр дүгелдер»,– див, «Викайә» вә «Һидайә» вә гайре мөтәдавилят мөтуннең гыйбарәтләрене салдылар. Хәзрәте Мир Тимер җавабында язды ки: «Сезләр нә өчен «Валвалҗа» вә «Тимер ташы» вә «Канийа» вә гайре китаблара нәзар кыйлмас сезгә карйәдә җомганың фаразлыгына әмер

ителмешдер вә дәхи «Алты хәдис»[32] китабларында мисыр шарт улынмагы күренмәйдер», – диде, һәм «Дөррел-әсар» дидеге китабында «Ля җомгатә вә лә тәшрикъ илля фи миср җамигъ дидеге» хәдис дүгелдер, сәхабәнең сүзедер. Ул сәхабә мөбһәмдер, кайу сәхабә ирдеге һәм беленмәйдер һәм «Ля җөмгатә вә ля тәшрикъ» дидеге хәдисе «Алты хәдис» китабында табылмады диде, вә һәм «Дөррел-әсар» шәрехендә димеш ки имамелһөмам хәзрәте Ногман бине Сабит бу урында имам Әгъзам хата әйләмешдер, «можтәһиднең хатасы мәгъфудыр» диде, һәм хәзрәте Рәсүл җомга намазыны үзендән гайре өч кеше берлә һәм гайед намазыны укыды див илә гайре зәликә җаваблар йазыб Болгара илче йибәрде. Болгар голәмалары әйделәр: «Син Имам Әгъзамны хатага нисбәт әйләдең, «Ля җомгата вә ля тәшрикъ» дигән хәдис дүгелдер дидең, безләр «Дөррел-әсар» дидеге китабның сүзене тотмазмызлар. Безләр белдек тәхкыйк ул китаб могътәзәлидер[33] вә һәм безләр сине бу ана дик сахибе кирамәт див белер ирдек, син һәм могътәзәли имешсең»,– див җаваб йаздылар. Агяһ улгыл «Дөррел-әсар» дидеге китаб могътәзәли дүгелдер, «Алты хәдис» китабы димәгем: берсе – «Сахихе Мөслими»дер, икенчесе – «Сахихе Бохари»дыр, өченчесе – «Мәсабих»дыр, дүртенчесе – «Мишкят»дер, бишенчесе – «Мөбарәк»дыр, алтынчысы – «Мөшарикъ»дыр. Ул заманда безнең Болгарда Харәзм вә Бохара голәмалары кәлам гыйльме илә вә мантыйк вә фәлсәфә фәнләрене укырлар ирде вә һәм укытырлар ирде. Зира ул остазымыз галлямәи Тәфтазани «Шәрхе гакаид»не тәсниф әйләде. Аның талибләре

---

32 «Алты хәдис» – китабы – мөселман дөньясында иң мәшһүр хәдис җыентыклары: 1. «Әл-җамигъ әс-сахих» («Дөрес җыентык»). Авторы – Әбү Габдулла Мөхәммәд әл-Бохари (810 – 870); 2. «Әс-Сахих». Авторы – Мөслим ән-Нишапури (817 – 875); 3. «Сөнән» («Сөннәләр»). Авторы – Ибн Маза (886 елда үлгән); 4. «Сөнән». Авторы – Әбү Дауд әс-Сиҗетани (888 елда үлгән); 5. «Әл-Җамигъ әл-Кәбир» («Зур җыентык»). Авторы Мөхәммәд әт-Тирмизи (892 елда үлгән); 6. «Сөнән». Авторы – Нисаи (915 елда үлгән).

33 Могътәзәли (гар. игътәзәлә) – китү, аерылу фигыленнән, «аерылып чыгучылар» мәгънәсендә. VII –XIV гасырларда ислам динендәге секта.

www.darul-kutub.com

мулла Хәйали вә һәм мулла Әхмәд Җәнди хәзрәтеләре Хашийә итмәклегендә улдылар вә һәм гыйльме мантыйкда «Тәһзиб»не тәсниф әйләде вә һәм аңа барча Талибләренең голәмалары шәрех итеб вә кайулары шәрехләрә хашийә итеб бу өч дийарда гыйльме хәдис мәнсух улдыгы кеби улды. Гыйльме хикмәт илә моназарә илә «Хикмәтел-гайн вә «Хикмәте һидайә» укымак кеби вә һәм укытмак илә мәшгуль улдылар. Илля бу хәдис гыйльме Дагстан йортында вә Мисыр йортында калды. Бу өч йорт голәмалары бу хәдис фәнедан гафил ирделәр. Бәс хәзрәте Аксак Тимер Болгарның бу кaулләрене ишетеб гаскәренә әмер әйләде: «Укларыңызны вә тубларыңызны атыңызлар, билләһилгалийел-газыйм, бу Болгар шәһәренең урыныны начиз вә набуд идәрмен»,– див ант эчте. Өч көннең эчендә шәһәремезне набуд вә начиз әйләде гаскәренең хәдене Аллаһы Тәгаләдән гайре белмәз ирде. Таш кальгаларымызны туб берлән ватдырыб Вулгы төбенә салды. Бикчура ханның унике вәзире илән башларын кистерде, лүэ-лүэ мисал кызларыны вә хатынларыны кол итеб гаскәрләренең рәисләренә бирде. Утыз алты голәманы таганга астырды, калган халыкны бер җомганың эчендә читкә китмәгә әмер әйләде: «Бу урында тормагыз», – диб хөкем әйләде. Җанбакты карты ыругы илә чыкды, Җанбакты авылы улды вә йәнә безнең Мөслим бабамыз ыругы берлә Ташбилге йылгасына төште, Ташбилге авылы булды. Тәтеш карты ыругы берлә Ак идел ярына төште – Тәтеш авылы булды, Мамадыш карты ыругы берлә Нократ иделенә төште – Мамадыш авылы булды. Бәгъзиләре Казан суының тамагында Йаңа Казанга күчеб китделәр, бәгъзиләре Уралның җаниб шәркыйсына Сарайчыкка күчделәр, бәгъзиләре кыргыз халкына керделәр. Ля илә ниһайә әтраф галәмә таралдылар. Әлкыйсса, тарих сигез йөз алтмыш тугызынчы йылында[34], маһ-е Мөхәррәмдә, җомга көн, бәгъдә саләтыль җомга, Румийә айының Җүзәнең йегерме йитенче көнендә Болгар начиз вә набуд булды. Әлдөнйада исеме калды. Ул заманда Болгарның өй хисабы унике мең дә йегерме дүрт

[34] Сигез йөз алтмыш тугызынчы йыл – милади белән 1464 ел.

www.darulkutub.com

өй ирде. Шул Болгарны хараб әйләде, халыкны әтрафе галәмә таратды, вә һәм Ак идел йарында Кашан дидеге шәһәр вар иде, аны һәм шәһәрнең нигезене бетереб, шәһәр халкыны әтраф-е галәмә пәракәнде әйләде. Әлкыйсса, Мир Тимер хәзрәте Болгарны вә һәм Кашанны хараб әйләгәч, газыйлык өчен Мәскәүгә китде. Ул заманда Мәскәү дә хан урыс Иван Вачилий углы ирде. Аны Исламә өндәйен див Болгар йортындин гаскәре илә күчте. Көйләрдә бер көн урысның Уладимир дигән кальгасына йитделәр. Анда кундыклары кичә Хызыр галәйһиссәлам хәзрәте Мир Тимернең дөшенә керде, әйтде: «Аллаһы Тәгаләдән сиңа әмер йукдыр Мәскәү йортыны дингә дәгъвәт итмәгә. Кайткыл, фәкыйһ Әбүл-Ләйс Сәмәрканди кабере эчендә сиңа моштакдыр, шәмди каберең андадыр», – диб күзендин гаиб улды. Иртә торыб хәзрәте Мир Тимер саләтел-фәҗерне укыгач, галлямәи Тәфтазани хәзрәтеләренә дөшне сөйләде. Галлямәи Тәфтазани әйтде: «Йа, солтанымыз, әмер улмаса – бармайык, зира ки шайтан ләгыйн пәйгамбәрләр сурәтенә керә алмас», диде.

Әлкыйсса, ул көн якшәмбе көн ирде. Гакраб айының әүвәлге көн урысларның Пукравы иде, чиркәүләренә теләү итмәгә кергән көнләре иде. Мир Тимер хәзрәтләре боларның чиркәүләре йанына килде. Чиркәү күршесе урысның кара байталы вар иде, урыслар чиркәүләрендин чыкдыкларында шул урысның азбарындан кара байталны алыб ике арт ботындин тотыб атды, чиркәүнең манарасы йыгылды. Ул байтал чиркәүнең икенче җанибенә төшеб сөйәкләре көл булды. Ул байтал төшкән йирдән Аллаһы Тәгалә бер күл пәйда кыйлды. Аксак Тимер гаскәре ул күлдән су алыб тәһарәт кыйлсынлар өчен, зира ки ул Уладимир кальгасының нәһере йук ирде, урыслар койу берлә тереклек әйләделәр. Бу көндә ул мөбарәк күл бардыр, урыслар аны нәҗес күл дийеб эчмәзләр, ул чиркәүгә һәм кермәсләр Аксак Тимер нәҗес әйләде дийеб. Әлкыйсса, Уладимир кальгасындан Сәмәркандка кайтмага тәваҗҗоһ әйләде. Йуллары Йаңа Казанга дөшде. Ул заманда Йаңа Казанның ханы Илһам хан ирде. Мир Тимер килүене ишетеб истикъбаль әйләде. Йаңа Казанга керделәр, гаскәрләрене әтрафә таратдылар. Ике ай үзе

www.darul-kutub.com

вәзирләре илән, галлямәи Тәфтазани илән вә гайре голәмалары илән тордылар, үзе вәзирләре илән әтрафда улан табигыйн лар каберенә зийарәт әйләде. Әүвәл Казан суының башында улан табигыйн Иштирәк Байтирәк углына, Курсада Гадел Абдул углына, Кәче илендә Зөлмөхәммәд Мөхәррәм углына, йәнә Гайшәбикә авылында Гайшәбикәнең үзенә, атасы Хаҗи Әрәмле каберенә, углы Таҗеддин әфәндегә вә һәм Нократ Шушмәсендә улан Хәсәншәйех Кадер углына, Балтач Нәдер углына, Салавыч Абайдан углына, Исмәгыйль Абзан углына, Зөйә тамагында Илйас Муса углына, Касыйм Ибраһим углына, Уҗым авылында Фәйзулла Гобәйдулла углына, Күк Күз авылында Колмөхәммәд Динмөхәммәд углына, Надиршаһ Сәлим Ишкинә углына, Бикташ авылында Тәмуш хаҗи Солтан Морад углына, Ибраһим Илһам углына, Симуш Килдебай углына. Бу барча табигыйн ризванә Аллаһы галәйһим әҗмәгыйнның камуларына Йаңа Казанда торыб зийарәт әйләде. Әлкыйсса, хәзрәте Мир Тимер Казандин Содума килде, йәгъни Алабуга шәһәренә килде. Ул заманда Содум ханы Илбакты ханның углы иде, үзе һичбер дин-дийанәт белмәгән хан ирде. Аны динә дәгъвәт әйләде, кабул әйләмәделәр. Ул Содум бер олуг шәһәр иде, аны зир вә зәбәр килтерде. Шәһәрләрене вә кальгаларыны йимертеб Ак идел эченә куйды. Үзләрене әсир әйләде, калганларыны пәракәндә идеб әтрафе галәмә таратды. Туймы тамагында улан табигыйн лар каберенә зийарәт әйләде. Әүвәл Акбаш кызына зийарәт әйләде, Кирсан Илмәмәт углына, Әләмгол Муллагол углына, Айдар Аит углына, Йулдаш Мәскәү углына. Андан Иделне чыгыб Мәләкәс авылының Сәйед Сәйдар углына, Тукбай Байгол углына, Җанбакты Уразбакты углына, Иманай Йунай углына, Ишбирде Тукбирде углына. Мәләкәс авылында йатыб зийарәт әйләде. Гаскәре Ак идел буйында Агый халкыда йатды. Әлкыйсса, кыш көне булды, кар йагар вакыт булды. Ирнә суының тамагы Зәйгә койгандыр. Ул урында Бәйраш ханның углы ирде. Аксак Тимер аңа хат йазды: «Бән сәңа кышламага барырмын», – див. Бәйраш хан хат йазды: «Әйа, солтаным, хәзрәте Мир Тимер, башым өстендә атамыз-анамыз сәңа

www.darul-kutub.com

фида булсын, кабулым вардыр, Раззак Аллаһы Тәгаләдер»,– диде. Бәйраш хан Баграш суы буйында Ирнәгә койгандыр. Ул суның бер бийек тагы вардыр, ул тагның башына бер олуг сарай дөзделәр. Ул сарай тәмам улгач, Мир Тимер хәзрәтне өндәде. Гаскәре илән килде. Баграш суының буйы гаскәр булды. Бәйраш хан Зәйдән гаскәре илән истикъбаль идеб ул таг башындагы сарайа килтерде һәм кергезде: «Колың Бәйраш синең хәзрәтеңә кышлык сарай төзеде, кабул итсәңез торырсыз», – диде. Аксак Тимер сарайны хублады, Бәйраш ханә күб хәзинәләр бирде.

Әлкыйсса, ул кыш анда кышлады. Мулла Хафиз әт-Ташкәнди каберенә зийарәт әйләде. Минзәлә суының тамагы Ак суына койгандыр, анда Мостафа хана кунак булды. Гариф билләһи Хуҗа Бәйрам каберенә зийарәт әйләде. Чаллы суы тамагында Ак идел йарында Мәүлед Хуҗага зийарәт әйләде. Андан Байчура Чирмеш авылында Хуҗа Әмир Кәланә зийарәт әйләде. Әлкыйсса, кайтыб Баграш суының буйында Бәйраш хан төзегән сарайына керде, кышладылар. Җүзәнең уникенче көнендә Аксак Тимер гаскәре илә кузгалды, Бәйраш хан берлә видаглашдылар. Бәйраш хан аңа ийәреб Акның Тугаш хан авылында ике әкбәр табигыйн каберләре вар ирде: бере – Морад Хафиз, икенчесе – Мөхсин Хафиз Йулдаш угланларыдыр. Андача бергә барыб зийарәт әйләде. Андан Мир Тимер хәзрәтләре видаг итеб, Сәмәркандкә китде, Бәйраш хан Зәйгә кайтды. Әлкыйсса, Аксак Тимер хәзрәтләре Уралны чыгыб кыргыз халкына керде, анларны дингә өндәде вә һәм төрекмән халкыны өндәде. Кабулы Ислам иткәнләренә йортларын бирде, үзендин хан тикде. Кабул итмәгәнләрене кол итеб әсир кыйлды.

Әлкыйсса, хәзрәте Аксак Тимер Сәмәркандкә өч йыл солтан улды. Дүртенче йыл маһе Рамазан мөбарәкнең йегерме йитенче кичәсендә фәтвәйе җөмһүре голәмайы хәнәфийә илә ләйләтел кадердер хәзрәте Мир Тимер даре бәкайә рихләт әйләде. Галлямәи Тәфтазани гайед көнендә вафат булды. «Калу иннә билләһи вә иннә иләйһи раҗигун». Тарих һиҗрәтнең тугызынчы йөз икенче йылы[35] ирде, Эт йылы ирде.

35 Тугыз йөз икенче йыл – милади белән 1496–1497 еллар.

www.darulkutub.com

### Фасыл фи бәйани фәридед-дәһер вәз-заман

Остазымыз галлямәи Тәфтазани тарих һиҗрәтнең сигез йөз йегерме йылы ирде дөнйайә килде. Замане әүвәлдә Тәфтазани илә Әндрай кальгасы бер иде, Тәфтазани бер мәхәллә ирде. Бер заман Әндрай кальгасына ваба керде, йәгъни тагун илә Сәлсан шәһәре һәлак улдылар. Шәмди авыл булыб калды. Галлямәи Тәфтазани йегерме ике йәшендә галлямәлек мәртәбәсенә ирешде. Әүвәл «Тасрифе Зәнҗани»гә шәрех итде, йегерме түрт йәшендә «Мотаввәлне» тәсниф кыйлды. Алтмыш йәшендә Харәзмә варыб дәрес әйтде. Өч йыл анда «Тәлвих Хашиәи Тәузыйх»ны тәсниф кыйлды вә һәм «Тәһзибе мантыйк»ны төзеде. Харәзмдән кире Тәфтазанга кайтды. Ахыр гомерендә сиксән йәшендә ирешдекдә Мир Тимер хәзрәтеләренең имамы улды. «Шәрхе Тәлхыйсе Мөтаввәлне» хәзрәте Мир Тимер өчен ихтисар кыйлды, зира Аксак Тимер хәзрәте үлгәнчә дәрес алмакны вә сабак алмакны куймады. Үлдеге вакытында дәрес «Мишкят» шәрифдә китабел-хаҗны укыган заманда үзе алтмыш өч йәшендә ирде. «Калу иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун». Бу рисаләгә «Тәварихы Болгария» див исем бирдек. Фәкыйрь Хисамеддин бине Шәрәфеддинне дога’и хәйреңездин фәрамуш бойырмайә сезләр, тарих һиҗрәтнең тугыз йөз туксан икенче йылында[36] Ташбилге авылында маһе Мөхәррәмнең 15 нче көнендә Җүзәнең һәм унынчы көнендә Сычкан йылында бу рисалә тәмам улынды.

[36] Тугыз йөз туксан икенче йыл – миляди беләнн 1584 ел.

# СҮЗЛЕК

А
Агяһ – белеп торучы
Аләт – җиһаз, корал, ирләрнең женси әгъзасы
Ан – вакыт
Атәшпәрәст – утка табынучы
Аурад – догалар
Ашна – таныш, дус

Ә
Әгъзам – иң бөек
Әгъләм – иң олы галим
Әҗәл – вакыт, үлем
Әзгасе әхлам – буталчык төшләр, саташу
Әкъдам – аяклар
Әкябир – олуглар, зурлар
Әл – кул
Әлкыйсса – кыскасы
Әлхасыйль – кыскасы
Әнваг – төр, сорт
Әсбаб – сәбәпләр, кирәк-ярак җиһазлар
Әтраф – тарафлар, тирә-як як
Әфляк – күк йөзләре
Әхкям – хөкемнәр, шәригать кануннары
Әхрака – яндырды

Б
Батыль – ялган
Бәд – начар
Бәйгать – буйсыну турындагы ант
Бәйт – йорт
Бәйтел мал – казна, хәзинә йорты
Бәка – мәңгелек
Бәрабер – тигез
Бәталәт – ялкаулык
Бәүл – сидек
Бәхер – диңгез
Бәхрәмәнд – файдаланучы
Бидгать – яңа гадәт, гөнаһлы эш, гөнаһ
Бизагать – байлык, мал, товар
Боләнд – биек, югары
Бөреҗ – Зодиак йолдызлыгы, унике айны унике йолдыз исеме белән атау

В
Вазыйфа – хезмәт хакы
Васләт – кавышу
Вәйран – җимерек, җимерү
Важиб – һичшиксез үтәлергә тиешле эш
Вәҗеһ – йөз, сәбәп
Вәхданийәт – Аллаһының берлеген тану
Видаг – саубуллашу, аерылу

Г
Габдешшәмс – кояшка табынучы
Гавам – гади халык
Гаҗиз – көчсез
Газа – дин өчен изге сугыш
Газабланып – ачуланып
Газем – ният
Газый – дин өчен сугышучы
Газыйм – бөек
Гаиб – югалу
Гайб – күренмәгән, теге дөнья
Гайед – гает, бәйрәм
Гайн – чишмә
Гакраб – чаян
Гакыйбәт – нәтиҗәдә
Гали – бөек
Галлямә – иң олы галим
Гамамә – чалма
Гараиб – сирәк очрый торган, гаҗәп

www.darul-kutub.com

әйбер
Гарыз – тапшыру
Гасый – фетнәче, гөнаһлы
Гаташ – сусау
Гафил – белмичә калган
Гәшт – сәяхәт итү
Голу – ярсу
Голүм – гыйлемнәр, фәннәр
Горрә – башлангыч
Горуҗ – күтәрелү
Госел – коену, юу
Гөруһ – төркем
Гуш – колак
Гүрстан – каберлек, зират
Гыйбадәт – Аллага коллык кылу, табыну
Гыйзам – бөекләр
Гыйнадия – кире

Д
Данишмәнд – белемле
Дар – йорт
Дарел бәка – мәңгелек йорт, теге дөнья
Дайә – бала караучы хатын
Дәват – кара савыты
Дәрхаль – шунда ук
Дәфен итү – күмү
Дәһер – чор, заман
Дийар – дәүләт
Доррә – попугай, тутый кош
Дөбер – арт, арка
Дөшнам – сүгү, хурлау

Ж
Жэмагать – төркем, җыелган халык
Җәнг – сугыш
Җегәр – йөрәк, бавыр
Җидал – талаш
Җомаг – җенси якынлык кылу
Җур – тәр

Зафәр – җиңү, уңышка ирешү
Зәбәр – өст
Зәмин – җир, дәүләт
Зир – аст
Зольмәт – караңгылык, җәбер
Зоһур – күренү
Зөмрә – төркем

И
Ибтида – башлангыч
Игъраз – кире кагу
Идел – елга
Идракъ – аңлау
Изен – рөхсәт
Икъдам – алга китү, тырышу
Икърар – дөреслеген тану
Икътиза – теләк
Илтимас – сорау, үтенү
Илтифат – игътибар
Имтисалән – буйсынып
Ирад – мисал китерү
Иркәк – ир бала
Истигъдад – хәзерләү
Истигъмал – файдалану, гамәл кылу
Истикъбаль – каршы алу
Истимдад – ярдәм
Ихтисар – кыскарту
Иттифак – бердәм

Й
Йөкчәк – борынгы, абруйлы, бөек
Йәнчү – аяк

К
Кадәм – аяк
Кадим – иске, борынгы
Каим – басып торучы, үз урынында торучы
Калил – аз
Катыг – кисү, бетерү

Катыйг – кисүче, бетерүче
Каттаг – кисүче
Камәр – Ай
Карйә – авыл
Каул – сүз
Кәвакиб – йолдызлар
Кәз – тапкыр, мәртәбә
Кәйфийат – үзенчәлек
Кәрамәт – могҗиза
Кәррамә – изге итте, юмарт итте
Кәсир – күп
Кәһеф – мәгарә
Кирам – изгеләр, юмартлар
Кенар – яр
Когуд – өйдә калу
Колүб – йөрәкләр
Корра – Коръән укучы
Корун – гасыр, чор
Көллү шәй – барлык әйбер
Кәнеш – Кояш
Көһһан – күрәзәчеләр
Куе – кырын
Кяһин – күрәзәче

Л
Ләгыйн – ләгънәт төшкән
Ләкаб – кушамат
Ләшкәр – гаскәр
Ләүхел-мәхфуз – сакланылган такта, Язмыш тактасы
Лүэ-лүэ – энҗе
Лязим – кирәкле

М
Манигъ – тыючы
Маһир – оста
Мәгъмур – төзекләндерелгән
Мәгъриб – көнбатыш
Мәгъфу – гафу ителә
Мәгъһүд – искә алынган, билг
Мәдфүн – күмелгән
Мәкамат – урыннар
Мәлгунь – ләгънәтләнгән
Мәлик – падишаһ
Мәлхәмә – героик поэма,
Мәмнугъ – тыелган
Мәмсух – шома, печелгән
Мәнсух – гамәлдән чыккан
Мәнфәгать – файда
Мәраз – авыру
Мәртәбә – дәрәҗә
Мәтләгъ – кояш чыгу, таң ату
Мәфһүм – мәгънә
Мәшаих – шәехләр
Мәшвәрәт – киңәш
Мәхбус – тоткын ителгән
Мигъраҗ – күккә ашу
Моҗдә – шатлыклы хәбәр
Мозаффар – җиңгән, теләгенә ирешкән
Моназарә – сүз көрәштерү
Монтазыйр – көтеп торучы
Морәҗҗәб – хөрмәтле
Морур – вакыт узу
Мосагыйд – мөмкинлек бирүче
Мосәлләт – җиңүче
Моукут – чикләнгән
Мохит – океан, әйләнә-тирә – билгесез
Мөҗавир – изге каберен саклаучы
Мөҗтәһид – тырышучы, дин китаплары буенча яңа хөкем чыгаручы
Мөкәррәм – хөрмәтле, кадерле
Мөләүвәс – шакшыланган
Мөлзәм – бәхәсләшеп җиңелгән
Мөнәҗҗим – йолдызлар буенча күрәзә итүче
Мөнкасим – бүленгән, кисәкләнгән
Мөрәххәс – китәргә рөхсәт алу
Мөстәкыйлән – бәйсез рәвештә, аерым
Мөтәваль – тоташ

www.darulkutub.com

Мөтәватир – халык телендә киң аралган
Мөтәдавил – еш кулланыла торган
Мөттәсыйф – күрсәтеп үтелгән, сыйфатланган – текстлар
Мөхтәлиф – төрле
Мөшәррәф – кадерле, хөрмәтле

Н
Набуд – харап ителгән
Нам – исем
Намәгъкуль – ярамаган
Нар – ут
Начиз – юк ителгән
Нәҗат – котылу
Нәҗес – шакшы
Нәзафәт – чисталык
Нәкыс – ким, кимчелек
Нәүм – йокы
Нәфес – рух, җан
Нәхес – бәхетсезлек, шомлык
Нәһер – елга
Нида – тавыш
Нишан – дәрәҗә, билге
Нөбөввәт – пәйгамбәрлек

Ө
Өслүб – ысул

П
Пәйда – күренү, табылу
Пәракәндә – таратылган

Р
Раззак – ризыкландыручы
Рәванә – юлга чыгу
Рәвафиз – шигыйлар
Рәис – башлык, җитәкче
Рәмиза – кайнар булды
Рәнг – төс
Рәнҗ – авыру, җәфа
Риба – процент алу
Риҗаль – ирләр
Риҗалел-гаиб – гаиб ирәннәр, борынгы мифология буенча күзгә күренми торган ирләр
Ризван – ризалык
Рисаләт – илчелек, пәйгамбәрлек
Рихләт – сәфәр
Робгы мәскүн – Җир шарының кешеләр яши торган дүрттән бер өлеше
Роҗуг – кире кайту
Росух – ныклык
Руми – христиан, византияле

С
Сакин – яшәүче, торучы
Салават – догалар, намазлар
Саләт – дога, намаз
Санийә – икенче
Сари – таба (юнәлеш)
Сәхабә – сөхабәләр, яраннар
Сахиб – дус, хуҗа
Сахибел җәмал – матур
Сахыб – сәхабәләр, яраннар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең яраннары, ул исән чагында ислам динен кабул иткән кешеләр
Сөбат – ныклык
Сәбга – җиде
Сәгадәт – бәхет
Сәгыд – бәхет
Сәйр – карап йөрү
Сәкәрҗә – исерткеч
Сәна – мактау
Сәргаскәр – гаскәр башлыгы
Сәрхәд (д) – чик
Сәтер – каплау, ябу
Солосән – өчтән икесе
Сохоф – Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләргә җибәргән Изге китаплар

Сөлүк – юл, суфилык юлы
Сыйдык – дөреслек
Сыйххәт – тазалык, исәнлек

Т
Табиб – врач, дәвалаучы
Табигать – иярүче хатын-кызлар
Табигъ – буйсынучы, иярүче
Табигыйн – иярүчеләр, сәхабәләрдән ислам динен кабул итеп, белем алган ирләр
Тагам – аш, ризык
Тагут – чума
Таифә – кабилә
Талиб – шәкерт, укучы, белем өстәүче
Тарикъ – юл
Тасдыйк – дөресләү
Тәбәссем – елмаю
Тәвабигъ – буйсынучылар, иярүчеләр
Тәбгы-табигыйн – иярүчеләргә иярүчеләр
Тәгъбир – төш юрау
Тәгълим – белем алу
Тәгъриф – аңлату, белдерү
Тәксыйм – бүлү
Тәсаррыф – тоткынлык
Тәсмийә – исем кую
Тәфәккер – уйлау, фикерләү
Тәхкыйк – дөрестән, чыннан
Тәхриб – җимерү
Тәхсыйль – белем алу
Тәшам – начарлык, шомлык билгесе
Тәшрикъ – намаз вакытында йөзне көнчыгышка юнәлдерү
Теши – кыз бала
Тәэвил – аңлату, юрау (Коръәнне, төшне)
Тәэхир – соңга калдыру
Толәбә – шәкертләр, белем алучылар

Ү
Үлә – беренче

Ф
Фалгуй – фал ачучы, күрәзәче
Фарыз – үтәлергә тиешле эш
Фасыл – бүлек, сезон
Фәҗер – таң
Фәрәнг – Европа, европалы
Фәреҗ – ярык, хатын-кыз җенси әгъзасы
Фәрех – шатлык
Фәрид – бердәнбер
Фәсыд – кан алу
Фирак – аерылу
Фәрамуш – оныту
Фискать – бозыклык
Фөруг – тармак

Х
Хаб – йокы
Хадисат – вакыйгалар
Халәнки – чынлыкта исә, хәлбуки
Халикъ – Бар итүче, Яралтучы (Аллаһы Тәгаләнең иң матур исемнәренең берсе)
Хамилә – йөкле хатын
Хараҗ – ясак, салым
Хәвадис – вакыйгалар
Хәҗамәт – кан алу
Хәй – тере, тереклек иясе
Хакыйрь – түбән, мескен
Халаикъ – халык, халыклар
Хәмед – мактау
Хәмел – йөк, көмән
Хәммам – мунча
Хәр(р) – эсселек
Хәшәрәт – бөҗәкләр

www.darul-kutub.com

Хин – вакыт, заман
Хисар – крепость, ныгытма, камау
Хоуз – диңгез, күл
Хоуфнәк – куркыныч
Хуб – матур, яхшы

Ч
Чук – күп
Чунки – чөнки
Чурә – якын

Ш
Шәкавәт – бәхетсезлек
Шәмди – хәзер, инде
Шәмес – кояш
Шәрик – дус, компаньон
Шәрыг – закон, шәригать
Шөһавәт – җенси дәрт
Шекяр – ау аулау
Шогуб – бүлекләнү
Шоум – шомлык, бәхетсезлек
Шөһүр – айлар

Һ
Һәвәс – теләк
Һәйбәт – курку
Һәзым – ашказанының ризыкны эшкәртүе
Һәргиз – һичкайчан
Һилял – яңа туган ай, айның беренче чиреге (7 көн)
Һөмам – батыр, мактаулы

www.darul-kutub.com

*Белешмәләр өчен*

www.darul-kutub.com

**ТАҖЕТДИН ЯЛЧЫГОЛ.** ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЯ.
Казан: Хузур-Спокойствие, 2014. – 154 бит.

**Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте**
**Экспертлар советы карарына нигезләнеп басыла**

*© Издательство «Хузур-Спокойствие», 1435/2014*
*© Гилязутдинов С.М.*

Формат 60x84 $^{1}/_{16}$, печатных листов: 9,75;
бумага офсетная, печать офсетная, тираж 2000 экз.
г. Казань, пр. Победы, 30, тел.: 251 47 88,
электронная почта: ipk_ppk@mail.ru

Типография «Астор и Я» г. Казань, Ахтямова, 13а.
Отпечатано в соответствии с предоставленным
электронным материалом.

www.darul-kutub.com